КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни ҖОМГА

№ 14
20 октябрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Флүн* МУСИН. Татар теле үз илендә хуҗа булу хокукын үзе яшәү һәм халкыбызны яшәтү өчен күп гасырлык көрәше, шул көрәш дәвамында ирешкән казанышлары белән яулады.

6 *Лөкман* ЗАКИР. Бөтен шымчыларны утыртып бетерергә ГУЛАГ лагерьларында гына урын житмәс, әмма аларның «эш»е дәүләт сере булырга тиеш түгел.

9 *Мәхмүт* ӘХМӘТҖАНОВ. Гаҗәеп талантлы һәм үзенчәлекле әдип Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә» дип аталган китабы совет тоталитар системасына гаепләү акты булып тора.

12 *Илдар* НИЗАМОВ. Рекламада да, әдәби һәм башка әсәрләрдәге кебек, туган телнең барлык байлыгын, иң нечкә стиль үзенчәлекләрен дә файдаланырга кирәк.

15 *Лилия* САТТАРОВА. Фәндә һәм халык арасында мөселман сәнгате турында дөреслеккә туры килми торган фикерләр бүгенгә кадәр яшәп килә.

20 *Кояш* ТИМБИКОВА. Башка халыкларны куркытып яшәү мәрхәмәтсез Русия империясендә әле хәзер дә дәвам итә түгелме?



Заман кемнең заманы? — Идегәйнең заманы!

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Күкләрдә көзләр азаны, күңелдә — тәкъдир кайтавазы: Татар иле торналары китә... Ә без бу юлы китмәскә булдык әле, торналар, таралмаска, сибелмәскә булдык. Киткәннәр дә кайтыр чорлар килде. Без бөек күктәшегез, канатташыгыз тәгаенләгән "Торналар төшкән җирдә" яшәргә хөкем ителгән...

Газинур МОРАТ

МИН ӘЙТТЕМ

Флүн МУСИН,
академик

Татар теле нигә кирәк?



Беренче карашка, кайберәүләргә бу сорауны куеп тору ук урынсыз һәм хәтта мәгънәсез дә булып күренергә мөмкин. Чөнки ул «Кешегә яшәү нигә кирәк, ашау-эчү, шатлану-моңлану нигә?» — дип сораган кебегрәк яңгырый. Әмма кызганыч ки, татар теленең нигә кирәклеге турындагы сорауны реаль тормыш үзе өледән-өле куярга мәҗбүр итә. Менә гадәти бер мисал. Шушы көннәрдә миңа Казандагы бер татар гимназиясендә ата-аналар җыелышында булырга туры килде. Шунда җыелыш башлануын көтеп утырганда, бер әни кеше, мөлаем гына татар ханымы, зарланып китте.

— Татар телен генә укыту җитмәгәнмени, нигә математика, физика, химияләрне дә татарча укытып, бу телне рәтләп белмәгән балаларыбызның башын катыралар микән? Болай татарча гына уку белән алар вузларга керә алмаячаклар ич.

Бу ханымга тагын берничә ана килеп кушылды. Мин белдеклерәк булып, бездә хәзер татар теленең дә дәүләт теле дип игълан ителүе, бу телдә югары уку йортларында да белем алу мөмкинлеге ачылачагы, телләр турында закон кабул ителүе хакында сөйләп, әлеге ханымнарны тынычландырырга тырыштым. Әмма теләгемә ирешә алмадым. Әңгәмәдәшләрем үз сүзләрендә калдылар:

— Кәгазьдә генә калды түгелме соң ул закон дигәнегез. Тормышта әлләни үзгәреш күренми ич. Татар теле моңарчы ничек кирәкмәгән булса, хәзер дә шул хәлендә кала. Бу телдә белем алучы балаларыбыз соңыннан үкенмәсләр микән?

Кыскасы, әлеге ханымнарның татар теленә карашы үткәнрәк еллардагы: «Авыл капкасыннан чыккач татар теленең кирәге бетә», — дигән мәгълүм гөман итү белән аваздаш булып чыкты. Белгәнебезчә, ул елларда кайчак хәтта урысча бер авыз сүз белмәгән татар агай-энесе дә, дөньясын каргый-каргый, баласын ничек тә булса урыс мәктәбендә укытырга тырыша иде. Чөнки ул заманда татар теленең кирәге бөтенләй диярлек беткән иде, тормышта үзеңне кеше итеп сизеп яшәргә теләсәң, «өлкән агай»ның бик данланган телен белергә кирәк иде.

Дөньялар күзгә күренеп үзгәргән чорда яшәсәк тә, агай-эне арасында татар теленә караш нигездә элеккечә кала, аңа бу тормышта әлләни хаҗәте булмаган нәрсә итеп карау һаман яши. Чөнки тормышыбызның үзендә мондый карашларны үзгәртердәй гамәлләр әлләни күренми.

Безнең каныбызга, аңыбызга бер гадәт нык сеңгән, ягъни хаким даирәләргә карап фикер йөртергә, эш итәргә күнеккәнбез. Менә бу тел мәсьәләсендә дә авыл һәм шәһәрләрдә яшәүче гади халык беренче чиратта югарыдагыларга игътибар итә. Ә анда, хакимият башында торучыларда, татар теленә мөнәсәбәттә, бигрәк тә аны рәсми планда, дәүләт эшендә куллану мәсьәләсендә борылыш бик сизелми. Дәүләт аппараты, район масштабыннан алып республиканыкына кадәр, һаман да урысча яза һәм сөйли. Ягъни телләр турындагы закон башлап шушы законны чыгаручылар һәм аны гамәлгә ашырырга тиешлеләр тарафыннан үтәлми. Җәмәгатьчелек бу хакта өледән-өле искә төшереп торса да, рәсми даирәләрдән аның сүзенә колак салучы әлләни күренми. Табигый, мондый игътибарсызлык, битарафлык үзе үк халык арасында телләр турындагы законның татар теленә караган өлешенең гамәлгә ашырыла алуына ышанычны киметә, кайчак хәтта юкка да чыгара. Реаль тормыштан чыгып карагандa, әлеге закон бары урыс теленең генә позициясен ныгытты дигән фикергә киләсең. Ул хәзер Мәскәү әмере белән генә түгел, бәлки үзебез кабул иткән закон буенча да асылда бездә гамәлдәге төп дәүләт теле булып кала. Һәм моны тиешле агай-эне яхшы аңлый. Нәтиҗәдә, һәртөрле рәсми оешмаларга яки кибетләрдә сатучыларга татар телендә мөрәҗәгать итсәң, һаман да еш кына: «Не понимаю. Говорите по-русски!» — дигән тәкәббер җавап аласың; нишләп татарча белергә теләмәүләрен төпченә башласаң, кайчак хәтта Жириновскийның татарларны Монголиягә куу, ягъни туган җиреннән читкә сөрү белән янавын кабатлауны ишетәсең.

Татар теленә, асылда, кимсетүле мөнәсәбәт, кызганыч ки, кайчак үзебезнең милләттәшләребез арасында да сизелә. Үзләрен татар халкының патриотлары, милләтне әйдәп баручылар итеп күрсәтергә тырышкан кайбер зыялыларыбызның балалары да татарча белмиләр һәм мондый очракта аталар белән балалар урыс телендә аралашып аңлашалар.

Кайчандыр күп кенә халыкларның, бигрәк тә төркиләрнең аралашу теле булган, шунлыктан «татарга тылмач кирәкми» дигән горур әйтемне тудырган татар теле нишләп хәзер кайчак хәтта «әттә», «әннә» дип телләре ачылган татарлар тарафыннан да кире кагыла торган кирәксез бер нәрсәгә әверелеп бара соң? Моның сәбәпләре төрле, әлбәттә.

Татар теленең мондый хәлгә төшүе, барыннан да элек, аны тудырган һәм яшәткән халыкның тарихи язмышы белән бәйләнгән. Белгәнебезчә, Казан ханлыгын җимергәннән соң Русиядә бу дөньяда бик мөһим роль уйнаган, урысның төп көндәше итеп каралган татар факторын төрлечә көчсезләндерү һәм ахыр чиктә юкка чыгару сәясәте үткәрелә. Моның өчен, бер яктан, татарның рухи-интеллектуаль җегәрен, аны үзләрендә йөртүче көчләрне чукындыру аша урыска күчерү, алай мөмкин булмаганда, юкка чыгару юлы белән өкренләп көчсезләндерү яки корыту чаралары күрелде. Нәтиҗәдә, татар интеллекты исәбенә урыс дөньясы көчәйде, ә безнең халык кайтарып алмаслык рухи-интеллектуаль югалтулар кичерде. Икенче яктан, татар булып калганнарны гасырлар дәвамында төрлечә кысу, кыерсыту, кимсетү, мыскыллау сәясәте алып барылды. Бу дөньяда татар булып яшәү үзе бер гөнаһ кебегрәк күренә башлады. Ахыр чиктә яшисе килү инстинкты безнең халык арасында татарлыктан качу күренешләрен барлыкка китерде. Берәүләр урыс дөньясында яши алу өчен урыслашу ягын карадылар. Икенчеләре, борынгыдан хәзерге Башкортстан туфрагында яшәгәннәре һәм анда җирле халыкка әверелгәннәре, патша властьлары татарларны кимсетү максатында башкортларга гына җир биргәндә, җирсез калмас өчен башкорт булып язылырга мәҗбүр ителделәр. Ә хәзер шундый татарларны тумыштан саф башкорт итеп күрсәтмәкче булалар. Гомумән, соңгы вакытта Башкортстанда, аннан килгән хәбәрләргә караганда, татарларга татар булып яшәү тагын да авырая төшә. Аларның тарихын инкарь итү, телен төрлечә кысу һәм, гадәттәгечә, башкортлаштыру бара. Күрәсең, Русия җитәкчелегенең башка республикаларда яшәүче урысларның мәнфәгатьләрен якыннан кайгыртуы үрнәгендә Татарстан хакимиятенә дә башка төбәкләрдәге милләттәшләребезнең хәле, язмышы хакында ныклап уйларга һәм конкрет эшләргә кирәк. Хәзер бу мәсьәләдә башкаларның кәефен бозарга теләмәгәнд[...] битарафлык яки ваемсызлык күрсәтү инде бер[...] чек тә аклана алмый. Өченчеләре исә, Урта А[...] якларына китеп барып, шундагы халыклар арас[...] кереп югалдылар.

Шушы рәвешле үз милләтеннән качу татар те[...] ленә мөнәсәбәттә дә сиздерә. Ягъни туган телдә[...] качу башланды, һәм ул бүгенге көнгә кадәр дә[...] итә. Нәтиҗәдә, татар теленең яшәеш офыгы тар[...] ганнан-тарая бара. Бу телнең кулланылу даир[...] дә кысыла. Бүген ул күбрәк көндәлек тормыш-к[...] күреш теле, матбугат теле, китап теле, аерым гу[...] нитар фәннәр теле рәвешендә яши. Соңгы вакы[...] татар матбугаты белән татар китабының тира[...] һәм аларны укучылар санының күзгә күренеп к[...] мүе бу телнең яшәү җирлеген тагын да тара[...] Билгеле булганча, милли матбугат белән милли к[...] тап, төрле сәбәпләр аркасында, халкыбызның [...] тән өчен тәшкил иткән, ягъни Татарстаннан чит[...] яшәгән күпчелек милләттәшләребезгә хәзер би[...] барып җитә һәм озакламый ул бөтенләй туктал[...] мөмкин. Үзебезнең республикага килсәк, анда та[...] тар матбугаты һәм китабының хәлен урысныкы б[...] ләп чагыштырганда гыйбрәтле бер хакыйкать ачык[...] лана. Мәсәлән, узган елгы мәгълүматларга караган[...] да, хәзер Татарстанда барлыгы 238 рәсми теркәлгә[...] газета-журнал булып, шуларның 38е саф татар[...] 124е бары урысча, ә калган 76сы ике яки өч тел[...] чыгарыла икән. Татарча китап бастыруга килсәк, [...] эшнең торышы тагын да аянычлырак. Хәзерге к[...] дә республикада 120дән артык нәшрият булып, ш[...] ларның берничәсе генә татарча китаплар чыга[...] республика күләмендә дөнья күрә торган китапла[...] ның бары берничә проценты гына чын татарны[...] икән. Бу саннар татарның үз илендә аның ми[...] матбугаты белән китабы урыс телендәге белән ча[...] гыштырганда нинди мескен хәлдә калуы тур[...] сөйли.

Соңгы вакытта реклама характерындагы газе[...] лар күбәеп бара. Киң катлау укучыларның ди[...] катен җәлеп итүче бу төрбасмалар татар теле[...] бөтенләй юк. Моның урынына татар газета-журна[...] лары урысча реклама бирү белән шөгыльләнәле[...] Хәлбуки, реклама — телне пропагандалауның у[...] мле чараларыннан берсе. Ә без бу чарадан бөте[...] ләй диярлек файдаланмыйбыз икән. Кыскасы, ма[...] бугат теле рәвешендә дә татар теле бүгенге к[...] республикада икенче дәрәҗәле булып тора.

(Ахыры 5 нче биттә).

Казанда музей әһелләре җыелып сөйләште

Октябрь аенда башкалабызда «Югары уку йортлары-ның музейлары. Проблемалар, перспективалар» дигән темага региональ конференция булып узды. Конферен-циянә Урта Идел төбәгенең югары уку йортлары музей-ларының фәнни-методик советы, Казан дәүләт универси-тетының тарих музее, Татарстан җөмһүриятенең берләш-терелгән дәүләт музее оештырды. 17 музей мөдире, шул исәптән Урал урман-техника академиясе, Мари техник университеты, Коми университетының мәгариф тарихы музее мөдире бүгенгә көндә югары уку йортлары музей-ларының эшендәге мөһим мәсьәләләр, аларның уку йор-тлары тормышындагы роле турында сөйләштеләр, Евге-ний Баратынский, Салих Сәйдәшев, Максим Горький му-зейларының экспонатлары белән таныштылар, Татар-стан Республикасының берләштерелгән дәүләт музеен-дагы «Иске музей» дигән күргәзмәдә булдылар.

Конференция эшендә Татарстан Республикасының мә-дәният министры урынбасары М.Низамиев, Казан дәүләт университеты ректоры Ю.Коноплев, профессорлар Г.Вульфсон, Е. Бусыгин һ.б. катнашты.

Бәракалла, урыс та сугыштан туйган бит!

Матбугатта хәбәр ителгәнчә, Сергей Соколов, Олег Не-вец, Сергей Малыгин дигән өч егет 5 сентябрьдә туган илләрен ташлап китә. Башта алар Ичкериядә «тәртип» урнаштырып йөрүче ротадан качкан була. Һәрхәлдә, егет-ләр француз хокемдарларына шулай дип сөйли.

Сентябрь башында егетләр Одессага килеп тошә һәм ничектер анда Неапольгә китүче йөк судносына кереп урпа-ша. Аннан Испаниягә барып эләгә болар. Барселонада егет-ләр сәяси сыену урыны сорыйлар. Ләкин аларның үтенечен шундук кире кагалар. Кайсыдыр бер акыллы башы егет-ләргә бәхетләрен Франциядә сынап карарга киңәш итә. Ә анда, документсыз тотылсаң, шундук хокем итәләр икән. Болар да Лилль шәһәрендә полиция кулына килеп кабалар.

Бәракалла, «бүленмәс Русия» дип утка кергән урыс со-лдатлары да чечен сугышыннан качып китә башлаган түге-лме соң, җәмәгать!..

Аллага шөкер, йөрәгебезгә йон үсмәгән әле

«Татарстан халыкларының мәдәни һәм табигый мирасы һәм милли мәсьәләләр комиссиясе». Дәүләт Советы даими комиссиясенең исеме иде бу. Әйтергә тел тотлыга, мәгънәсе дә аңлашылмый. Депутат-язучылар бер сессиядә бу исемне үзгәртүне яныш-көеп таләп иттеләр. Тыңламадылар. Үҗәтләнделәр. Ә менә әле генә узган дүртенче пленар сессия барысын да үз урынына куйды: хәзер ул «Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе» дип атала.

Татар милли университеты мәсьәләсендә дә шундыйрак хәл килеп чыкты. Акчасы, бинасы булмаган хәлдә дә эшләп килгән милли университетны белмәмешкә-күрмәмешкә салынып, кайбер җитәкчеләребез матбугат, телевидение аша моны әлегә кирәксез гамәл, дип чыгыш ясавы аяз көнне яшен суккандай булды, чәчләр үрә торды. Казандагы 15ләп югары уку йортында нигездә урысча укытыла, ә бер татарча югары уку йорты ачу башка милләтләрне кыерсыта, имеш. Ела да үл, дигән кебек килеп чыкмыймы бу? Юк. Дәүләтчелеген, мәдәниятен, телен, тарихын кабат торгызырга алынган халык моңа ничек килешсен. Йөрәгенә йон үсмәгән әле аның. «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Законның үтәлмәвенә борчылып, милләт өчен җан атып йөрүче депутатларның да йөрәге сызланган дыр. Сессия мөнбәреннән бу хакта депутат Разил Вәлиев ачынып сөйләде. Суверенлык турындагы Декларация кабул ителгәч, татар китабын чыгару 4 тапкыр кимегән. Телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру өчен каралган 4 миллиард сум акчаны республикада яшәүчеләргә бүлсәң, һәркемнең өлешенә тигән акчага бер дәфтәр генә алырга мөмкин. Хәзергә ул акчаның да 110 миллионы гына бирелгән. Димәк, бу акча һәркемгә бары ике бит кенә кәгазь алырга җитә.

Ниһаять, беренче нәтиҗә күренде. Иң куандырганы: Казан дәүләт университеты бинасында милли гуманитар югары уку йорты оештырырга карар кылынды. Әмма ул киләчәктә алай гына булып калмас, дигән өмет яши җанда. Чөнки татар баласының югары уку йортында барлык фәннәрне дә үз телендә өйрәнергә хокукы юкмыни?! Татар халкының телен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, тарихын тирәнтен белергә теләгән башка милләт кешеләренә дә милли университетның ишекләре ачык булыр. Безнең күңел иркен бит

Көләсең килсә, «Гөргәри кияүләре»нә бар

Камал театры драматург Туфан Миңнуллинның [Г]өргәри кияүләре» дигән музыкаль комедиясен [с]әхнәләштерде.

Елмаям, көләм дисәң, театрга рәхим ит һәм [та]нылган артистлар Наил Дунаев, Фирдәвес Хәй-[ру]ллина, Әсхәт Хисмәт, Дания Нурлы, Вера Мин-[ки]на, Нәҗибә Ихсани, яшьләрдән Илсәя һәм Рамил [Тә]хфәтулла, Искәндәр Хәйруллиннарның «Гөргәри [ки]яүләре»ндә оста итеп уйнавын кара.

Спектакльдән бер күренеш.

Ө. ШӘФИГУЛЛИН фотосы.

Дәвер кемнең дәвере? Идегәйнең дәвере

1 нче биттәге рәсемдә — Татарстанның һәм Русиянең халык артисты Ринат Таҗетдин Идегәй ролендә (Ф.Гарифуллин фоторәсеме). Ринат Таҗетдин театрның узган елгы сезонында, Камал театры артистлары арасында даими үткәрелә торган ярышта, Идегәй ролен уйнап, беренче урынны яулап алды.

Быелгы 90 нчы сезонны да театр «Идегәй» трагедиясе белән ачып җибәрде. Әлеге пьесаның авторы, драматург Юныс Сафиулланың «Тамашачы ни көтә?» дигән язмасын гәзитебезнең киләсе саннарының берсендә укый аласыз.

Ректорны да биеттеләр...

Казан дәүләт педагогия университетында мөстәкыйль татар теле һәм әдәбияты факультеты барлыкка килүен без шатланып хәбәр иткән идек инде. Ә менә 16 октябрьдә әлеге факультет I курс студентларын тәбрикләү кичәсен үткәрде. I курстан өч төркем — «Сандугач», «Сылукайлар», «Көзгә муллык» командалары үзара көч сынашты. Студентлар шактый чая булып чыкты — биючеләр конкурсында алар ректор Рүзәл әфәнде Йосыповны да биергә чакырдылар. Ректор да ялындырып тормады, шөкертләр белән рәхәтләнеп биеде, күңел ачты.

Миләүшә, рәхмәт сиңа!

Арабыздан бик иртә киткән шагыйрь, композитор Ләбиб Айтугановның 60 еллыгына багышлап, аның туган җире Әгерҗе районының Нарат авылы мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Ноябрь ахырында шундый ук кичә Казанда булачак. Тиздән Ләбиб Айтугановның шигырьләр җыентыгы да дөнья күрәчәк. Төзүчесе — шагыйрьнең кызы Миләүшә Айтуганова.

Киләсе атнада...

24 октябрьдән 26 октябрьгә кадәр Чаллыда «Өз[лексе]з педагогик белем: тәҗрибәләр, проблемалар, [персп]ективалар» дигән темага Бөтенрусия фәнни-га[мәли] конференциясе булачак.

Гармунчыларның Файзулла Туишев исемендәге [бәйгесе]нә паек булган лауреатларның «Гран-при» өчен [бәйгес]е 23 октябрьдә Казан дәүләт университетының [...]-тамаша залында уза.

[...]Г Камал исемендәге Татар дәүләт академия те[атры] тамашачыларны 26 октябрьдә мәшһүр драма[тург Х]аҗи Гыйззәтнең 100 еллыгына багышланган тан[тан]а[...]а чакыра

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында татар халкының мәшһүр җырчысы, СССРның халык артисты Азат Аббасовның тууына — 70, иҗат эшчәнлегенә 45 ел тулу уңаеннан хөрмәтләү кичәсе уздырылды.

Октябрь аенда республиканың барлык суд хезмәткәрләре «Адонис» фирмасы теккән яңа төрле эш киемнәре — мантия, эш костюмы, күлмәк һәм аяк киеме алачак. Татарстан судьясы мантиясенә. Русия вариантыннан шактый аермалы буларак, милли бизәкләр төшерелгән, кию өчен уңайлырак та. Бүгенге көнгә 600 ирләр һәм 200 хатын-кызлар костюмы әзер инде.

Казанның Совет районы хакимияте яшь укытучылар слеты үткәрде. Чөнки бу уку елында гына да районның 34 мәктәбендә йөздән артык яшь укытучы үзенең мөстәкыйль хезмәт юлын башлап җибәрде.

«Казан» милли мәдәният үзәгендә «Сәнгать, төрки халыклар традицияләре һәм хәзерге заман» дигән темага республика конференциясе булды. Биредә Татарстан дизайнерлар берлеге оештырган «Дизайн дөньясы» дигән күргәзмә ачылды.

«Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Р.Галиевнең тормыш юлы Американың биографик институты тарафыннан 28 ел дәвамында нәшер ителә торган «Дөньяның танылган биш мең эшлеклесе» дигән биографик белешмәлекнең бишенче басмасына кертелгән.

Санкт-Петербургта биология өлкәсендә фәнни тикшеренүләр алып баручы галимнәрнең халыкара симпозиумында Татарстан галимнәреннән академик И.Тарчевский, биология фәннәре докторы Ф.Кәримова һәм биология фәннәре кандидаты Е.Бунтукова фәнни докладлар белән чыгыш ясадылар.

20 гә якын китап авторы, әсәрләре Казанда гына түгел, ә Мәскәү, Нукус, Киев, Вильнюс нәшриятларында нәшер ителгән, Татарстанның һәм Русиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Мәдинә Маликованы хөрмәтләү кичәсе булды.

Чаллының «Айгөл» балалар ансамбле җырчысы Вероника Еремина, бию төркеме белән берлектә, Русия телевидениесенең 1 нче каналы буенча күрсәтелә торган «Көлбикәдә. балда» тапшыруының Яңа ел чыгарылышында өр-яңа татарча җыр башкарачак.

Татарстан Журналистлар берлегенең массакүләм мәгълүмат чараларының баш мөхәррирләре катнашында Казанда узган пленумында Татарстан Республикасында Матбугат көнен, «Татарстан Республикасының атказанган журналисты» дигән мактаулы исемен булдыру һәм башка мәсьәләләр тикшерелде.

Русия Федерациясе Хәрби фәннәр академиясе президенты, хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы, армия генералы Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев Казанга килде.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев Төркия Республикасының Гуманитар академиясе академигы итеп сайланды.

Татарстан хөкүмәтенең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, Премьер-министр Фәрит Мөхәммәтшин Антальягә (Төркия) ялга китте.

Сәхифәләрдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

«Азатлык»ка йокымсырау төс түгел

Хәтер көне алдыннан башкалада «Азатлык» татар яшьләре берлегенең YI корылтае булып үтте. Милли хәрәкәт оешмалары үткәрә торган җыен-митинглардан аермалы буларак, корылтай үткән «Казан» милли мәдәният үзәге тирәсе тыныч иде. Корылтай да шулай тыныч кына үтте. Элеккечә кызып-кызып бәхәсләшүләр, көтелмәгән фикерләр булмады, яшьләргә хас энергия, дәрт сизелмәде бу җыенда. Яшьләр янына милли хәрәкәттә билгеле шәхесләр — Марат Мөлеков, Рәшит Ягъфәров, Габделбәр Фәйзрахманов, Вафирә Гыйззәтуллина килгән иде. Һәм алар корылтай эшендә яшьләргә караганда активрак та катнаштылар. Милли хәрәкәттә яшьләр юнәлеше өчен бигрәк тә алар күбрәк борчыла дигән фикер калды. Югыйсә, киресенчә булырга тиеш түгелме соң? Корылтайга килүче делегатлар исәбеннән чыгып та «Азатлык»ның бүгенге хәле турында фикер йөртергә мөмкин. «Казан» милли мәдәният үзәге залының яртысы буш булу — анысы бер хәл, ә менә кайбер төбәклардән делегатларның бөтенләй килмәве төрле уйларга этәрә. Акча табалмаганнардыр дисезме? Ә бит делегатлар арасында Ярославльдән үк килүчеләр дә бар иде.

ТЯБ рәисе итеп Тәлгат Әхмәдишин калдырылды. Моны сайлау дип әйтергә тел әйләнми, президиумнан әйтелгән тәкъдимне зал кул күтәреп хуплады гына. Шулай ук берничә резолюция кабул ителде. Шуларның берсе — «Шәрык» клубы бинасын (хәзерге Татарстан урамы, 8 нче йорт) татар яшьләренә кайтарып бирүне сорап Казан шәһәре хакимияте башлыгына мөрәҗәгать. Әйе, «Азатлык»ның башкарган һәм ниятләгән эшләре шактый. Тик элеккеге «Азатлык» түгел инде бүгенге татар яшьләре оешмасы. Әүвәл «Азатлык» тирәсе дөрләп-кайнап тора иде. Ә хәзер, кызганыч, хәл башкачарак. Бәс, әгәр шулай икән, иртәгә татар милли хәрәкатенә дә сүрелү, сүлпәнәю куркынычы яный түгелме соң?..



Моң иҗатчысына ихлас хөрмәт

Заманыбызның мәшһүр композиторы Сара Садыйкова үзе исән чагында ук халкыбызның кабатланмас моң иясе буларак дан алды. Халык үзенең талантларын беркайчан да онытмый. Үткән атнада Казанның Татарстан урамындагы 13 нче йортта Сара Садыйковага мемориаль такта кую тантанасы булды. Анда Татарстан Җөмһүриятенең мәдәният министры урынбасары М.Низамиев, композитор исемендәге фонд рәисе Ә.Хөсәенов һәм башка күренекле кешеләр катнашты.

Зөлфәт Төркиягә җыена

Курчак театрының быелгы репертуарында 27 әсәр бар. Сезон 19 октябрьдә С.Прокофьевның «Абау, Крокодил!» дигән әсәре белән ачылды. Ноябрьдә тагын бер премьера — Туфан Миңнуллинның «Укытты бүре сабак» дигән әсәре сәхнәгә менәчәк.

Тиздән Төркиядә бөтендөнья театр эшлеклеләре берләшмәсенең II халыкара курчак театрлары фестивале булачак. Анда театр Зөлфәтнең «Ат өреккән шомлы төн» дигән әсәрен алып барырга җыена.

Казан фаҗигасеннән сабак алабызмы?

Инде хәбәр иткәнебезчә, «Казан» милли мәдәният үзәгендә «Хәтер көне»нә багышланган «Казан фаҗигасе һәм аның сабаклары» дигән темага фәнни бәхәс булып узды. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Бөтентатар «Мәгариф» бергәлеге оештырган бу җыенны галимнәр Сәлам Алишев һәм Рәшит Ягъфәров алып барды. Анда галим һәм сәясәтчеләр Фәндәс Сафиуллин, Дамир Исхаков, Марат Мөлеков, Абдулла Җәләлов, Рәүфә Уразманова, Әмир Мәхмүдов, Зәки Зәйнуллин, Раил Имамов һ.б. чыгыш ясады.

Билгеләп үтелгәнчә, республикада кайбер хокукый нигезләмәләр ясалуга карамастан, татарның дәүләтен торгызу буенча эш бармый диярлек, җөмһүрияттә татар халкына өстенлекле мөнәсәбәт юк, һәм алга таба да аның булуы күренми.

Фәнни бәхәстә катнашучылар тарафыннан кабул ителгән резолюциядә татар халкының милли азатлык көрәше тарихын өйрәнүне киңәйтү һәм аны укыту-тәрбия эшенә ныграк кертү;хөкүмәт каршында милли эшләр буенча комитет төзү; телләр турындагы законны тормышка ашыру өчен дәүләти структуралар булдыру; 15 октябрь көнен рәсми рәвештә «Хәтер көне» дип билгеләү; 1552 елда Казанны саклаучыларга һәйкәл кую кирәклеге әйтелә.

Татар-мөселман дөньясы

Бахрейнда да ислам безнең илчебез була ала

Татарстан мөфтие Габдулла хәзрәт Галиулла Бахрейн мөмләкәтендә булып кайтты. Ул анда юстиция министры һәм дин эшләре буенча җаваплы Абдулла ибн Халит белән очрашты һәм эшлекле сөйләшүләр алып барды. Сәүдә җитәкчеләре, нефть компаниясе хуҗалары һәм финанс өлкәсендәге җаваплы кешеләр белән дә очрашулар булды.

Бу сөйләшүләр ике дәүләттә яшәүче мөселманнар арасында дустанә элемтәләр оештыруда зур әһәмияткә ия. Бахрейн мөмләкәтендә дә Татарстан белән кызыксыну бар, аларның җөмһүриятебез белән хезмәттәшлек итүгә теләк-ниятләре зур икән. Инде теләкне тормышка ашырасы гына кала.

Үзеңнеке булмагач, Африкага барасың

Октябрь башында Тунисның «Әз-зәйтүн» һәм Ливиядәге Ислам университетларына Казаннан шәкертләр укырга китте. Башкаланың Кабан арты мәчете каршында югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Исхак хаҗи Лотфулла әйтүенчә, соңгы дүрт елда гына да чит илләрдәге югары дини уку йортларына 45 шәкерт җибәрелгән. Африка илләренә киткән һәм Төркиягә юл алган шәкертләр шушы мәдрәсәдә белем эстәгән. Аларны чит илләрдән килгән һәм мәдрәсә мөгаллимнәреннән торган жюри сайлап алган. Чит җирләргә гыйлем эстәргә киткән егетләребез гарәп, француз, инглиз телләрен, хокукый фән нигезләрен дә өйрәнәчәк. Безнең егетләребезне укытуга киткән чыгымнарны Ислам дәүләтләре лигасының «Хәйәтүл-лигаса» исемле җәмгыяте хәйрия үз өстенә алган. Болар барысы да әйбәт, әлбәттә. Тик безнең үзебезгә Казанда шушындый мәртәбәле дини югары уку йорты оештырырга вакыт җитмәдеме икән? Ләкин ул «үзешчән» булмасын иде. бу эштә дәүләт катнашса да, зыян итмәс, гәрчә, Ленинның декреты буенча дин дәүләттән аерылган булса да. Әнә, Мәскәү «Христос-коткаручы» храмын төзүгә акчалата ярдәм итә ич. Безнең хөкүмәт әһелләренә тагын нинди дәлил кирәк икән?

■ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре буенча бүлек мәгълүматларына караганда, республикабызда яшәүче халыклар арасында дини нигездә низаглар чыкканы юк. Узган ел Татарстанда мөселман дине тотучылар өчен 71 мәхәллә, ә носари динендәгеләргә 24 приход теркәлгән булса, быел 482 мәхәллә һәм 121 приход теркәлде. Хәзер республикабызда 4 мәдрәсә, православие динен тотучылар өчен руханилар хәзерләүче 1 дини уку йорты эшли.

■ Екатеринбургта Урал төбәгендә яшәүче татар һәм башкорт эшмәкәрләренең I конгрессы булды. Аның эшендә 50дән артык вәкил катнашты. Анда катнашучылар Татарстан белән Башкортстан икътисадын савыктыру өчен мөмкин кадәр булышлык күрсәтү турында сөйләштеләр.

Конгресс өлкәдә милли сәясәтне тамырдан үзгәртүне таләп итеп, Свердловски өлкәсе губернаторы Э.Россельгә мөрәҗәгать белән чыкты. Өлкәдә башкорт һәм татар телләрендә нәшер ителә торган гаммәви мәгълүмат чаралары бюджеттан финансланырга, шулай ук өлкәдә салына башланган мәчет төзелешенә дә дәүләт матди ярдәм күрсәтергә тиеш, диелә анда.

■ Санкт-Петербург шәһәренең җәмигъ мәчетенә дүрт метрлы алтынланган ай куелды. Мәчетнең гөмбәзе «Полиформ» берләшмәсе эшчеләре тарафыннан яшел төстәге фарфор блоклар белән тышланды.

Ярымай Чаллыда, «КамАЗ» акционерлык җәмгыятендә Петербург инженеры Шиһабетдин Янбәков сызымы буенча эшләнде.

■ Сарытау өлкәсенең Маркс шәһәрендә яңа ачылган мәдрәсәдә 20 шәкерт укый. Бирегә Согуд Гарәбстаныннан яшь мөгаллимнәр киләчәк.

■ Сарытауда Русия мөселманнары берлегенең бүлекчәсен оештыруга багышланган конференция булды. Рәис итеп бертавыштан Каюм Тугушев сайланды.

Кайгы арты кайгы...

Узган атнада Казан шәһәр хакимиятенең эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәге директоры Альберт Невскийны өеннән чыгып барганда атып үтергәннәр. 2 октябрьдә җинаятьчел дөньяда абруе зур булган эшмәкәрне теге дөньяга озатканнар иде, икенче көнне үк 34 яшьлек эшмәкәрне ишек алдында шәхси «Мерседес»ы янында чәкегәннәр. Шул ук көнне икенче бер эшлекле кешенең тәрәзәсенә атып, кунагын яралаганнар.

10 октябрьдә Казандагы Декабристлар урамындагы «Каприз» кибетенең каравылчысын үтереп, 8 миллион сумга якын акчаны кулга төшергәннәр. 11 октябрьдә Каравайдагы җинаятьчел төркем җитәкчесе «Амбал»ның башына җиткәннәр. Аңа Казанның 7 нче хастаханәсенең реанимация бүлегендә 8 тапкыр атканнар. Янында утырган хатынына да эләккән. Шул ук көнне Мәскәү энергетика институтының Казан филиалында кичке бүлектә укучы студент Марат Атнагуловның 16 урыннан чәнчеп ташланган гәүдәсенә тап булалар. Ә менә Чаллы шәһәреннән сатарга он төяп барган шоферны кыйнап, рэкетчылар аның 2 миллион сум акчасын талап алалар. Кибет директоры исә бу «чыгым»ны капларга теләми. Хатынын һәм 2 баласын туйдырырга хәленнән килмәвен аңлаган һәм хаксызлыкка түзә алмаган 33 яшьлек ир бензин сибеп үзенә ут төртә. 16 октябрьдә Казан шәһәрендәге Тельман урамындагы бер йортта Сәлимуллин яши торган фатир шартлый. Йорт хуҗасы шундук үлә.

...Һәм куанычлы хәбәр

■ *Республикабызның олы юлларында рэкетчыларның юлбасарлык итүе күпләрне шөбһәгә төшергән иде. Менә инде ул юлбасарлар үзләре Алабуга эчке эшләр бүлеге оештырган тозакка эләктеләр.*

■ *Татарстанның эчке эшләр министры милиция генерал-майоры Искәндәр Галимҗан улы Галимовка РФ Президенты фәрманы белән генерал-лейтенант дәрәҗәсе бирелде.*

«Мәдәни җомга» газите редакциясе Искәндәр әфәндене яңа хәрби дәрәҗәсе белән кайнар котлый һәм моннан соң республикабыздагы һәртөрле башбаштаклыкка, җинаятьләргә чик куелыр, дигән өметтә кала.

Татар теле нигә кирәк?

(Ахыры. Башы 2 нче битте).

Соңгы вакытта татар теленең язмышына тагын бер куркыныч яный башлады Мин татар халкының килеп чыгышы тирәсендә бәхәсләр куертуны күздә тотам Кайбер ртыграк бәхәсләр куертуны... алим-голамә бу мәсьәләгә инде нокта куясы урына. аны тагын да катлауландыру томанландыру тын карый кебек Бер ишеләре без болгардан ыккан, шуңа күрә баштагы исемебезне торгызырга ирәк. ягъни безнең халыкка болгар исемен кире айтарырга. йә булмаса татарлар арасында бүген ә болгарларның яшәвен рәсми танырга кирәк диәр һәм паспортка үзләренең милләтен болгар дип яздыручылар да күренә башлады Этнос булып формалашканчы урысларны да төрле исемнәр астында йөрткәннәр әмма бүген урыслар арасында әлеге борынгы исемнәрне паспортка яздыру гына түгел бу хакта уйлаучы да юк Безнең канкардәш төрки халыклар арасында да аларның борынгы исемнәрен кире кайтарырга теләүчеләр күренми кебек Чөнки болар барысы инде тарих. ә аны керым кешеләр теләгәнчә генә үзгәртеп булый «Болгар» исемен дә хәзер инде кире кайтару мөмкин түгел ул тарихта безнең халык йөрткән исемнәрнең берсе булып кына кала ала Бу әлбәттә һич тә безнең болгар бабаларыбыздан баш тартуны аңлатмый Чөнки этник яктан да тел мәдәният буенча да хәзерге Идел һәм Урал буе татарлары якынча X-XY гасырларда Идел һәм Чулман буйларында Бөек Болгар дәүләтен төзегән һәм яшәткән болгар халкының турыдан-туры варислары булып торалар Шуңлыктан без берничә ел элек болгар-татар дәүләтчелегенең һәм мәдәниятенең 1100 еллыгын беркемнән яшермичә билгеләп үттек Ә менә бездә халкыбызның килеп чыгышы мәсьәләсе тирәсендә тудырылган шау-шудан файдаланып. ахры быел чувашлар әлеге датаны үзләренеке итеп әверелдереп билгеләп үттеләр һәм бу хакта татар галимнәренә хәбәр итеп тә тормадылар Чөнки андый чакыру җибәрелсә безнең галимнәр чувашларның Идел буе болгарларын үзләренең бабалары итеп күрсәтергә тырышуларына берниндә дә нигез булмавын әйтерләр иде Мисал өчен академик М Зәкиев «Мирас» журналында чыгып килүче «Идел буе татарларының оешуы» дигән хезмәтендә антропологик, этнологик, тел, мәдәният, дин — барлыгы 13 позициядән карап Идел буе болгарларының һич тә чувашлар була алмавын асылда татарларга каравын исбатлый Заманында Н Ильминский белән Н.Ашмарин татарларга каршы актив файдаланылган фактны — кайбер болгар кабер ташы язуларында чуваш сүзләренең дә очравын исә галим Болгар дәүләтендә башка күп кенә этник төркемнәр белән бергә чувашларның да бер өлеше яшәвенә бәйләп аңлата Ә инде бу өлеш чувашлар болгарлашкач һәм мөселманга әверелгәч ягъни 1360 еллардан болгарларның кабер ташы язуларында да чуваш сүзләре юкка чыга Чуваш халкының төп өлеше исә борынгыдан хәзерге җирендә Идел буе болгарларыныкыннан нык аерылган иҗтимагый рухи һәм мәдәни мохиттә яши

Идел буе болгарларының турыдан-туры бабаларыбыз булуын раслау белән бергә безгә бу фактларны һич тә абсолютлаштырырга ярамый ә татар халкы, аның теле формалашуда һәм үсүдә башка компонентларның да катнашуын истә тотарга кирәк Бигрәк тә кыпчак һәм татар компонентларын әйтергә кирәк, соңгы вакытта кайбер галимнәр мәсьәләдә татар компонентына игътибарларын ирмә-бер арттырдылар һәм аның ролен артык зурайтып күрсәтәләр кебек Ачыграк әйтсәк. кайбер хезмәтләрдә каядыр YII-YIII гасырларда Азия киңлекләрендә яшәгән Төрки каганаты таркалганнан соң шул күчмә дәүләт составында булган төрки-татар кабиләләренең күпмедер өлеше көнбатышка юл ала һәм шуларның тагын кайсыдыр өлеше Идел буйларына килеп чыгып анда татар этносына һәм теленә нигез сала дигән фикер үткәрелә Монда инде әлеге татарлар безнең халык формалашуда төп этник факторга әверелдерелә ә болгарлар һәм кыпчаклар башка этник компонентлар дәрәҗәсенә төшерелә, ягъни икенчел факторга әйләндерелә Мондый гөман белән килешеп булмаса да болгар-татар этносы формалашуда әлеге факторның да роле күпмедер булуын танырга кирәк

Бер нәрсә бәхәссез халкыбызның баштан ук төрле этнослар актив аралашкан үзара тыгыз хезмәттәшлек иткән җирдә — Идел белән Чулман буйларында яшәве аның этнос һәм милләт буларак формалашуында һәм үсүендә төрле этник һәм милли факторларның катнашуына китергән Бик борынгыдан безнең ерак бабаларыбыз төрки дөнья белән бигрәк тә нык аралашканнар аның аерылгысыз өлешенә һәм мөһим үзәкләреннән берсенә әверелгәннәр Бу тарихи хакыйкатькә бүген аеруча басым ясарга кирәксы килә Чөнки соңгы вакытларда Урта Азиянең кайбер галимнәре татарларның килеп чыгышын болгар белән генә бәйләп караучылар фикеренә таянып безне урта гасырлар гомумтөрки тарихы белән мирасыннан бигрәк тә Алтын Урданыкыннан аерып ташлап, бәләкәйләштермәкче боларны үзләренеке генә итеп күрсәтмәкче булалар

Татарларның килеп чыгышы турында аңык бер фикер булмау киресенчә бу мәсьәләне башка бер яктан чишелеп булмаган бәхәс объектына әверелдерү хәвефе безнең халыкны берботен итеп карауга комачау итә, аны төрлечә таркатырга, бүлгәләргә тырышучылар файдасына эшли Бу хәл үз чиратында татар теленең яшәешенә дә кире йогынты ясый Туган телебезнең бөтенлеге югала аның аерым диалектларын яки җирле сөйләмнәрен мөстәкыйль тел итеп күрсәтергә тырышыла

Татар теленә үзебездә дә бигрәк тә рәсми даирәләрдә тиешле игътибар һәм хөрмәт булмау күпмедер дәрәҗәдә милләтлеккә өркеп яки шикләнеп карау белән дә бәйләнгән Мәгълүм ки совет заманында миллилекне коммунистик пропаганданың ата дошманына әверелдерелгән милләтчелек белән тәңгәл итеп карау аркасында партия һәм дәүләт структураларында эшләүче чиновниклар катлавы әлеге төшенчәдән уттан курыккандай курыкты һәм алар тырышлыгы белән гомумән безнең бөтен тормышыбызда миллилек мәсьәләсенә шикләнеп карау аңардан ничек тә качарга тырышу омтылышы көчәйде Табигый бу хәл миллилекнең иң мөһим күрсәткечләреннән берсе булган телгә мөнәсәбәттә дә сизелде Ягъни аңардан да төрлечә качарга тырышылды Теге яки бу киңәшмәгә яисә җыелышка берәр урыс кешесе килеп керсә әлеге әфәнденең кәефен төшермәс өчен. тизрәк урыс теленә күчү ягы каралды

Хәлбуки көнбатыш цивилизациясендә миллилек категориясе бик күптәннән берниндә шик-шөбһәсез халыкара кабул ителгән күренеш рәвешендә танылып һәм кулланылып килә Әйтик теге яки бу илнең. аның халкының һәр төрле оешмаларын «милли» төшенчәсе белән бәйләп күрсәтү гадәткә кергән Мәсәлән урта гасырлардан алдынгы Аурупа илләрендә интеллектуаль үсешне чагылдырган фәнни үзәкләр — фән академияләре төзелә башлагач аларга «милли академия» исемен бирү үзенә бер канун төсен ала Аурупадагы шундый академияләрнең иң өлкәне — Деи линчеи милли фән академиясе 1603 елда Римда төзелә Шушы традицияне дәвам итеп хәзер дә күп кенә илләрдә эре фәнни үзәкләр милли академияләр дип йөртеләләр Бүгенге көндә дөньядагы иң зур академияләрнең берсе булып АКШның Милли фәннәр академиясе тора Гомумән тормышның бик күп өлкәләрендә башка халыкларга һәм дәүләтләргә үрнәк булып торган бу ил миллилекне хөрмәт итүдә дә башкаларга үрнәк күрсәтә Гәрчә америкалылар тарихи яктан соңрак һәм дөньяның төрле төбәкләренә карый торган этник компонентлардан оешкан милләт булсалар да алар үзләренең милли горурлыгын бик югары тотулары бу сыйфатларын саклау һәм үстерү турында һәрдаим кайгыртулары белән аерылып торалар Шул сәбәпле АКШта һәртөрле дәүләти һәм хосусый оешмаларга да «милли» исемен бик теләп бирәләр икән

Безнең төрки дөньяның төп үзәкләреннән булган Төркиядә дә милли горурлык хисен тәрбияләүгә зур игътибар бирелә Бу илдә булганда анда бөтен дәүләт системасының төрекләрдә үз илең халкын белән горурлану хисен тәрбияләүгә һәм үстерүгә хезмәт итүен тоясың Безгә дә ерак Америкадан һәм якындагырак Төркиядән үрнәк алып булса да. милли горурлык турында ил җитәкчелегеннән башлап моңа кадәрге шик-шөбһәләрдән арынган хәлдә ныклап кайгырта башларга кирәк Әйтик Татарстан Фәннәр академиясенә кайбер югары уку йортлары-на Берләштерелгән дәүләт музеена сәнгать музеена үзәк спорт оешмаларына һ б ларга «милли» исемен бирү шундый кайгыртучанлыкның бер мисалы булып торсын иде Мондый исем белән бергә әлеге оешмаларның эшчәнлегендә татар теленә дә игътибар артырга һәм бу яктан алар башкаларга үрнәк булып торырга тиешләр

Татар теленә кимсетеп яки түбәнсетеп карау еш кына аның мөмкинлекләрең үсеш тарихын һәм дәрәҗәсең белмәү белән дә бәйләнгән Хәлбуки туган телебезнең мондый сыйфатлары асылда аның тарихи туу һәм яшәү җирлегенә бәйле Борынгыдан төрле халыклар тыгыз аралашкан һәм хезмәттәшлек иткән җирдә барлыкка килүе һәм яшәве сәбәпле ул элек-электән зур активлык күрсәткән һәм хәтта халыкларның аралашу теленә әйләнгән Бу хәл үз чиратында татар теленең камил телләрнең берсенә әверелүенә китергән Мисал өчен миңа заманында туган телебезнең бу сыйфатын үземә күрергә туры килде Мин М Ломоносов исемендәге Мәскәү университетында Ленин тауларында яңа мәһабәт бинасы төзелү нәтиҗәсендә ул дөнья күләмендә дан-шөһрәт казанган вакытта укыдым Әлегрәк бу шөһрәтле уку йортына йә бик зур төрләрнең балалары гына әлегә яисә бер урынга берничә дистә абитуриент дәгъва иткән конкурс аша үтеп кенә керер була иде. Миңа Татарстанның шәһәрләреннән бик читтә урнашкан авыл мәктәбен бетергән сугышның беренче айларында ук әтисез калып ялгыз әнисе белән ул вакыттагы тормышның бөтен ачысын үз башыннан кичереп үскән авыл малаена әлбәттә икенче юл «насыйп» булды Безнең группада күбрәк Мәскәү Ленинград кебек зур шәһәрләрдән мәктәптә төпле белем алган һәм зыялы гаиләләрдән чыккан студентлар җыелган иде Менә шундый элитар группада миңа татар авыл малаена латин һәм инглиз телләре әлеге әзерлекле шәһәр студентларына караганда җиңелрәк бирелә иде һәм монда мин беренче чиратта туган телемнең ярдәмен күрдем Аерым алганда татар телендә дөньядагы иң камил латин һәм инглиз телләрендәге ә ү ө в ң. һ кебек авазлар булуның ярдәме тиде Урыс телендә мондый авазларның булмавы әлеге тел вәкилләре алдында мине өстенрәк хәлгә куя иде Чит телләрне укыткан күренекле галимнәр әлеге авазларның булуын татар теленең камиллеге турында сөйләүче мөһим фактор икәнен әйтәләр иде Татар теленең тарихы грамматикасы синтаксисы фонетикасы да аның төрки телләр арасында камиллеге белән аерылып торуы турында сөйлиләр

Туган телебезнең үткәне турында сүз чыккач аның Болгар һәм Казан ханлыгы чорларында тормышның төрле-төрле өлкәләрендә файдаланылуын мисал өчен дипломатия теле хәрбиләр теле табигать һәм техник фәннәр медицина һәм фәлсәфә теле икътисад теле һ б вазифаларын башкарганын да әйтергә кирәк Ягъни ул заманнарда дәүләт теле булу нәтиҗәсендә татар теленең кулланыш җирлеге гаять киң һәм күпфункцияле булганын әйтәсе килә

Менә шундый тарихы булган татар теле 1552 елдан дәүләти статустан мәхрүм калуы аркасында безнең көннәргә ерак үткәндәге вазифаларның байтагын югалткан һәм аны куллану даирәсе соң чиктә тарайган хәлдә килде Америкада ул инде хәтта критик телләр ягъни бетүгә баручы телләр рәтендә карала башлаган диләр Нәрсә эшләргә соң?

Бу уңайдан бер фактны искә аласы килә Әш шунда Петербургтагы урыс язучылары оешмасы тәкъдиме белән Русия Дәүләт Думасында хәзер урыс телен яклау һәм саклау турында махсус закон чыгару мәсьәләсе карала һәм андый законның кабул ителәчәгенә шик була алмый әлбәттә Монда бары Русиядәге күпсанлы милли телләрне рәсми кулланыштан кысрыклап чыгарган шушы күпмилләтле дәүләттә гулысынча хакимлек иткән һәм дөньядагы иң куәтле телләр рәтендә йөртелгән бу телне яклау кирәклегенә генә беренче карашка сәер тоелырга мөмкин Ни өчен дигәндә бүгенге көндә Русиядә аңа көндәш булырлык бүтән тел юк Күрәсең биредә урыс телен Көнбатыш телләре «агрессиясеннән» саклау кирәклеге күздә тотыладыр Гомумән урыс теле үз тарихының буеннан-буена башка телләрдән күп нәрсә алып алар исәбенә баеп яшәде Аның лексик хәзинәсендә төрки-татар чыгышлы сүзләрнең аеруча зур урын тотуы күптән билгеле Кайбер галимнәр төрки-татар сүзләре әлеге хәзинәнең өчтән бер өлешен алып торулары турында да әйтәләр

Хәзер урыс зыялылары арасында туган телләрен чит йогынтыдан саклау аны милли яктан чистарту сафландыру омтылышы көчәя Урыс телен яклау һәм саклау турында закон булдырырга теләүнең нигезендә менә шушы омтылыш та ятадыр күрәсең

Инде гасырлар дәвамында Русия һәм Совет империяләрендә хакимлек иткән телне дә нәрсәдәндер яклау ихтыяҗы туган икән аның тарафыннан басып алынган һәм яшәү даирәсе соң дәрәҗәдә чикләнгән башка телләрне яклауны Ходай үзе кушкан дияргә мөмкин Мондый яклауга һәм саклауга бүгенге көндә татар теле аеруча мохтаҗ Шунлыктан бу телне яклау турындагы закон икеләтә-өчләтә кирәгрәк Урыс язучыларыннан үрнәк алып татар әдипләре аларның профессиональ оешмалары әлбәттә беренче чиратта Язучылар берлеге һәм ПЕН-үзәк туган телебезне яклау һәм саклау турында закон чыгаруны сорап Татарстан Дәүләт Советына мөрәҗәгать итәрләр бәлки Әйе татар теле язмышы турында кайгыртуны хәзер дәүләт бурычы һәм эше итеп кую зарур Чөнки бу телгә кайчан да булса барыбер Татарстанның төп дәүләт теле вазифасы йөкләнер дип ышанасы килә Бүгенге икетеллелек пәрдәсе артында бездә башка телнең үзен хуҗа итеп тотуын исә вакытлы күренеш дип карарга кирәк Татар теленә килсәк ул үз илендә хуҗа булу хокукын үзе яшәү һәм халкыбызны яшәтү өчен күп гасырлык көрәше шул көрәш дәвамында ирешкән казанышлары белән үзе яулады

Локман ЗАКИР

1. Шымчы җәлладмы, корбанмы

Бу тапшырудан соң инде давыллы дүрт ел узып киткән икән, ә ул, юк, һаман да хәтердән чыкмый. Анда элекке совет «диссиденты» В Буковский белән КГБның ул вакыттагы яңа хуҗасы В Бакатин зәңгәр экраннардан озак кына гәпләшеп утырганнар иде. Шунда Бакатин стукачларны (КГБда аларны булышчылар дип йөртәләр) тоталитар система корбаннары, дип расларга маташкач, күпләр колак артын кашып куйганнардыр,дип уйлыйм. Буковскийны өчендер әңгәмәдәшеннән: «Алай булгач, хаксызга яла ягып җәзалап үтерелгәннәр кем була инде?» — дип сорый алмады. Күрәсең, КГБның әүвәлге тоткынына КГБ хуҗасы кабинетында сөйләшеп утыру җиңел эш булмагандыр, ә, бәлки, мондый профессия кешеләре белән әңгәмәң кыскарак булса, әйбәтрәк дип уйлагандыр. Аны аңлап була: ул дулкынлана иде, тәмәке арты тәмәке кабызып утырды.

Бу мәгънәсез мәсьәләне аңлау өчен сүзне Павлик Морозовтан ук башларга кирәктер. Ул заманнарда СССРдагы кызыл галстуклы миллионнарча мәктәп балалары аңардан үрнәк алырга тиеш иде. Бу яшь каһарманның сурәтен тиражлау рәвешләре дә төрледән-төрле булып, арада иң күп санлысы һәм балаларның күңелләренә иң нык тәэсир итә торганы театр булгандыр, мөгаен. Мин үзем дә мәктәпнең драм түгәрәгендә биш еллап өлекче пионер ролен уйнап йөрдем. Сәхнәгә менгән саен, ярты капчык ашлык урлаганы өчен, мин «әти» кешене сатарга тиеш идем, ә аны һәр юлы төрмәгә алып китәләр, минә исә пионер линейкасында бөтен мәктәп алдында кызыл чүпрәктән киселгән кызыл йолдыз белән бүләклиләр иде. Бу рольне уйнаудан мин күрше апа 1 килограмм бодай өчен 10 елга төрмәгә озатылгач кына туктадым. Әлеге апабыз тәки кире әйләнеп кайта алмады. Ә аның ятим калган 17 яшьлек кызын дию пәриеннән дә кыяфәтсезрәк кырык яшьлек колхоз рәисе хатынлыкка алды. Бу адәм актыгы да коммунист иде. Ләкин эштән кайтучы колхозчыларны сагалап торып, ирләрнең кесәләрен, хатын-кызларның күлмәк асларын актарырга да күп сорамый иде.

Бу тәмуг кисәве минем диваналанып беткән пионер аңымның тәмам астын өскә китерде. Аннары инде спектакль саен мин сатып йөргән сәхнәви «әтием»нең һич тә карак булмаганлыгына да төшендем. Ул бит ашлыкны үз хезмәте өчен генә урлаган булган икән. Чөнки Сталин колхозчылары бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы бушлай яки, үзләре әйткәнчә, «таяк»ка эшләп йөрделәр ләбаса. Аннары ул аны әле мин аяк сузмасын өчен «урлаган» булган икән.

Әйдәгез, ил халкы артыннан астыртын күзәтү өчен партия һәм хөкүмәт махсус тәрбияләгән миллионнарча шымчылар турында бераз фикер йөртеп алыйк. Шымчылар бездә җитәрлек һәм аларның төгәл санын хәзергә беркем дә ачыктан-ачык кына әйтми. Ун миллионнар дип тә ишетелә. Олы яшьтәге кешенең һәр унынчысы шымчы дигән хәбәрләр дә йөри. Аларның зурраклары бар, бар кечерәкләре: партия аларны да номенклатураны калибрлагандай калибрлый килде. Шымчылар безнең белән яшиләр һәм эшлиләр. Ләкин син аны, менә шушы инде ул, дип тиз генә әйтә алмыйсың. Шулай да кемнең кем икәнен аерырдай уртак сыйфатлар да юк түгел. Мәсәлән, шымчыларның кулыннан, кагыйдә буларак, әллә нәрсә эш тә килми, ләкин еш кына аларның рәсемнәре Мактау тактасында булыр. Эштә алар зур-зур җинаять дәрәҗәсендәге хаталар җибәрәләр, әмма моның өчен аларны түгел, башкаларны җәзага тарталар, ә эштән күбесенчә аның башлыгын алып ташлыйлар. КГБның яшертен, күбесенчә аноним-телефон терәгенә таянып, алар коллективта үзләрен кыю һәм хәтта оятсыз дәрәҗәдә кыю тоталар. Зиһенлерәк хезмәттәшләре алардан ераграк торуны мәгъкульрәк күрә.

Шымчылар үзгәртеп кору, хәбәрдарлык сәясәтен башта рак астыртын гына, соңрак ачыктан-ачык хурлык тамгасы белән тамгалап чыктылар, ә августта КГБ шефы Крючковны кулга алгач, кикрикләре тагын шиңә төште. Чөнки Крючков, бер генә дәүләт тә шымчыларсыз яши алмый дип, аларны ачыктан-ачык яклап килде.

Ләкин озак та үтмәде. В Бакатин дигән яңа шефларының «Московские новости» газетендәге интервьюсын укыгач (08 09 91, № 36), алар тагын җанланып киттеләр. Архивларга шымчыларны кертеп, КГБ гамәлләренә карата гомуми ачу тудыру куркынычын истә тотып, В Бакатин болай диде: «...агентура архивларына минем каберем аша гына керә алырсыз! Мин иҗтимагый тормышка үч алу мотивларын кертергә теләмим».

КГБ башлыгы бөтен дөнья алдында шундый сүзләр әйтеп торгач, шымчыларга тагын ни кирәк! Эчләре тагын да җылынып китте боларның. Менә шулай шул: совет шымчылары — иң кагылгысыз кешеләр. Шымчы статусы халык депутаты статусыннан да дәрәҗәлерәк булып килде. Исегездәдер, ГКЧПны хуплаган күп кенә депутатларны эшләреннән алдылар, хөкемгә дә тарттылар. Ә шымчылар, табигый инде, котүләре белән фетнә ягында булдылар, алар арасыннан фетнәчеләргә каршы килгән бер генә адәмне дә таба алмыйсың.

Кыскасы, бу илдә шымчы булу мактала да, ышанычлы да, файдалы да.

Әгәр Сталин заманында, шымчылар бездә гомумән юк, дип киленсә, үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык дәверендә ул рәсми рәвештә расланды: имештер, КГБ яшерен ярдәмчеләрсез уңышлы эшли алмаячак. Ә ул ярдәмчеләр сәясәттә генә түгел, илнең икътисадына да нык йогынты ясый торган күпмиллионлы яшертен армияне төшкил иткәч, шымчыга конкретрак билгеләмә бирергәдер: кем ул — җәлладмы, әллә корбанмы?

В Буковский белән телевизион әңгәмәсендә В.Бакатин Павлик Морозов белән бер сыйныфта утырып кала язды бит әле. Күптән түгел генә ул хаксызга репрессияләнгән бабасының «эше»нә килеп юлыккан да, анда әләк авторының фамилиясе дә куелган икән. Моны сөйләгәндә В Бакатин берничә тапкыр әлеге шымчыга үч тотмавын әйтте. Минемчә, аның бу юмартлыгы төбендә мәгънәсезлек ята. Йә ул да, М.Горький кебек, бабасын бер дә яратмаган, йә аңардан бөтенләй үк баш тарткан. Андый хәлләр дә бездә аз булмады бит. Әгәр дә аның урынында патриарх Всея Руси булып, уң яңагына сукканда, сул яңагыңны да куй, дип утырса, мин аның белән, бәлки, килешер дә идем. Чөнки бу — Библиянең төп фәлсәфәләреннән берсе. Ләкин ул бит Алласыз бәндә. Минем үземнең, мәсәлән, шымчыларны җенем сөйми. Чөнки берсенең әлеге белән абыем хаксызга ун ел утырып кайтты. Кайтты да үлеп тә китте. Ә шымчысы кем булган дисезме? Әйтергә дә оят хәтта: үзен рухани дип йөри торган бер адәм актыгы шунда.

Соң нишләп безнең хак-хөкем шымчылар мәсьәләсен куймый. Шулар җәлладлар булып чыга. Ә җәлладны, хаклык таләп иткәнчә, хөкемгә тарту лазим. Шул чакта бизмән тигезләнер һәм КГБ шефын әлеге дә баягы бик сагайта торган җәмәгатьчелек нәфрәтенә дә урын калмас иде. Әгәр дә, әйтик, берәр шымчының әләге белән хаксызга берничә кеше җәзаланып, теге мәртәттән кешеләр, чын исемен әйтеп, йөз чөерәләр икән, бу бит черки тешләве белән бер.

Беләм, бөтен шымчыларны да утыртып бетерергә ГУЛАГ лагерьларында гына урын җитмәс. Ләкин аларның агентура архивларын ачып (шымчы-әләкче «эше» дәүләт сере булырга тиеш түгел), без тоталитаризмның бугазына басарбыз һәм халыкның нормаль тормышы өчен нигез булдырырбыз. Мин аларның күбесенең, тәүбәгә килеп, кеше күзенә чалынмыйча, тыныч кына гомер кичерәчәкләренә ышанам. Ә инде менә кеше алдында берәү кабәхәтнең йөзенә лач итеп төкерә икән, монда ул кадәр кот очарлык нәрсә юк. Ә гыйбрәте белән сабагы үтемле булыр иде. Ул кешеләр андый гына җәзага бик лаек — бу атып үтерү дә, унар ел каторгаларда яту да түгел. Иман турында алданрак уйлансыннар иде.

2. Юлбашчының ахирәттәге тормышы күпме тора

Хәзер, табигый ресурсларга шундый бай булган ил Ленин партиясе җитәкчелегендә һәлакәт упкыны читенә килеп җитеп, аягын селкеп утырганда, юлбашчының ахирәттәге тормышына киткән исрафларны исәпләсән дә ярый торгандыр, шаять.

Сугыш вакытында аның гәүдәсен Төмәнгә махсус поезд белән алып барып, дүрт ел буе аны саклаган табиблар һәм гаскәриләргә киткән чыгымнарны аерым хисапка алырга мөмкин булыр иде. Чөнки бу гаять яшерен операция чекистлар тарафыннан — нинди авыр көннәрдә бит — кешеләр ачтан кырылганда, яралы сугышчыларны ташырга поездлар җитмәгәндә башкарыла лабаса.

Теге дөньядагы исрафларын төгәл исәпләп чыгарганда, халыкны, бәлкем, юлбашчының гәүдәсен кабергә төшерү кирәклегенә ышандырып булыр иде. Ә моңа каршы хәзер зур шау-шулар куптаралар, хәтта мавзолейны һәм Ленин һәйкәлләрен саклау буенча махсус комитетмы, союзмы төзеп өлгергәннәр ди инде. Ленинның идеологик үлеменнән соң да аның гәүдәсен броняланган пыяла астында тотарга теләүчеләр бар икән, соң, алар мавзолейны хосусыйлаштырсыннар да, аны карап торуга китә торган чыгымнарны үз кесәләреннән чыгарсыннар. Менә шунда инде Ленинның, мине өнием янына зиратка күмегез, дигән серле васыяте бик тиз табылачагына шик калмас иде.

ШАГЫЙРЬ НЕЧКӘЛЕК БИЛГЕСЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛА

Тәңре белән сөйләшү

— Бу мизгелдә күпме җан иясе
Ялварадыр, күзен төбәп, Ходам...
Минем дә бар сиңа әйтер сүзем,
Мине дә бер колак салып тыңла...

— Мин бит беләмниләр әйтәсеңне,
Ни әйтергә кирәк түгелен дә...
Күңелең белән сөйләш, күңелең белән —
Мин туганнан бирле күңелеңдә!

Каян белдең?

Миңа бик салкын икәнен,
Миңа бик авыр икәнен
Син каян белдең?
Башта елмаеп төшемә кердең,
Аннан,
Ак канатлы фәрештәдәй,
Үзең яныма килдең.
Җылы кулларыңны бирдең,
Күзләремә карап көлдең...
Авырлыклар иңнәремнән төште —
Әйтерсең, сират күперен кичтем,
Әйтерсең, карлы котыптан
Җәннәт багларына күчтем...
Ялгыз түгел икән ич мин...
Рәхмәт сиңа, дустым!

* * *

Теләгемә өмет канат куйды,
Кошлар кебек шуңа очып йөрим.
Теләкләрем чынга ашмый калса,
Бәхетсезе булырмын мин Җирнең...

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне —
Бөркелеп лә керсен саф һава.
Күкрәк тутырып та суламагач,
Җирдә безгә тагын ни кала?

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне —
Арыныйк бер, әйдә, тузаннан.
Сусаганбыз сафлык, чисталыкка,
Безнең җаннар шуңа кузгалган!

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне,
Бер елмаеп кара Кояшка!
Болыт чыкты, диеп, тормыштан
Туялар димени бу яшьтә?!.

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне —
Ургылып ла керсен саф һава!
Күкрәк тутырып та суламагач,
Бу дөньяда тагын ни кала?!.



* * *

Карурманда киле югаласым,
Адашасым киле юлларда.
Заман шавын онытып тик беразга,
Урман шавын телим тыңларга.

Карурманда киле югаласым
Тик бер генә көнгә булса да.
Төрле яклап уйлар чага мине —
Шөпшә кебек уйлар — усаллар.

Карурманда киле югаласым,
Күбәләкләр булып уйныйсым...
Бәлки, урман әйтеп бирер иде
Ник күңелләр болай уйлы соң?

Карурманда киле югаласым,
Кошларына кушылып җырлыйсым
Әче яшьләремнән арынганчы
Үксеп-үксеп киле җылыйсым.

Карурманда киле югаласым,
Агачларын кочып йөрисем...
Диңгезләргә төшкән тамчы кебек,
Яшел дәрьясында эрисем...

Карурманда киле югаласым...

Фирая ЗЫЯТДИНОВА

Туган җирдә җаным тыныч

Туган якта битләремнән
Назлап ефәк җилләр исә.
Кошлар минем өчен сайрый,
Гөлләр минем өчен үсә.
Туган якның һавасы да
Тәнгә сихәт, җанга дәва.
Монда минем җаным тыныч —
Борчуымны җилләр ала.
Таллар — сердәш, чишмә — көйдәш,
Каеннарым — сеңелләрем.
Онытырлыкмы бер керфеге
Монда үскән сөмбелләрнең?
Монда үскән ал гөлләрнең
Керфегеннән баллар тама.
Монда минем җаным тыныч —
Борчуымны җилләр ала.

Хаклык

Хаклык эзләп, күпме кеше
Суга төшкән, утка пешкән.
Эзләгәнен табалмыйча,
Фани дөньялардан күчкән...

Бәргәләнгән, суккаланган,
Ярда яткан балык кебек.
Йолдызларга менмәк булган,
Мөналмасын белә торып.

Хаклык эзләп, башын ваткан
Җирдә күпме гали затлар.
Кояш чыккан, кояш баткан,
Алсуланып таңнар аткан...

Сулар барыбер үргә түгел,
Сулар түбән таба аккан.
Адәм углы, йөри торгач,
Әйләнгән дә үзенә кайткан.

Дөреслекне эзләгәндә
Сабый күңел, ап-ак күңел
Тапканнары — ни үкенеч! —
Хаклык түгел, хаклык түгел!

Серләре күп бу дөньяның,
Иң серлесе — хаклык уты
Серен ачкач, ние кала —
Бәлки, эзлисе дә юктыр...

Кеше булып калыйк

Бергә-бергә бер сукмактан йөрдек,
Үрләрне дә бергә-бергә мендек
Бу дөньяда шактый күпне күрдек —
Җиргә бит без сыналырга килдек.

Бергә-бергә күп хәлләргә тардык,
Арган чаклар булды, хәлдән тайдык;
Тормыш безне судан утка салды —
Бергә-бергә бер утларда яндык.
Моңарчы без сынатмадык бугай —
Моңа шаһит Кояш, йолдызлар, Ай...
Моннан соң да Кеше булып калыйк:
Ярдәмеңнән ташламачы, Ходай!

Сагыш

Яланнарда ялгыз йөрим,
Белмим ниләр кирәген...
Күңелемне моңнар сарган,
Сагыш тулы йөрәгем
Яланнарда ялгыз йөрим,
Иелəм җиркҗиләккә.
Бәлки, җиләк шифа булыр
Сагыш тулы йөрәккә?
Яланнарда ялгыз йөрим,
Тыңлыйм көккүк тавышын.
Моңлы кошның җан авазы
Арттырадыр сагышым
Яланнарда ялгыз йөрим,
Нишләтим бу сагышны?
Минем болай йөрүпәрем
Ялгышыммы, язмышмы?
Яланнарда ялгыз йөрим,
Бетәрме бу сагышлар?
Ялгышлар бер төзәтелеп,
Кушылырмы язмышлар?



АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Хәтерем ялгышмаса, 1961 елның җәе иде Без — редакция хезмәткәрләре утырган бүлмәнен (сүз «Совет мәктәбе» бүгенге «Мәгариф» журналы турында бара) ишеген җиңел генә шакып берәү керде «Сезгә бер нәрсә алып килгән идем. ул зур түгел. күз йөгертеп чыга алмассызмы?» — диде. Авторның моңа кадәр матбугатта исеме киң таралмаган кеше — Мөхәммәт Мәһдиев икәнен белдек. Озын буйлы Йөзгә-биткә чибәр кеше Тавышы да күркәм.

Язма «Сарыкны кем ашаган?» дип атала Надан бер татар теле һәм әдәбияты укытучысының «сыйнфый күзлектән» Габдулла Тукайның әсәрләренә анализ ясавы шул кадәр оста итеп тасвирлаган ки, мин дә күптән түгел үзем белән бергә эшләгән мәктәп укытучыларының кайберләрен күз алдыма китердем ..

Беркем дә очраклы рәвештә язучы. шагыйрь, драматург була алмый Әдиплек нигезендә Бөек Табигать. Ходай Тәгалә биргән талант ята.

Ләкин күренекле язучы булу өчен талант кына да җитми. тирән белем. галимлек тә кирәк Кызганыч. совет тоталитар системасы язучылардан иң элек «социалистик реализм методы» белән «сыйнфый күзлектән карап иҗат итүне» таләп итте Шуның аркасында урта кул язучылар форсаттан файдаланып. мактаулы исемнәр алдылар. лауреат булып киттеләр Мөхәммәт Мәһдиев ул заман чыбыгын шактый ашаса да. үз йөзен югалтмады. Бу юлда аңа галимлеге дә ярдәм итте

Менә шушы керештән соң төп мәсьәләгә — әдипнең «Ачы тәҗрибә» китабына тукталу урынлы булыр кебек.

Бөек Гетеның «һәр кабердә олы бер дөнья ята», дигән мәшһүр дә. бер үк вакытта моңсу да сүзләре бар. Әмма ул хаклы. Чөнки кеше гомер буена дөньяны танып белү белән мәшгуль була Кыскасы, без гомер буе тәҗрибә туплыйбыз. Француз философы М Монтень. гомерендә искә алырлык татлы мизгелләр кичергәннәре бәхетле дип санарга кирәк. дигән (шуңа күрә йөзек кашы кебек кайбер шәхесләребезнең. «Дөньяда миннән дә бәхетсез кеше юк». — дип әйтүләренә гаҗәпләнергә туры килә) Бик күп кайгы-хәсрәтләр күрсә дә. Мөхәммәт Мәһдиевне дә бәхетле дип саныйм мин. Моны әдипнең соңгы китабы да раслап тора.

«Ачы тәҗрибә» китабы 28 очерк-истәлектән тора. Алар һәммәсе дә матур, йөгерек әдәби тел белән язылган, иҗтимагый кыйммәтләре дә искиткеч югары.

Китаптагы беренче истәлек-эссе «Яңа Чүриле» дип атала. Аның беренче юллары ук, минем кебек авыл малаен. шундук әсир итә, балачакка алып кайта. Сугыштан соң да авылда тормыш искиткеч авыр иде Сталин үлгәнче халык ачлыктан интекте. Гаҗәбе шунда. халык моны нормаль хәл дип кабул итте, сугыштан соң шулай булырга тиеш. дип уйлады. Ә башка илләрдә, хәтта Германия, Япония кебек җиңелгән дәүләтләрдә дә халыкның көнкүреше безгә караганда күпкә яхшырак иде Бездә аз гына үзгәреш тә «оҗмах ишегалды» итеп күзаллалды. Инде әдипнең үзен тыңлап карыйк. «1948 елның март ае Дүрт ай элек кенә акча реформасы булды, кибетләргә чәй-шикәр. ипи, ситсы, галош кайта башлады. Авыл халкына тагын ни кирәк? Авыл халкына ни җитми? Авылда буфет ачтылар (сельполы авыл), керсәң — йа дөнья. болай да яшәп була икән, ярты телем икмәк өстенә ярты йомырка куелган, исеме — бутерброд, анысын ошатмасаң — шундый ук телем өстенә бер кисәк селедка куелган — анысының исеме дә шундый. Бер стакан кызыл аракы Керәләр, шуны әйләндереп куялар да тормышның рәтләнә баруы турында гәп коралар, «кан җылына» Кызганыч, Рәсәй империясендәге коллык психологиясе бүген дә шундый: төп һөнәре эчү дә сузылып яту. авыр тормышка күнү Дөньяда, хәтта элекке «социалистик илләрдә» дә, тормыш аз гына авырлашса, йөз меңнәрчә кеше урамга чыга, хөкүмәткә катгый таләпләр куя һәм теләгенә ирешә дә Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген Русия халкының 90 процентка якыны — хәерче. Ләкин хәерчеләр кесәдән генә йодрык күрсәтә, күбрәк Дудаевны сүгә, Лермонтовның чеченнар турындагы шигъри юлларын яттан сөйли Халыкның күбесе эшләми, шуңа күрә, тормышны яхшыртыгыз дип, хөкүмәткә дәгъва да белдерми Кем әйтмешли, кунак ашы — кара каршы...

«Пәке йөзенә яланаяк басып...» дигән истәлек тә күңелләрне тетрәндерә Бер караганда, анда язылганнар безгә шактый таныш кебек. Әмма талантлы каләм остасы фактлардан чыгып шундый нәтиҗәләр ясый ки, укыгач, тән чымырдый башлый Әйе, сугыштан соң, без университетта укыганда, «спецчасть» (КГБ-МВД бүлеге) күп студентларны чүпләде. Без белгәне генә дә — группада (16 кеше) 2 «стукач» булган Ничек Ходай саклагандыр инде, «авылда һаман тормыш рәтләнми», дип әйтүчеләрне тоннәрен алып китәләр иде бит ул чакта. Мөхәммәт Арча педучилищесында белем алганда. тарих фәнен моңа кадәр Казан ОГПУ-НКВДсында тикшерүче булып эшләгән кансыз. садист Гәрәйша Бикчәнтәев укыта .. Училищеның үзендә дә шуңа охшаган берәү табыла Ул 3 талантлы педагогның (К Ибаевның. Х Искәндәревнең, Ә Кариеваның) башына җитә Хәтерлим. безнең мәктәптә урыс теле һәм әдәбиятын укыткан Сабир абый Гыйззәтуллинны да 37 нче елда кулга алдылар Янәсе. ул үзенең дәресләрендә «бөек юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович Сталинның исемен сирәк телгә ала» икән. Ул үзе исә «Пушкин. Лермонтов. Крылов әсәрләрен әйткәндә ничек итеп бөек юлбашчының исемен еш кабатлыйм инде» — дигән. Бу сүзләр чекистларның ачуын гына кабарткан Хәер. Мөхәммәт Мәһдиевнең үз әтисе дә 37 нче еллар корбаны. Донос язучысы да читтән килмәгән. шул тирәнеке булган. Иң фаҗигалесе шунда. әлеге шымчылар үзләрен хаклы санаган, «үзебезнең совет властен дошманнардан (әлбәттә. сыйнфый дошманнардан) саклыйбыз». дип уйлаганнар. Хәер. бабасын, атасын харап иткән пионер Павлик Морозов турында шигырь-поэмалар ятлап үскән халыктан тагын ни көтәсең инде...

М.Мәһдиевнең «Европага тәрәзә тишкәндә» дигән очеркын укыганда да күңелгә «сәяси уйлар» килә. Әгәр бүгенге заман тарихчыларының фикеренә таянсак, Петр Беренченең Аурупага тәрәзә тишүе халык өчен җиңеллек түгел, һәлакәт китергән, илне хәерче иткән, йөз меңнәрчә солдат сугыш кырында ятып калган. Петр патша моңа кайгырмаган, хатыннарның корсагы зур — тагын балатабарлар әле, дип әйтергә яраткан... М.Мәһдиевнең «тәрәзәсе»нә килгәндә, әдип урыс империясенең кеше шәхесен коточкыч дәрәҗәдә бозуын күрсәтә алган... Булачак ил сакчылары, матрос бушлаты киярга җыенган яшьләр поезд белән Балтыйк буена баралар. Атна-ун көнлек юлда алар үзләренең кем икәнлекләрен күрсәтәләр: бөтен эшләре — эчү, шуның белән мактану, колхоз, совхоз бәрәңгесен урлау, яшьләрне, картларны җәберләү, талау... Автор нәтиҗә ясый: «Без — кыргый толпа». Шул «кыргый толпа» баш кондукторның фонарен (ә ул аңа бик кирәк, чөнки шунсыз поезд китми), литвалылар ресторанынннан көмеш чәнечкеләр урлый, хутордагы алмагачларны сындырып йөри — болар һәммәсе дә «булачак ил сакчыларының батырлык үрнәге». Ул хакта язучы болай ди: «Тәэсирләр алмашу китте. Кичә кем кайсы ресторанга кергән, кем күпме эчкән, кем патрульдән ничек качкан. И малайлар Без бит инде Ватан сакчылары. Без нинди, Ватаныбыз шундый инде». Бу сүзләргә нәрсәдер өстәү кирәк микән? Чөнки урыс армиясенең бөтен тарихы шулардан гыйбарәт. Гомер-гомергә урыс армиясенең төп функциясе полиция ролен уйнау, халыкларны талау, көчләү булган. Бүгенге чечен сугышы — шуның классик үрнәге. Соңгы елларда армиядә урлашу, корал сату, дедовщина кебек күренешләр нык артты. Армия — илнең көзгесе. Солдатлар, офицерлар туктаусыз эчә. Тәртипсезлек нормага әйләнеп бара...

«Остаз» очеркы гаять әһәмиятле теманы яктыртса да, мин аңа озак тукталмыйм. Чөнки китапны кулына алган һәркем бу эссе-истәлекне зур кызыксыну белән укып чыгачагына ышанам. Сүз трагик язмышлы, гаҗәеп талантлы методист-педагог, урыс теле һәм әдәбияты укытучысы Хәлим Искәндәрев турында бара. Минемчә, һәрбер урыс теле һәм әдәбияты укытучысы бу очеркны җентекләп, кулына каләм тотып укырга (татар балаларына нәтиҗәле итеп урыс телен ничек укыту алымнарына өйрәнү өчен) тиеш. Язучының осталыгы шунда, ул методик алымнар кебек «коры нәрсәне» мавыктыргыч итеп укырлык дәрәҗәгә күтәргән!

Хәлим Искәндәрев очраклы шәхес түгел, «ширпотреб кысасында» формалашмаган. Ул — коеп куйган галим-методист. Автор фикеренчә, олы хәрефтән языла торган бу Педагогның 1912-1913 елларда дөнья күргән «Белек йорты» китабының икенче кисәген бүген күчереп басканда, ул 5-8 сыйныф укучылары өчен кызыклы бер хәзинә булыр иде.

МӨБАРӘК ТӘСБИХ ӨЗЕЛСӘ...

«Узган гомер — калган хәтер» истәлеге дә югары зәвык белән язылган. Әсәрдә 70 нче еллардагы флот тормышы тасвирланса да, автор гадәти-трафарет юлдан китми Җыр сәнгатенең бөек тәрбияви көче хакында уйлана, җыр аркылы халыкның үткәне, тарихы ачыла, ди. Һәм шул фикерне үзенә хас алымнар белән йөрәккә үткәрерлек итеп дәлилли. Очерк бераз моңсу, әмма нык уйландырырлык сүзләр белән төмамлана. «Исәнме, туган ягым! Исән-сау тордыңмы? Мин бит әллә ниткән күтәренке-романтик хыяллар, куәтле җырлар патшалыгыннан кайтып киләм. Синдә яшәп, синдә үләргә, шушы җирдә күмелергә дип кайтып киләм».

«Ялта», «Пицунда» бүлекләрендәге истәлекләр укучыны мәшһүр фольклорчы, профессор Хәмит Ярми, күренекле урыс язучылары С.Маршак, М Шолохов, татар язучысы Рабит Батулла белән таныштыра, алар турында кызыклы мәгълүматлар да бирелә...

● Мөхәммәт МӘҺДИЕВ.

Мөхәммәт Мәһдиев өлкән буын татар язучыларын якыннан белә, алар белән күп тапкырлар очрашкан, табыннарда утырып гәпләшкән. Алар арасында халкыбызның затлы уллары, әдәбият классиклары Шәйхи Маннур, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан да бар. Бу өч классик турындагы очерклар шулай итеп язылган ки, әйтерсең лә, син үзең дә алар белән күптәнге таныш инде.

«Гагра» очеркында авнтор ул чорда кичергән бәхетле мизгелләрен искә ала.«Казан утлары»ның баш мөхәррире Рафаэль Мостафин белән бергә ял итүләрен яза. Бәхет, язмыш дигән нәрсә шулдыр инде, тәнкыйтьче Р.Мостафин Мөхәммәттә язучылык таланты бар икәнен сизеп ала һәм аңа эшлекле киңәшләрен бирә, миңа сөйләгәннәрегезне хикәяләр итеп языгыз, ә без аларны «Казан утлары»нда бастырырбыз, ди һәм сүзендә тора.Менә шулай, кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, дигәндәй, Рафаэль Мостафин татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертәчәк кешене — М.Мәһдиевне иҗат юлыннан китәргә өнди. Табигый, Мөхәммәт бу киңәшкә колак сала, чөнки «Рафаэльнең ул чорда татар халкы арасында дәрәҗәсе бик тә зур иде — журналның эчтәлеген, исемен яңартты... ул чорда бик кыю мәкаләләр басылып алды — Рафаэль милли геройга әйләнеп китте».

Югарыда әйтелгән бүлектә «Тарих сакалын юа» дигән гаять үзенчәлекле очерк бар. Сүз революциягә кадәрге Русиянең күренекле җәмәгать эшлеклесе В.Шульгин турында бара. Аңардан тыш, ул чакта Заграда кинорежиссер А.Каплер (Сталинның кызы Светланага гашыйк булган өчен тәмуг газапларын күргән кеше), Көньяк Африка Республикасының күренекле язучысы Алекс Ла Гума да ял итә. Очерк-истәлектә алар хакында да гаҗәеп мавыктыргыч, кызыклы итеп язылган...

Китапта Казан дәүләт университетына («Казан. Университет», «Тагын университет» очерклары) зур урын бирелгән. Бу гаҗәп түгел, чөнки Мөхәммәт нәкъ шул вузда аспирантура тәмамлый, кандидатлык диссертациясе яза һәм аны яклый. Һәм, ниһаять, 30 ел шул югары уку йортында могаллимлек итә. Казан университетын мин дә шактый яхшы беләм, Мөхәммәт телгә алган педагоглар (мәсәлән, Марианна Пахомова) миңа да таныш. Чөнки мин дә шул вузны тәмамлаган (1950) идем.

Революциягә кадәрге иң абруйлы татар уку йортларының берсе — Иж-Бубый мәдрәсәсе булган (совет чорында бу уку йорты биргән дипломны

учительский институт дипломына тиң итеп карыйлар иде...). М.Мәһдиев шул мәдрәсәнең укыту-тәрбия системасын, педагоглар эшчәнлеген күп еллар буена өйрәнә. Моның өчен без галимгә чиксез рәхмәтле булырга тиеш. Әмма татар дөньясында алай түгел шул. «Совет педагогикасы» (әйтерсең лә, педагогика фәне формацияләргә карап бәйләнә) дигән фән җитәкчелек хәрәкәтен, прогрессив уку системасын дошман күрде. Шундый фәннең башында «күренекле галим» — югары инстанциягә күтәрелгән партия чиновнигы С.Батыев торды. Ә андыйлар, әлбәттә, М.Мәһдиев кебекләргә ачык йөз күрсәтмәде генә түгел, киресенчә, адым саен аяк чалды. Боларны «Каһәрләнгән хәрәкәт, каһәрләнгән тема...» дигән эссены укыгач беләсең. Әмма М.Мәһдиев оптимист: «Килер бер көн, Әгерҗедә һәм Иж-Бубыйда Габдулла, Гобәйдулла, Мохлисә Бубыйларга мәрмәрдән һәйкәл куярлар әле», — ди ул чын күңеленнән.

Без еш кына татарларның саны 7 миллион, алар Рәсәй киңлекләренә. БДБ илләренә, хәтта бөтен дөньяга сибелгән, дип сөйләргә яратабыз. Дөресен генә әйткәндә, татар менталитетын истә тотканда (башкалар эченә кереп, тиз генә эреп бетәргә әзер торучы халык...), шатланырлык урын юк. Чөнки ул 7 миллионның иң зур күпчелеге тиздән юкка чыгачак. Бәлки, мин арттырамдыр? Кызганыч, юк шул. Урта Азиядә, Казакъстанда, Себер якларында, Ерак Көнчыгышта һ.б. төбәкләрдә 4 миллионга якын татар яши дип исәпләнә. Әмма алар өчен үз телендә уку йортлары һ.б. юк, туган әдәбияттан, мәдәнияттән дә мәхрүмнәр. Кыскасы, бүген үзен татар дип санаганнарның балалары татар булмый инде. Чөнки Мәскәү һаман да коммунистик идеология — бары тик урыс милләтен генә калдыру сәясәтен үткәрү белән мәшгуль. Татар бөтен дөньяга сибелгән, дибез, әмма алар безнең радио тапшыруларын да тыңлый алмый, чөнки кыска дулкында сөйләүче радиостанциябез юк... Халкы 6 миллион булган Финляндиядә берничә дистә мең швед яши һәм швед теле — Финляндиянең дәүләт теле. Ә безнең Татарстаныбызда татар теле дәүләт теле статусы алса да, әлегә бер тел — урыс теле генә өстенлек итә. М.Мәһдиевнең «Курган җирендә күргәннәр» дигән истәлеген укыгач, татар халкының хәле никадәр аяныч икәненә тагын бер кат инанасың... Минемчә — ә бу фикер минеке генә түгел — татарны этнос, халык итеп саклап калу өчен әлегә мөмкинлекләр бар. Татарстанда — 1 миллион 700 мең, Башкортстанда миллион ярым татар яши. Татарны әнә шул җомһүриятләрдә генә саклап калырга мөмкин. Әмма шуны ачык итеп әйтик. Башкортстанда татар милләтен һәръяклап кысу сәясәте дәүләт күләмендә алып барыла. Кечкенә бер мисал: татарлар саны әллә ни күп булмаган Ырынбур, Самарада татар урта мәктәпләре эшли, ә 400 мең татар яши торган Уфада бер татар мәктәбе дә юк (Казанда — 50дән артык). Быел бик зур авырлыклар белән Башкортстанда бер татар гимназиясе (Татарстанда 100ләп) ачылды... Без якламасак, Уфа татарын кем яклар? Сүз милләтнең яшәү-яшәмәве турында бара лабаса...

Бүген шактый халык «коммунистик үткәнне» сагына. Андыйларга Мөхәммәт Мәһдиевнең әлеге китабыннан «Viva la Commune!» очеркын укып чыгасы иде. Социализм дип аталган илдә фашизм сәясәте ачыктан-ачык үткәрелде. Ил байлыгының 80-90 проценты армия тотуга китеп барды. Бүген дә армия мескен бюджетның 40-45 процентын йотып бара.

Җыеп кына әйткәндә, Мөхәммәт Мәһдиевнең гыйнак кына итеп «Ачы тәҗрибә» дип аталган китабы совет тоталитар системасына гаепләү акты булып тора! Мәшһүр әдип, олы галим бик күп мәсьәләләрне иҗтимагый югарылыкка күтәрә алган. Моңа кадәр бездә әле андый китапның булганы юк иде...

«Ачы тәҗрибә» китабы гаҗәеп бай, халыкчан тел белән язылган. Миннән торса, мәктәпләрнең уку программаларына «Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре үрнәгендә татар теленең үзенчәлекләрен өйрәнү» дигән курс кертер идем. Мөхәммәт Мәһдиев татар теле мөмкинлекләреннән шул кадәр оста файдалана ки, әйтерсең лә, сүзләргә тылсымлы канатлар куя.

Һәм соңгысы. Мөхәммәт Мәһдиевне шәхес буларак якыннан белмәсәм дә, бу гаҗәеп талантлы һәм үзенчәлекле әдип белән замандаш булганыма горурланып, аның һәрбер яңа әсәренә, иҗат уңышларына куанып яшәдем. Табигатьнең законнары катгый: вакыты җиткәч һәркем бакыйга күчә. Мөхәммәт тә үзенең туган төбәге — Гоберчек авылы зиратында мәңгелек йокыга талган. Туган халкыбыз үзенең күренекле иҗатчысын, тылсымлы сүз иясен — Мөхәммәт Мәһдиевне һәрвакыт хәтерендә кадерләп саклар, әсәрләрен укып илһамланыр, алардан сабак-гыйбрәт алыр. Әдипнең бер хикәяте дә шулай атала бит: «Кеше китә — җыры кала...»

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.

МОСАФИР СӘФӘРДӘН КАЙТТЫ

ЧОР БУТАШТЫРА, ҖЫР — ТОТАШТЫРА...

Шушы көннәрдә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Гыйракта уздырылган YII халыкара сәнгать фестиваленнән Мактау грамотасы белән бүләкләнеп кайтып төште. Бу уңайдан безнең хәбәрчебез ансамбльнең җитәкчесе Лима КУСТАБАЕВА белән җәһәт әңгәмә корды.

— Лима ханым, Гыйрактагы фестивальнең төп үзенчәлеге нәрсәдә иде?

— Фестиваль бик зур итеп уздырылды. Бирегә дөньяның 50гә якын иленнән килгәннәр иде. Алар арасында Һиндстан, Таиланд, Иордания, Йәмән, Филиппин, Япония, Марокко кебек илләрдән, Русия төбәкләреннән һәм республикаларыннан фольклор һәм эстрада коллективлары бар иде.

Татар халкы белән гыйраклылар арасында уртаклыклар күп, безне бәйләүче җепләр нык. Динебез, борынгы язуыбыз, әлифбабыз, мәдәниятебез, тарихыбыз, гореф-гадәтләребезнең шактый өлеше гарәпләрнекенә, Көнчыгышка барып тоташа. Без Вавилонда ачык күк астындагы зур концерт залында чыгыш ясадык. Көнчыгыш халыкларының матур гадәтенчә, һәр урындыкка мендәрчекләр салып чыкканнар. Безгә чыгыш ясау өчен бер сәгать вакыт бирделәр. Сәхнәгә республикабыз флагын элеп куйдык. Концертны башлаганда да шундый ук флаг белән тамашачылар каршына килеп чыктык. Безнең концертны, биюләрне, аеруча сәхнәгә килеп чыккан мизгелне җирле телевидение аша әледән-әле күрсәтеп тордылар.

— Сезнең чыгышларга аеруча кемнәр теләктәш булды?

— Әйткәнемчә, чыгышларыбызны бик күпләр яратты. Әмма Ингушетия Республикасыннан килүчеләргә аерым тукталасым килә. Алар безгә үтә дә җылы мөнәсәбәттә булдылар, хөрмәт, ихтирам күрсәттеләр. Авыр вакытларында Татарстан эшмәкәрләре Кашаповлар күрсәткән матди ярдәм — 50 «КамАЗ» машинасына төяп алып барылган дару, ризыклар өчен ихлас рәхмәтләрен әйттеләр.

— Инде әйткәнебезчә, ансамбль чит илләргә еш чыга. Ни генә дисәң дә, чит — чит инде ул. Анда Сез нинди хисләр кичерәсез?

— Иң беренче чиратта күңелне җаваплылык хисе били, дип әйтер идем. Без бит сәнгать ярдәмендә дөньякүләм мәйданга чыгабыз. Чөнки милли сәнгатьне күрсәтү — ул халкыбызның йөзен күрсәтү. Тамашаны, милли җыр-биюләребезне ничек күрсәтүеңә карап, халыкның культура дәрәҗәсенә карап бәя бирәләр бит. Әлеге фестивальгә дә әйткәнемчә, бөтен дөньядан килгәннәр иде һәм алар безнең турыда татар халкы турында бик әйбәт фикердә калдылар кебек.

— Уңышлы сәфәрләр Сезнең үзегезгә тагын да илһамланып эшләргә бер этәргеч бит алар...

— Фестивальдә яңа дуслар табылды, бәйләнешләр дә булдырылды. Гыйнвар ае ахырында Төркиянең Истанбул шәһәрендә чыгыш ясарга чакыру алып кайттык. Без анда ике бүлектән торган зур концерт бирәчәкбез.

Аннары быелгы сезонны ноябрь аенда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында Бөек Җиңүнең 50 еллыгына багышлап әзерләнгән «Әрни әле, әрни ул яра» дигән әдәби-музыкаль композиция белән ачып җибәрәчәкбез.

Әңгәмәне
Сөембикә КАШАПОВА
оештырды

Алар безгә мәңгелектән бага...

Драматургларсыз театр яши алмый. Ә бирегә урын алган драматурглар — татар милли театрына, сәхнәсенә нигез салган, аны үстергән, яшәткән шәхесләр. Шәриф Камал, Фатих Әмирхан, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Габдрахман Ильяси, Гаяз Исхакый, Галиәсгар Камал, Нәкый Исәнбәт... Алар бүген дә безнең арада, әсәрләре белән халык, тамашачы күңелендә.

Әйе, халык үзенең бөекләрен онытмый. Ул аларны сыннарда, рәсемнәрдә, скульптураларда, һәйкәлләрдә мәңгеләштерә. Үз халкына фидакарьләрчә хезмәт иткән улларын сыннарда гәүдәләндерүче осталарыбыз да байтак. Сынчы-рәссам Фәһим Фәсхетдинов шундый күркәм егетләребезнең берсе. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры 90нчы сезонын ачып җибәргән көнне бөек татар драматургларының скульптура портретлары галереясы белән бизәлде.

Унике мәшһүребезнең скульптура портретын Фәһим Фәсхетдинов иҗат иткән.

Бу тантанада чыгыш ясаучылар күп булды. Анда гаҗәеп җылы, кайнар сүзләр әйтелде. Ә сынчы гыйнак кына итеп.

— Сезнең алда чираттагы имтиханымны тотам, рәхмәт, — диде.

— Бу эшнең ничек баруын күзәтеп, карап, белеп, кызыксынып тордым, — диде үз чыгышында театр артисты Әзһәр Шакиров. — Ул әзләнүләр, тирән өйрәнүләр, олы хезмәт нәтиҗәсендә туды. Берничә омтылыш ясалды. Менә сез күргәне — соңгысы. Хәзер театр нурланып тора. Галереядагы драматургларның скульптураларыннан рухи нур бөркелә. Фәһим милли рухны тота, яктырта, җиткерә белгән. Тукайлардан, Җәлилләрдән башланган изге эше менә бүгенге уңышка китерде, рәхмәт аңа.

Олуг актерның сүзләренә без дә кушылабыз һәм сынчы Фәһим Фәсхетдинов үзенең алдагы иҗат имтиханнарын да һәрчак шулай уңышлы тотар дигән изге теләктә калабыз.

Сәрмәдия МИНГАЛИЕВА.

● Сынчы-рәссам Фәһим Фәсхетдинов.
● Фатих Әмирхан һәм Хәй Вахитнең скульптур-портретлары.

«ЧАЛЛЫЯР — КИЛӘЧӘККӘ КАРАШ» КОНКУРСЫНА

Казан аларга «Афәрин!» диде

Күптән түгел генә Казанда Чаллы дәүләт драма театрының гастрольләре булып узды. Уңышлы гастроль азагында танылган сәнгатьчеләребез бу яшь коллектив турында үз фикерләре белән уртаклашты. Сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстанның сәнгать эшлеклесе Илтани Илялова:

— Әлеге театр белән мин моннан дүрт ел элек танышкан идем Бу юлы мин аптырап калдым каршымда яңа театр. әйтерсең лә, мин сезне беренче тапкыр күрәм Сез яхшы якка үзгәргәнсез Бу — нормаль профессиональ театр Гастрольләрегез уңай тәэсир калдырды Иң башта шуны әйтер идем актерлар уенында спектакльләрдә эчке кичереш эчке хәрәкәт бар Ләкин репертуарда сагыш. моң, кайгы күп Чаллы шәһәрендә бер генә профессиональ театр бар икән шул бер театр шәһәрнең төрле катлам тамашачыларының зәвыкын канәгатьләндерергә тиеш. дип уйлыйм Шуңа күрә репертуар төрле булырга тиеш Комедиясе дә. трагедиясе дә... Бик уңышлы булган алымнарны. детальләрне режиссер спектакльдән спектакльгә кабатлый сыман тоелды

Бу — сәхнәдә ачык күренә Әйтик яктырткыч фонарь-пистолет белән гел уйнауда да. үлем символы — ак пәрдәне еш куллануда да чагыла ул Режиссерның мондый алымнары актерлар уенының кабатлануына да китерә. Кайбер очракларда музыкаль бизәлешләрдә ярашмаганлык бар Әйтик. «Язлар моңы»нда гармун да уйный. артта фонограмма да кушыла Бу эклектика күңелдә ризасызлык уята. Актер гармунда әйбәт уйный бит нигә шуның «тере» уйнавын гына кулланмаска!

«Курку» спектакле шәп Бу спектакльдә музыка да бик уңышлы урынлы кулланыла Музыка спектакльдән аерылмый ул берботенлек хасил итә «Курку»дагы сәхнә җиһазланышында образлылык күзгә ташлана Бу башка спектакльләргә дә хас Әйтик «Күбәләк булып җаның кайтыр»да кыеш-мыеш ясалган тәрәзәләр ишекләр бу йортта яшәүчеләрнең кыек язмышы фаҗигасе турыда сөйли

Театрның эш алымнарында миңа иң ошаган әйбер — ул актерларны төрле планда файдалану Бу бик тә кирәкле нәрсә Инсаф Фәхретдин бер көнне рухы сынган сәрхушны икенче көнне бай. куәтле кансыз малтабарны уйный Рәфкать Хәмиди бер көнне сатирик образ — парторгны уйнаса. икенче көнне — драматик рольдә Актерны төрле планда уйнату — режиссерның иҗат эше актерны кабатлаулардан коткара торган процесс

Ләкин мин ризасыз калган нәрсәләр турында да әйтергә бурычлымын Иң беренче канәгатьсезлек — сөйләм культурасының аксавы. Сүзләр аңлашылмый бу бигрәк тә яшь актерларга кагыла Бу ихтимал сезнең зур залда уйнавыгыздан киләдер Сез бит авыл клубларына үзегезнең кечкенә сәхнә кечкенә залыгызга күнеккән Әмма актер үзенең нинди сәхнәдә нинди залда уйнаганын һәрвакыт истә тотып үзенең мөмкинлекләрен тәңгәл кулланырга да тиеш Сөйләм культурасына дикциягә бик нык игътибар итәргә кирәк

Сәхнәдә кайвакыт хәрәкәт юк кебек әмма эчке кичерешләр киеренке мохит бар Бу тышкы тынычлык кына Эчкә яшерелгән гайрәт бервакыт тышка бәрәчәк Бу — актерның режиссерның уртак уңышы

«Күбәләк булып җаның кайтыр» спектаклен мин моннан дүрт ел элек караган идем Әсәр үзгәргән Бу — югары дәрәҗәдәге спектакль Декорациясе дә яхшы Әсәр фәлсәфи нигезгә корылган Нурислам нигезе кем кулына кала? Ананың бер баласы үлде икенчесе асылынды өченчесен үтергәннәр Ана үләч Нурислам нигезенә кем хуҗа булыр? Бик моңсу момент Киләчәк җүләрләр кулына калачак мы? Бу гаять заманча яңгырый Спектакльдә уңышлы эшләр бик күп Сөетгәрәй — Рафил әфәнде Нурмөхәммәт — Булат әфәнде Ана — Гөлүсә ханым Искәндәр — Символ Гайнетдин ышандырып уйныйлар Аеруча Әлфия Рәхмәтуллина Илмира ролен бай . куәтле итеп башкара Миләүшә Ермакова да Рәфидәне үзенчәлекле итеп уйный

«Курку» спектаклендә куркыныч проблема алынган. Сталин дәверендәге кебек, кешеләр гел курку астында яши, кайчан үтерерләр, кайчан кочләрләр. кайчан таларлар. дип. Бу — олы эш. бик җитди актерлык уены. Спектакль берботен стильдә куелган.

Хәбәрчебезнең: «Чаллы театры турында фикерегезне бер генә җөмлә белән әйтеп бирсәгезче», — дигән үтенеченә, мәшһүр артисткабыз Гөлсем ханым Исәнгол:

— Үз культурасы ялтырап торган профессиональ театр! — диде

Драматург Юныс Сафиулла:

— Шәп театр!

Галиәсгар Камал исемендәге театр директоры Шамил әфәнде Закир:

— Зәвыклы театр!

— Бу профессиональлек ничек чагыла?

Гөлсем ханым:

— Яхшы актерларның яхшы уенында. Бу театрда мәһабәт ир-җегетләр күп. Яшь артистказарны үз артларыннан ияртә алырдай тәҗрибәле Гөлүсә ханым, Әлфия Рәхмәтуллина кебек актрисалар бар.

Юныс әфәнде:

— Режиссурада хикмәт!

Шамил әфәнде:

— Купай репертуар сайлауда!

Әңгәмәдәшләремнең өчесе дә хаклы иде: яхшы актерларсыз. яхшы режиссурасыз, һәйбәт репертуарсыз профессиональ театр яши алмас иде.

Гали Арслан, сәнгать фәннәре докторы:

— Бик кызыклы театр. Югары дәрәҗәдәге профессиональ коллектив Режиссура көчле. Сәхнә җиһазлау сәхнә бизәү эшләре — сценографиянең образлы булуы — Чаллы театрының иҗади йөзе.

Зөһрә Шакирҗан, театр музее мөдирәсе:

— Театрда зәвык сизелә Яшь театрның юл башы зәвыктан башлана икән. бу инде бик тә куанычлы күренеш Озын гомерле булсын ул театр

Равил Шәрәфи, Татарстанның халык артисты, Тукай бүләге иясе:

— Әйбәт. әйбәт. әйбәт театр!

Наил Әюп, Татарстанның халык артисты:

— Кыскача гына әйткәндә. җегетләр — молодцы!

Драматург Батулла Фаил Ибраһимның режиссерлык сәнгате һәм аерым спектакльләр турында тәфсилләбрәк сөйләде:

— Чаллы дәүләт драма театры репертуарындагы гүзәл спектакльләр турында көгазь тутырып мәкаләләр язарга булыр иде. Шулар арасында «Курку» спектакле аерым урын били. Яшь язучы Зөлфәт Хәкимнең әсәрен яшь буын режиссеры Фаил Ибраһим куйган, яшь буын актерлар уйный. сәхнәне яшь рәссам Булат Нәсих җиһазлаган Режиссерлык, актерлар уены сәхнә бизәлеше, спектакльнең музыкаль яңгырашы — бөтенесе дә тулы бер ярашканлык тәшкил итә

«Идел» журналында басылган кыйссадан Фаил Ибраһим пьеса ясаган һәм, әйтергә кирәк. «кыйссадан пьеса» оста кул белән язылган Әсәрдәге күппланлылык сәхнәдә бер мәйданга бер күренешкә тупланган.

Исеменнән күренгәнчә. әсәрнең төп каһарманы — Курку Монда барысы да курка Илдар-Булат Сәләх тә, Айгөл-Энҗе Хәйретдинова да Арнольд-Символ Гайнетдиннән курка Арнольд — хәтәр каратист, сугыш алымнарын бик яхшы белә ул. сугыш чукмары булarak кына түгел үзенең фәлсәфәсе, тормышка, кешеләргә булган мөнәсәбәте илә куркыныч Арнольд күзе төшкән һәр хатын-кызны үзенеке итә Юлына аркылы төшкәннәрне изә, сыта, җиңә һәм хатынны үзенең җенси ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тота башлый Ләкин ул да курка Хатынын кыз балаларын көчләрләр. үтерерләр дип куркып яши

Айгөл белән Илдарны көчле. кырыс (крутой) дуслары да, шәһәрнең иң данлы сугышчысы Әгъдәс тә, хәтта «надан һәм ярымисерек милиция» капитаны да коткарырга алынмый Алар да Арнольдтан курка

Бу тирән психологик әсәр татар әдәбиятында, татар театр сәнгатендә яңалык һәм тетрәндергеч яңалык.

Спектакльне иҗат итүчеләр заман темасын сәхнәгә күтәреп, каһарманлык күрсәткәннәр. Темасы бүгенге. куелышы заманча. уйнавы яңача, фикерле тамашачы өчен бу — бик зур бүләк һәм олы куаныч

Булат Нәсих әфәнде ясаган сәхнә җиһазлары катлаулы түгел. каракучкыл челтәрле дивар. шартлы ишекләр. бер диван, диварга эленгән гитара. төрле төстәге яктырткыч пампалар-рампалар. персонажлар «яшәү» өчен бик тә кулай мохит барлыкка китерә.

Зөлфәт Хәким үзе язган шигырьгә, үзе чыгарган көйләрне үзе җырлый. Җырдагы моңсулык, фәлсәфи хиссият бөтен спектакльгә тәэсир итә Бу җырлар спектакльнең музыкаль бизәлеше генә түгел, ә бәлки спектакльнең тере тукымасы, сәхнә каһарманы. Актерлар уены музыканың тәэсир көчен арттырамы әллә музыка актерларны үз артыннан ияртәме?

Бу тамашада образлар элеккеге схемалар буенча тудырылмаган. Һәр образ — катлаулы бер дөнья Аларның һәм уңай, һәм тискәре яклары бар. Кайчак аңлатып бирә алмаслык кытыршы холыклар белән хәрәкәт итеп, актерлар тамашачыны кыл өстендәге кебек киеренке халәттә тота Актерлар бу спектакльдә гадәти булмаган ситуация, гадәти булмаган уен алымнары белән очраша.

Илдар — күп кызлар күргән, барысын да (вөҗдан газабы кичермичә генә) ташлаган бер җырчы. шагыйрь. Соңгы ташлаган кызы Айгөлне дә сөйми ул. Ләкин вакыйгалар кинәт үзгәрә һәм Илдар ничәмә-ничә ирдән калган Айгөлне якын күрә, аны ярата башлый. Бу ярату аның үзенә газап, куркыныч китерә.

Айгөл — бозык кыз, хиссез генә әллә ничә ирнең сөяркәсе булганнан соң Илдарны ярата башлый. Һәм бу ярату аңа газап китерә. Аны куркыныч астына куя.

Арнольд, сөймәсә дә. Айгөлне сөяркәсе итәргә тели. Ул гади хулиган да, маньяк та түгел. Белемле, зыялы нәселдән, чибәр ир. Аның сөекле хатыны, сөекле балалары бар. Нигә кирәк булган аңа бер сөйрәлчек кыз? Ул куркаклыгы өчен кешеләрдән үч ала кебек.

Татар тамашачысы өчен монда яңалыклар байтак.

Тамашаның бөтен мохите режиссер ихтыярына буйсына.

Кочаклашу, сөешү, көчләү күренешләрендә режиссер сак кылана. Сәнгатьнең «ярамый» дигән сызыгына килеп җитә дә, туктап кала.

Әмма шулай да сугыш күренешләре Илдар тоткан агач пычакның шалтырап идәнгә төшеп китүе тамашачыны иң җитди, куркыныч урында көләргә мәҗбүр итә. Ни өчен соң тамашачының бер өлеше, бигрәк тә яшьләр, бу күренешләрне караганда шаркылдап көлеп утыра? Юкса, канга-кан, үлемгә-үлем көрәш бара Димәк. бу өлешләрне театр яңадан карап чыгарга. үзгәртергә тиеш. Җыласы урында тамашачы көлә икән, димәк, сәхнәдә пародия уйнала.

Ләкин бу вак җитешсезлекләр генә «Курку» спектакленә тискәре йогынты ясый алмый, аның сәнгати дәрәҗәсен төшерә алмый.

«Курку» — Чаллы театрының йөзе, визит карточкасы һәм коллективның горурлыгы!

Талантлы рәссам буларак, Фаил Ибраһимның киеренке иҗат итүе бу спектакльдә аеруча ачык күренә.

Олыдан кубып сөйләшерлек әнә шундый спектакльләр театр репертуарында байтак. Бу театр — теләсә нинди иҗади мәсьәләләрне хәл итәрлек көчкә ия, талантлы коллектив. Анда режиссура бар, ул — сәхнә остасы Фаил Ибраһимның ышанычлы кулларында. Анда тәҗрибәле актерлар Инсаф Фәхретдин, Символ Гайнетдин, Гөлүсә ханым, Рифкать Хәмиди, Әлфия Рәхмәтуллиналар белән беррәттән талантлы яшьләр дә иҗат итә Театрның репертуарында классика да, бүгенге әсәрләр дә, драмалар да, комедияләр дә ышанычлы урын алган. Чаллы театры Казандагы гастроле белән үзенең югары профессиональ театр икәнлеген исбат итте

Татарстан җөмһүрияте белән бер елда туган Чаллы дәүләт татар драма театрының гомере озын, киләчәге якты булсын! Амин!

АЛТАТАР.

P.S. ***Безгә мәгълүм булганча, театрның техник һәм финанс мөмкинлекләре бик фәкыйрь икән. Профессиональ театр клублар, башка һәвәскәр коллективлар дәрәҗәсендә, хәттә алардан да кайтышрак шартларда яши, иҗат итә. Өлгереп җиткән профессиональ театрны бу мөшкел хәлдән йолып алуның ике генә юлы бар. Йә театрны Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагына күчерергә кирәк, яисә Чаллы мэриясе бу театрга йөз белән борылырга, аңа аерым дикъкатьле булырга һәм тиешле финанс химаячелеге кылырга тиеш дип беләбез.***

И ТУГАН ТЕЛ...

«МӘДӘНИ ҖОМГА» ГАЗЕТАСЫНЫҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ № 3 (26)

Татар телен белүчегә ихтыяҗ бармы?

*Сәбат**

(өзек)

Бел, үтәр бу тау-болытлар,
яктырып тормыш юлың,
Алдагы көннең берендә
елмаер нур яктысы.

Заһидә БУРНАШЕВА.

*Чигенмәү.

Туры телем таш ярыр

Кайда мәктәп ачылса — анда төрмә бикләнә

Сәхифәбездә:

- Туган телне — гамәлгә! Татар теленә ихтыяҗ бармы? Сөйләшү башлыйбыз.
- Нигез мәктәптә ныгытыла. Гимназиядә — милли рух.
- Реклам дигән жанр бармы? Татар рекламы ни хәлдә?
- Сөйләмият дәресләре.
- Этимологик табышлар.
- Татар теле кабинетларына конкурс бара. Яңа хәбәрләр көтәбез.

Безнең анкета

«И туган тел...»нең элекке санында («МҖ», 29 сент.) без яңа уку елында татарча укый башлаган яшьләргә «Сез ни өчен татарча укырга карар кылдыгыз?» дигән сорау белән мөрәҗәгать итеп, кайбер җавапларны сәхифәбездә урнаштырган да идек. Ниятебез изге: һәр татар кешесе ана телен яхшы белеп, шул телдә уйлап, аралашып, тәрбияләнеп үссен, моның өчен барлык шартлар тудырылсын; татарча белем бирүнең сыйфатын күтәрү турында җитди уйланырга, чаралар күрергә вакыт җитте.

Сөенеч ки, анкетага җавап бирүчеләр мәсьәләнең бу яклары белән генә чикләнмичә, татар телен дәүләт теле буларак үстерүнең башка җитди якларына да игътибар итәләр: татар телен татарларга гына түгел, башка милләт кешеләренә дә өйрәтү, укуны югары уку йортларында дәвам иттерү мөмкинлеге, дәүләт идарәсе аппаратында ике телдә дә эш итүне җайга салу һ.б. Сүз республикабызда бүген татар теленә, дәүләт теле буларак, кондәлек ихтыяҗ тудыру турында бара. Анкеталар бастыруны дәвам иттереп без өңгәмәне күбрәк менә шушы юнәлештә алып барырга тәкъдим итәбез.

Мин бит татар баласы

Татар теле — минем туган телем. Яшьләрнең телебезне оныта баруы мине бик тә борчый. Телебезне үстерүдә, саклауда татар балаларының үзләренә зур тырышлык куярга кирәк дип саныйм. Татар журналистикасы бүлегенә шуңа да кердем.

Ләкин төп сәбәп ул гына да түгел. Мин — татар баласы. Татар теле аһәңле, сыгылмалы тел икәнен беләм. Әнә шул телнең серләренә төшенәсем килә, тагын да күбрәк беләсем килә. Туган телеңдә иҗат итү, иҗат җимешләрең белән кешеләрне куандыра, уйландыра, борчылдыра алу зур бәхет минемчә.

Йокымсыраган татар халкын уятуда бердәнбер корал — татар теле. Бик күп иҗат кешеләрен таныткан коч тә туган телләрә. Кеше үз туган телен белсә генә, башка халыкларның гореф-гадәтләрен, йолаларын, телләрен ихтирам итә ала. Димәк, кеше булып калыр очен дә туган телеңне белү кирәк.

Гөлинә ХИСАМЕТДИНОВА.

Битарафлык

Хәзер татар теленең дәрәҗәсе нык үсте, дип сөйләргә яраталар. Ләкин бит эш сүздән бик ерак тора. Халык арасында йөргән саен, татар теленә битарафлыкның бик көчле булуын аңлыйсың. Бу битарафлыкны иң башта дәүләт җитәкчеләренең салкын карашыннан күрәм.

Үзем татар авылындагы татар мәктәбен тәмамлап килсәм дә, татар телен яхшы беләм, дип әйтә алмыйм. Чөнки, авыл мәктәпләрендә белем бирү дәрәҗәсе түбән. Көз буе басуда, кыш җиткәч кенә уку башлана. Җир чыгу белән, кабат эш башлана. Шулай итеп, укырга юньләп вакыт та калмый.

Талия ХӘКИМОВА.

Мәктәпләрдә

Үз нигезе кирәк

Казан шәһәрендәге 42 нче мәктәп каршындагы (Идел буе районы) татар гимназиясе хакында моннан ике-өч ел элек күп язылды, ө соңгы вакытта игътибардан төшеп калды кебек. Әллә эшләре артка киткәнме?

Доресен әйтим, мәктәп эченә килеп кергәч, күңелне сөер бер канәгатьсезлек хисе били башлаган иде. Шөкер, икенче катның бер ягына урнашкан гимназия мәйданына барып чыккач, бу хис үзеннән-үзе таралды: тәртипне, чисталык, пөхтәлекне күреп, рәхәт булып китте. Шушы гимназияне ачу өчен бөтен көчен куйган директор Фирая Ибраһим кызы Минһаҗева һәм аның уку-укыту эшләре буенча урынбасары Асия Солтан кызы Рафикова гимназия хәлләре белән тәфсилле таныштырдылар.

Шушы тирәдә урнашкан 69, 24, 42 нче мөктәптәге укытучыларның соңгысында, татар телен белүчеләр күп булганлыктан, гимназияне биредә ачарга булганнар. Беренче елны бирегә теләге булган һәр баланы алганнар. Аларның саны 196га җиткән, ә 1993 елдан керергә теләүчеләр күбәеп киткәч, имтихан нигезендә 60ар укучы ала башлаганнар. Имтихан вакытында аеруча аларның дөрес итеп татарча сөйләшә белүләренә игътибар ителә. Анда психологлар, табиблар да катнаша.

Урыс укучылары арасында үзләрен иркен тота алмаган балаларның, бирегә килгәч, төрле яклап сәләтләре ачылып киткән. Укулары яхшы якка үзгәргән. Төрле концерт-ярышларда да осталыкларын күрсәтә башлаганнар. Чөнки моның өчен биредә шартлар бар: һәр почмактан милли рух бөркелеп тора. Укучыларның, укытучыларның ана телебездә сөйләшүләрен ишетеп җан соенә.

Гимназиядә татар телен укытуга зур әһәмият бирелә. Ул дәресләрне Земфира Хәбибрахман кызы Моханова, Равил Хәсән улы Садыйков кебек тәҗрибәле укытучылар алып бара. «Безгә татар телен яраткан балалар килә, шуңа күрә алар белән эшләве дә рәхәт», — ди Земфира ханым.

Күп җирдә дәреслекләр, кулланмалар җитмәүгә, программалар булмауга зарланалар. Ә биредә: «Дәреслекләр җитә, бездән бүтән мәктәпләр дә ала, ә программага килсәк, анысыннан да зарланмыйбыз», — диделәр.

Земфира Хәбибрахман кызы укучыларга күбрәк мөстәкыйль эшләр бирә. Дәреснең 5-10 минутын шуңа багышлый. Болай эшләгәндә, укучыларның уйлау сәләте арта. Бала эзләнә, баш вата башлый. Әнә берсе иншадан «4» ле алган. Укытучысы төзәткән хаталарны ул сүзлекләрдән карап төзәтергән. Димәк, аңа ничәле куйсалар да, барыбер түгел. Дөресен әйтергә кирәк, шәһәр балаларының бөтенесе диярлек, татар булуларына карамастан, башта урысча уйлый һәм аннан соң гына татарчага тәрҗемә итә. Биредә дә 7-8 нче сыйныф укучылары җавап бирер алдыннан уйланып торалар. Ә 5-6 сыйныфларда инде бу хәл күзәтелми. Алар башта ук татарча уйлый.

Равил әфәнде үзе бик матур итеп гармунда уйный икән. Дәресләрендә ул моны бик оста файдалана. Кирәкле урыннарда татар көйләрен уйнап күрсәтә. Шулай итеп, дәрес тагын да җанлана.

Әлбәттә, кыенлыклар да юк түгел. Өйрәнергә теләге булып та, үзләштерү сәләте түбән булган укучылар бар. Аларны яхшы укучылар белән тигезләү өчен күп көч куярга кирәк.

Шулай ук бина мәсьәләсе дә борчый. Инде класс бүлмәләре җитмәгәч, узган ел элекке 361 нче балалар бакчасы бинасын биргәннәр. Хәзер башлангыч сыйныфлар шунда укый. Ә укытучыларга исә көн буе бер бинадан икенчесенә йөгереп йөрергә туры килә.

Гимназияне ачканда яңа бина салып бирәбез дигән вәгъдәләрен хокүмәт җитәкчеләре онытканнар, ахры.

Рузилә ЗИННУРОВА.

● Земфира Моханова 6А сыйныф укучылары (сулдан уңга) Басыйров Радик, Ибатуллина Алсу, Хәмитова Айсылу белән тәнәфес вакытында.

ТАТАР ТОТЫП КАРАМЫЙЧА ЫШАНМЫЙ

яки милли рекламыбыз ни хәлдә?

Рекламның тормышыбызда көннән-көн күбрәк урын ала баруы игътибарга лаеклы факттыр. Татар аңында да ул колачын җәя килә, сөйләмендә күбрәк чагылыш таба. Сәүдә, икътисад, көнкүреш белән генә чикләнмичә, реклам сәясәткә, хәтта әхлак-тәрбия өлкәсенә дә үтеп керә. Кыскасы, татар рекламы бар, аны төрле юнәлешләрдә, хәтта фәлсәфи, психологик якларын да фәнни нигездә өйрәнү ихтыяҗы килеп туды.

Иң башта монда хәлиткеч урынны әлегә массакүләм мәгълүмат чаралары — газет-журнал, радио, телевидение тота. Реклам турында уйлау, үзара аралашу-сөйләшү һәм эш итү асылда шулар тәэсирендә гамәлгә ашырыла. Элек тә шулай булган. Татар аңында басма сүз белән реклам аерылгысыз. Беренче сәяси сүзлекләрнең берсендә (аны классик драматургыбыз, публицист һәм тәрҗемәче Галиәсгар Камал төзегән) бу төшенчә болай теркәлгән: алучыларның дикъкатен җәлеп итәр өчен нинди дә булса бер мал хакында басылып таратылган яки газетләрдә бастырылган игълан. Г.Тукай, Г.Ибраһимов һәм башка әдипләр реклам төшенчәсен нәкъ шушы мәгънәдә, нәкъ менә матбугат белән мөнәсәбәттә кулланганнар да.

Шунысын искәртеп китик: алар **реклам** дип язганнар. 30 нчы елларга чаклы фәкать шулай язылган. Шулай дөрес тә. Бу халыкара терминда а урыс теле аша кергәнгә күрә генә ияреп йөри. Урысның үзендә дә ул җиде килешнең берсендә генә әйтелә, әмма без хәзер уйлап та тормыйча барлык килешләрдә дә текрарлыйбыз. Хәлбуки **рам, фанер, гарнитур, кукуруз, конфет** кебек дистәләрчә берәмлекләрдә инде текрарлаудан туктаганбыз, һәм берни дә югалтмаганбыз. Әйдәгез, **реклам** дияргә күнегик.

Татар газет-журналлары да совет чорында реклам белән турыдан-туры шөгыльләнмәде. Соңгы елларда хәл үзгәрә башлады: бер яктан товар җитештерүчеләрнең, көнкүреш хезмәте һәм башка (сәнгать, мәдәни, юридик, медицина һ.б.) хезмәт күрсәтүчеләрнең, сәүдәгәрләр һәм кәсепчеләрнең мөстәкыйльлегенә берникадәр юл куелу, үзәктән планлаштыруның берникадәр кимүе, икенче яктан, массакүләм мәгълүмат чараларының да чагыштырмача иркенлек алуы, гомумән дә демократия, хәбәрдарлыкның борын төрткә башлавы реклам өлкәсенә дә йогынтысы ясамый калмады. Татар рекламы да хәрәкәткә килде дияргә була.

Чыннан да аны төпле өйрәнергә кирәк. Ни өчен? Иң әүвәле ул һәркайсыбызга кагыла — җитештерүчегә дә, кулланучыга да, арадашчы-сәүдәгәргә дә. Димәк ки реклам ул, фәнчәрәк әйтсәк, иҗтимагый күренеш. Шуңа күрә дә аның массакүләм мәгълүмат чаралары белән бәйләнеше дә табигый. Аннары чамалавы кыен түгел: җитештерүче һәм аның товарын алучы бар икән, ягъни сәүдә яши икән, татар моңа гамьсез кала алмый. Сәүдә аның милли аңында, канында. Риза Фәхретдин әйтмешли: «Кырмыска шикәр тәмен ничек белсә, татар да сәүдә тәмен шулай белә». Ә сәүдәне инде рекламсыз күз алдына китерү мөмкин түгел.

Рекламны өйрәнү берничә юнәлештә бара ала. Беренчесе — реклам милләтнең үзаны, гореф-гадәте белән бәйле булганга, аның тәҗрибәсен халыкның үз тарихыннан, беренче чиратта язма мирасыннан, аерым алганда матбугат өлъязмаларыннан эзләү мәслихәттер. Матбугатыбыз тарихы шул җөмләдән газет-журналларыбыз да шактый тирән өйрәнелгән булса да, кызганычка каршы, реклам тарихы әлегә дә баягы (аңа карата сыйнфый караш хөкем сөргәнгә, рекламны капиталистик, социалистик дип кагыйга каршы куеп карагангa), бер читтә кала килде.

Тәҗрибә өйрәнү гыйлем эстәүнең икенче бер юнәлеше ул — күрше-күлән эшчәнлегенә күз салу. Демократия, базар мөнәсәбәтләре нык үсеш алган илләрдә реклам бездәге кебек бер урында тормады. Алга киткән илләрдә реаль эшчәнлеге икътисад — сәүдә — базар тәртибе белән аерылгысыз бәйләнгән бу төшенчә капитал, бизнес, көндәшлек (конкуренция), маркетинг төшенчәләре белән тиң, янәшә кулланыла. Шул ук вакытта ул кешеләр аңында массакүләм коммуникация чаралары белән дә янәшә, тиң йөри. Менә шуңа күрә дә реклам саф икътисади күренеш кенә булып калмыйча, сәясәткә, идеологиягә, әхлак-тәрбиягә дә караган катлаулы үзенчәлекле бер иҗтимагый күренешкә әверелгән. Реклам аерым-аерым кешеләргә дә, җәмгыятьнең төрледән-төрле катламнарына да, тулаем бөтен халыкка да, икътисади максатларны гына күздә тотып түгел, әле әйткәнебезчә, сәяси, идеологик, хәтта дини, әхлакый максатларны да күздә тотып йогынты ясау мөмкинлеген бирә. Һәм хакимият башлыклары, иҗтимагый хәрәкәт, фирка-партияләр, дин әһелләре бу мөмкинлекләрдән көндәлек тормышта да, аеруча сайлау кампанияләре вакытында, тегенди-мондый сәяси кризислар, сугыш-низаглар килеп чыкканда бик оста файдаланалар. Хәер, өйрәнер һәм сабак алыр өчен бу үзе — әле башланмаган, тикшеренүчеләрен көткән зур бер тема.

Шулай да иң җитди, иң төпле өйрәнү мәйданы ул бүгенге татар рекламы үзе булырга тиештер. Үсеш өчен җирлек нәкъ менә үз тәҗрибәңнән — үз уңышларыңнан, үз гыйбрәт-сабакларыңнан бөртекләп җыела.

Бүгенге рекламны төрле яссылыкта өйрәнергә була. Шулай да беренче планга аның кешегә тәэсир итү үзенчәлеге чыгадыр. Рекламның укучы, тыңлаучы, тамашачыга тәэсир итүе ул — эзлекле, даими йогынтылы, катлаулы процесс. Бу тәэсир башлыча текст аркылы башкарыла. Димәк, текстның өйрәнү объекты буларак үзәк урынга чыгуы — табигый хәлдер. Ә текст ул — сөйләм оештыруның төп чарасы, төп нәтиҗәсе. Димәк, рекламны сөйләм эшчәнлегеге, сөйләм категориясе дип карау фәнни һәм гамәли эзләнү өчен перспективалы, өметле кыйбла була ала.

Бу нәрсә дигән сүз? Аралашу барышында уй-фикерне белдерү сөйләм рәвешендә гамәлгә ашырыла. Сөйләм барлыкка килсен өчен бер яктан аның сәбәп-мотивлары (иясе, адресаты, нияте-максаты, шартлы), икенче яктан, корал-чаралары, ягъни тел һәм башка (ым, ишарә, тавыш, тамга, сурәт һ.б.) чаралар булырга тиеш. Күренә ки, һәр әдәбият төрен, жанрны сөйләм төре дип, карый-анализлаган кебек рекламны да сөйләм төре дип, ягъни үзенә бер жанр төре дип карау-анализлау законлы күренеш булыр. Бу реклам текстын төзегәндә туган тел чараларын һәм телдән башка чараларны урынлы һәм тәэсирле файдалану өчен үзенә күрә бер механизм-схема була ала түгелме соң? Нәкъ шулай.

Реклам тәкъдим итү өчен аның кемгә, кайсы аудиториягә юнәлтүен яхшы белергә кирәк. Җәмәгатьчелекнең хәлен-кәефен, аерым шәхесләрнең аны кабул итү-итмәвен, аларга икътисади, социаль, этнографик факторларның тәэсирен исәпкә тоту зарур.

Безнең республика шартларында массакүләм мәгълүмат чараларына реклам материалларын әзерләгәндә аларның асылда авылда укылачагын истә тоту мөһим. Мәгълүм ки, ул адресат милли һәм психологик үзенчәлекләргә ия. Аның рекламны кабул итүе, аңа нинди реакция ясавы шәхсен үзенә генә түгел, бәлки гаиләсендә, авылында урнашкан, яшәп килгән гадәт, традицияләргә дә бәйле.

Әйтик, авыл җирендә яшәүчене реклам бирүче фирманың кычкырып торган исеме, шул ук вакытта ашык-пошык кына күрсәтелгән товары яисә үтәләчәк хезмәте һәм дә озын гына телефон номерлары исемлеге генә канәгатьләндерә алыр микән? Инде кызыксынып киткән очракта да авыл җирендә яшәүченең мөмкинлекләре чикләнгән — хәбәрнең вакыйкларын төпченергә тели икән, тиз генә номер җыеп аңлашыр өчен аның кул астында телефоны бармы соң?!

Кыскасы, авыл җирендә яшәүче кеше төпләрәк, тәфсилләрәк игълангa мохтаҗ. Игълан ителгән хезмәт күрсәтү яисә товарның ниндилеген, файдасын син аңа конкрет саннар, мисаллар белән төшендер. Бу хакта кемнән, кайда, кайчан мөрәҗәгать итеп сорашырга икәнен, хәтта кайчан, ничек килергә икәнен дә сурәтләп бир...

«Татар тотып карамыйча ышанмый» дигән халык мәкале Англиядә булган бер вакыйга гади татар авылында мөгаен кабатланмас. Анда: «Бу посьон сезне чәчегез коелудан саклап калыр һәм шәхси машиналарыгыз бензинны янга калдырырга ярдәм итәр», — дигән игълан халыкка нык тәэсир итә, кыска гына вакыт эчендә посьон күпләп сатылып та бетә. Ә татар, аеруча авыл агае, товарны алай кабаланып алырмы икән? Татарлар элек-электән оста сәүдәгәр булган, аларның сәүдә эшләрендә зур уңышларга ирешүе сабырлыктан, саксыллыктан, һәрнәрсәне бизмәнгә салып үлчәп исәпләп караудан, нәтиҗәне алдан күрә белүдән туып торган.

Тагын шунысы да бар: Ислам диненең, шәригатьнең йогынтысы сәүдә эшләрендә дә чагылыш тапкан. Коръәндә хәрәм тыела, ягъни мөселманга алыпсатарлык белән шөгыльләнгәндә товар юллау, йөртү, сату барышында нинди генә чыгымнарга дучар булса да, аның хакын алган бәясеннән ике тапкырдан арттырырга ярамаган.

Ә бит татар авылында милли һәм дини гадәтләр асылда сакланып калган, хәзерге шартларда алар яңа буын аңында да яңара. Әйтик, бүгенге рекламдагы хезмәт күрсәтүгә һәм товарларга куелган чамасыз югары бәяләрне халык кабул итә алмый. Һәрхәлдә, мондый төр адресатка шундый бәяләрнең ничек-ничек барлыкка килүен, кыйммәтчелекнең сәбәпләрен кыска һәм үтемле итеп төшендереп бирү зарур.

Милли юмор-мәзәк белән сугарылган реклам тексты һичшиксез уңышка ирешер иде. Гомумән, реклам текстын үтемле, тәэсирле формалаштыруның башка үзенчәлекле мөмкинлекләре дә аз түгел. Текстны бизәүне генә алыйк. Аны гарәп яисә иске татар язуы шрифтлары, милли, дини орнамент элементлары белән бизәп тә тәкъдим итәргә була. Шулай да ул заманча зәвыклы, милләт рухына туры килерлек тыйнак булырга, артык чуарлыкка, купшылыкка юл куелмаска тиештер.

Шунысы куанычлы: соңгы елларда татарча аталучы фирма һәм сәүдә йортлары арткан-арта бара. Аһәңле, халыкчан, яңача яңгырашлы исемнәр аз түгел: **Идел, Тасфир, Сәүдә йорты** һ.б. Шулай да вакыт-вакыт уйлап-үлчәп бетермәгән, тешкә тия торган исем-атамалар очрап куя. Мәсәлән, бертуган Кашаповларның идея-эшләре дә, рухлары да, исем-фамилияләре дә татарча, ә менә кибетләренең исеме **«Прометей»**.

Тел ул рекламда иң үтемле, иң тәэсирле чараларның берсе. Рекламда да әдәби һәм башка әсәрләрдәге кебек туган телнең барлык байлыгын, иң нечкә стиль үзенчәлекләрен дә файдаланырга мөмкин һәм кирәк тә. Дөрес, рекламда стиль үзенчәлекләренең ни дәрәҗәдә файдалану мөмкинлекләре әле өйрәнелмәгән, сыналмаган. Бу — киләчәк эше. Шулай да кайбер уңай омтылышларны да билгеләп үтү кирәктер. Әйтик, кайбер рекламнар татарның бай гына мөрәҗәгать чараларыннан уңышлы файдаланалар. Бездә гомуми мөрәҗәгать сүзләре дә (**милләттәшләр, туганнар, якташлар, мөселманнар, кардәшләр** һ.б.) рәсмилек белән бәрәттән туганлык, кардәшлек, бер-береңә якынлык, хөрмәт хисе белән сугарылган. Шулар белән мөрәҗәгать ителгән игъланнар әлбәттә үтемлерәк була.

Янә дә татарда **әби, бабай, абый, апа, сеңлем** кебек мөрәҗәгать сүзләре дә бар. Гадәти көндәлек тормышта, әйтик, трамвайда өлкәннәргә урын тәкъдим иткәндә, урысмы ул, татармы **апа** дип эндәшсәләр, ә өлкәннәр үз чиратында «Рәхмәт, **кызым** яисә **улым**» **энем** яисә **сеңлем**, дип җавап бирсәләр, нинди культуралы, күңелле, җанга рәхәт булып китә. Андый сүзләрне рекламда да кулланып була лабаса.

Реклам текстын радио, телевидениегә әзерләгәндә, язма текст үзенчәлекләренә өстәп, сөйләм үзенчәлекләрен дә, аерым алганда авазларның дөрес әйтелеше үзенчәлекләренә игътибарлы булу сорала. Дөрес сөйләшүгә, фонетик дөрес әйтелешкә, шөкер, авыл халкы бик игътибарлы, кимчелекләрне тиз тоя, аларга ризасызлык белдерә килә. Реклам текстларында татар теленә читтән кергән, аннары яңа яши башлаган — неологизм сүзләргә аеруча игътибар кирәк.

Авыл җирендәге аудитория өчен реклам материалларының тәрбияви әһәмияте дә аз түгел. Алар нәкъ шундый эчтәлекле игълан-материалларга ихтирам белән карый. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан» газете үзенең реклам битендә Саклык банкы рәисе исеменнән өндәмә хат белән мөрәҗәгать итте. Ул банкның юбилее уңаеннан үз клиентларын ихластан тәбрикли, аларга бәхет тели, гаиләләрнең матди хәлен яхшыртырга өлеш кертергә тырышуын белдерә. Рекламның төп максаты — банк күрсәтәчәк хезмәт турында ул соңыннан гына, тыйнак кына санап үтә. Әмма укучы бит нәкъ менә шундый маңгайга бәреп әйтмәгән фикерләрне хөтергә яхшырак ала. Авыл кешеләре аеруча менә шундый текстларга сизгер.

Моңарчы авыл кешесенә адресланган хәбәрләр, шул исәптән реклам игъланнары да нигездә берьяклы, рәсми, ягъни өстән күрсәтмә бирү кебегрәк кенә иде. Күпләр моңа ризасызлык белдереп килде. Рекламга да коммуникация, ягъни үзара аралашу чарасына әверелергә вакыт җитте. Әлегә моның механизмы, беренче чиратта укучы, тыңлаучы, тамашачының реакциясен белү алымнары юньләп эшләнмәгән. Бит укыган, тыңлаган, күргән мәгълүматка карата фикерне белеп тору бик мөһимдер. Һәрхәлдә, игълан да, товар җитештерүче, реклам бирүче белән аны кулланучылар арасында чын-чынлап үзара аралашу, аңлашуга, нәтиҗәле әңгәмәгә әверелә алыр иде.

Тагын бер мәсьәлә. Авыл укучысы татарча газетнең урысча тексты белән чуарлануын өнәп бетерми. Кайвакыт бит газетнең яртышар бите урысча реклам белән тутырыла. Кайбер журналларның бөтен бер тышлыгы «урысча» чекерәеп тора. Билгеле инде, редакция бай рекламчыга ярарга тырышкан, аңа телинкә тоткан. Ә газет укучы мәнфәгате?! Ул бит газет-журналга иң башта аны ана телендә укып бару, шуңардан тәм, ләззәт, рухи азык алу максатыннан язылa. Ул да акча түли, өстәвенә алдан түләп куя. Урысча уку ихтыяҗын тойса, ул урысча газет алдырыр иде.

Бу хакта әрнеп бер язган идем инде, хәл һич үзгәрми бит, кабатларга мәҗбүрмен — анам теленең шулай кимсетелүе өчен гарьлек хисе көннән-көн көчәя генә. Ни өчен һаман реклам бирүче байлар татар телен дә, урыс теле белән бердәй дәүләт теле дип танымыйлар, аның дәрәҗәсен бөтен республика алдында төшерәләр? Бу сорауга аларның юньле-башлы җавап бирүләренә берниндиы ышаныч юк. Ә менә татар журналистларының милли горурлыклары инде һич югы үзләренең укучы-мөшләре алдында җаваплылыклары кайда!?

Алда телгә алынган һәм дә әле саналып кителмәгән күп кенә мөмкинлекләрне һәм үзенчәлекләрне эшкә җиккәндә, татар рекламы да үзенең «балалык» чорын җиңел үтеп, тиз җитлегер, моңарчыгы рекламның стандартлык, рәсмилек чирләреннән котылып, аларны кабатламас, халык белән ихластан сөйләшү чарасына әверелер дип ышанып калабыз.

Илдар НИЗАМОВ,
КДУ доценты

Ничек үзеңдә ышаныч булдырып, халыкка тәэсир итәргә

Дейл КАРНЕГИ

I бүлек

Үзеңдә ышаныч һәм кыюлыкны ничек көчәйтергә

Минем алым кулланылган ораторлык сәнгате курсларын 1912 елдан бирле биш йөз меңнән күбрәк хатын-кыз һәм ир-ат тыңлаган Бу предметны ни өчен өйрәнә башлавы һәм дәресләрдән нәрсә алырга исәп тотуы турында һәрберсе язма аңлатма бирде Билгеле, һәркемнең үз фикере бар. шулай да әлеге хат авторларының омтылышы, төп ихтыяҗлары бер-берсенә бик тә охшаган «Аягүрә торып. кеше алдында сөйләргә туры килгәндә. — дип яза булачак шәкертләремнән берсе, — тартынам. дулкынланудан фикерне туплый алмыйм, ни әйтергә теләгәнемне онытам, кешеләр алдында чыгыш ясаганда, үземдә ышаныч, тынычлану һәм уйлау сәләтен булдырасым килә Клубтамы, эшмәкәрләр даирәсендәме, аудитория алдында фикеремне мантыйкый тәртиптә, ачык һәм үтемле итеп белдерергә телим». Меңләгән кешенең фикере менә шундый.

Берничә ел элек бер джентльмен (аны мистер Д У Джент дип атыйк) Филадельфиядә мин оештырган ораторлык сәнгате курсларына тыңлаучы булып язылды Күп тә үтмәде. ул мине сәнәгатчеләр клубына иртәнге чәйгә чакырды Өлкән яшьтә булса да, ул һәрвакыт янып яши. эшханәсенә җитәкчелек итә. дини оешма тормышында да дәрәҗәле урын тота, шулай ук җәмгыять эшләре белән дә шөгыльләнә Шул көнне әлеге табын әңгәмәсендә ул миңа болай диде

— Миңа берничә тапкыр төрле җыеннарда чыгыш ясарга тәкъдим иттеләр. ләкин мин булдыра алмадым дулкынлана башлыйм. башымда бер фикер калмый. шуңа күрә мин гомерем буе халык алдында чыгыш ясаудан тыелып килдем Хәзер колледж советы җитәкчесе булгач. миңа утырышларда рәис сыйфатында сүз әйтергә кирәк... Сезнеңчә ничек. мин бу яшьтә чыгыш ясарга өйрәнә аламмы?

— Сорап торасыз тагы. мистер Джент. — дим — Нинди шик булырга мөмкин! Булдырырсыз әгәр дә минем күрсәтмәләргә һәм тәкъдимнәргә таянып эш итсәгез. һичшиксез булдырырсыз

Аның миңа ышанасы да килде шул ук вакытта өмет артык җиңел аклана түгелме. дип шикләнә дә иде

— Куркам сез моны миңа кечелекле булып кына әйтәсез, — ди ул.

— Мине өметләндерергә омтыласыз.

Өйрәнү курсын тәмамлаганнан соң, без берникадәр вакытка элемтәдә булмадык, соңрак янә күрештек һәм сәнәгатчеләр клубында тагын чәй эчтек Без шул ук почмакта, таныш өстәлдә утырдык Мин теге сөйләшүне искә төшердем һәм «Чынлап та артык зур өмет күрсәтмәгәнменме?» — дип сорадым Ул кесәсеннән кызыл тышлы куен дәфтәрен чыгарып халык алдында кайчан кайда сөйләячәк исемлеген күрсәтте

— Кешеләр каршында чыгып сөйләргә сәләтле булуым шуның белән җәмгыятькә файда китерүдән канәгатьләнү алуым тормышымда иң шатлыклы вакыйга дип саныйм ..

Шушы очрашу алдыннан гына Вашингтонда коралсызландыру мәсьәләләре буенча мөһим конференция булган иде Англия Премьер-министрының шунда катнашырга җыенуын белгәч Филадельфия баптистлары аңа үз шәһәрләрендә булачак күп кешелек митингта чыгыш ясарга чакыру телеграммасы җибәргәннәр Мистер Джент әйтүенчә. шул митингта Англия Премьерын аудиториягә тәкъдим итүне шәһәрнең барлык баптистлары арасыннан аңардан үтенгәннәр

Менә шушы кеше моннан өч ел элек кенә кайчан да булса халык алдында чыгыш ясарга өйрәнә алачагына ничек каравым турында шикләнеп кенә сораган иде ләбаса

Аның чыгыш ясарга шулай тиз өйрәнүе гайре табигый хәл түгелме соң? Юк. әлбәттә Шундый ук йөзләгән мисал китерергә була Берсен генә китереп үтәм Берничә ел элек Бруклиннан табиб (доктор Кэртис дип атыйк) кышны Флоридада «Гигантлар» бейсбол командасы күнегү ясый торган мәйданчыктан ерак түгел җирдә үткәрә Команда өчен нык борчылучы буларак, ул еш кына аның күнегүләрен карарга йөргән Озакламый доктор команда белән бик дуслашып киткән һәм аны команда хөрмәтенә оештырылган бер мәҗлескә чакырганнар

Табынга кофе белән чикләвек куелганнан соң, кайбер дәрәҗәле кунаклардан берничә сүз әйтүләрен үтенәләр Менә мәҗлесне алып баручының сүзләре һич көтмәгәндә аяз көнне яңгыр кебек, аңа ява башлый.

— Бүген безнең арада табиб утыра һәм мин доктор Кэртистан бейсболчыларның сәламәтлеген саклау турында сөйләвен үтенәм

Ул мондый чыгышка әзер идеме икән? Әлбәттә әзер иде Аның бик яхшы әзерлеге бар иде ул бит гигиенаны өйрәнгән гасырның өчтән берен сәләтле табиб булып эшләгән

Кэртис. көнәфигә иркенләп утырып. әңгәмәдәше белән шул темага төне буе сөйләшеп чыга алыр иде Әмма торып басып. шуны ук хәтта кечкенә генә аудитория алдында да әйтүе аңа бөтенләй башка нәрсә иде Паралич сукты диярсең. йөрәге кага башлады. кысылып килде Ул бит тормышта беркайчан да халык алдында чыгыш ясамаган булган менә хәзер башындагы бөтен уй-фикерә челпәрәме килгән

Нишләргә? Барысы да кул чаба. барысының күзе аңарга төбәлгән Ул башын селки. ләкин моңа каршы кул чабулар көчәя генә «Доктор Кэртис! Сөйләгез инде сөйләгез!» диюләр көчлерәк. таләпчәнрәк яңгырый

Кэртис тәмам өметсез аптырашта Ул берничә җөмлә дә әйтә алмасын белә Шуңа күрә торып баса да бер сүз әйтмичә бик каушаган һәм кимсенгән хәлдә чыгып китә

Бруклинга кайтуга ук анын минем ораторлык сәнгате курсларына язылуы бер дә гаҗәп түгел Кеше алдында тагын да кызарырга. телсез калырга ул һич тә теләми иде

Ул укытучысын сокландыра торган укучыга әверелде Эшкә ифрат җитди карады чөнки чыгыш ясарга өйрәнү теләге бик көчле иде аңарда Чыгышларга ныклап әзерләнә күнегүләрне бөтен көчен салып үти бер дәресне дә калдырмый иде Нәтиҗә дә шундый укучыларга тиң дәрәҗәдә булды уңышының тиз килүенә иң олы хыялыннан да артыграк булуына ул үзе дә аптырады

Берничә дәрестән сон ук анын борчылу дулкынланулары кимеде. үз-үзенә ышанычы үскәннән үсә барды Ике ай эчендә доктор үз төркемендә иң шәп ораторларның берсе иде инде Тиздән ул башка җирләрдә чыгыш ясарга чакырулар ала башлады Башкаларның игътибары хөрмәте аңарда горурлык хисе тудыра. шулай итеп дусларының да ишәюе куаныч бирә иде

Республика партиясенең Нью-Йорктагы сайлау алды комитетының бер әгъзасы доктор Кэртисның халык алдында чыгыш ясавын ишетеп аны үз партиясе өчен үгетләп шәһәрдә чыгышлар ясарга чакыра Бу ораторның бер ел гына элек мәҗлестә аудитория алдында каушаудан телсез калып, оялып чыгып китәргә мәҗбүр булганын ишетсә әлеге сәяси эшлеклебез ничек кенә гаҗәпләнмәс иде!

Кешеләр алдында чыгыш ясау өчен үзеңдә кыюлык һәм ышаныч хисен, тыныч һәм ачык итеп сөйләү сәләтен булдыру бик күпләр күз алдына китергән авырлыкның уннан берен дә тәшкил итми Бу — аерым атаклы шәхесләргә генә Хак Тәгалә тарафыннан бирелә торган талант түгел Бу — гольф уйный белү кебегрәк Теләгә бик көчле булган һәр кеше үзенең эчке сәләт. мөмкинлекләрен моңа җигә үстерә ала

Аудитория алдында баскан килеш фикер йөртү утырган көе фикерләүдән начаррак дияргә нигез бармыни? Мондый нигез юклыгын сез. әлбәттә беләсез Асылда, кешеләргә мөрәҗәгать иткәндә сез яхшырак фикерләргә тиешсез кебек Тыңлаучыларның булуы сезне «кабызып җибәрергә» дәртләндерергә тиеш Аудиториянең канатландырып җибәрергә зиһенне ачыграк. интенсиврак эшләргә мәҗбүр итүче көч булуын сезгә бик күп оратор әйтер Андый вакытта, вәгазьче Генри Уорд Бичер әйткәнчә аларның башына моңарчы килмәгән фикер. факт уйлар «әллә кайдан гына очып килә дә төшә». шуларны тотып алырга да халыкка җиткерергә генә кала Сез дә моңа ирешә аласыз Өзлексез күнегүләр үткәргәндә сез дә мөгаен моңа ирешерсез

Сезгә генә шулай бик авыр дип уйламагыз Үз чорының иң оста телмәрчеләре дә башта шундый артык куркудан һәм тартынудан җәфаланган

Сугышларда чыныккан ветеран сәяси эшлекле Уильям Дженнинс Брайан беренче чыгышлары вакытында да тез буыннары калтыравын яшермичә искә төшерә иде

Марк Твен да беренче тапкыр лекция укырга кафедра артына баскач. авызына мамык тулган кебек тойган. ә пульсы кубок өчен ярышкандагы кебек сикергән

Виксбергны алган һәм үз заманының ин бөек армияләреннән берсен җиңүгә алып килгән генерал Грант халык алдында сүз әйтергә кирәк булгач югалып кала. үзе әйтмешли. башы миңгерәүләнгән кебек хәл кичерә

Үз чорының иң атаклы сәясәтче ораторы француз Жан Жорес беренче чыгышын ясарга җөрьәт иткәнче бер ел дәвамында депутат палатасында авызыннан бер сүз дә чыгармыйча утыра.

«Беренче тапкыр халык алдында чыгыш ясарга омтылып караганда, — ди Лойд Джорж. — мин коточкыч хәлдә идем Телем аңкауга ябышкан иде башта бер сүз дә әйтә алмыйча тордым»

Күренекле дәүләт эшлеклесе Джон Брайт АКШта гражданнар сугышы вакытында юнионистлар ягында тора, колларны азат итүне таләп итеп крестьяннар алдында беренче чыгышын ясарга карар итә Шунда барганда ул, сөйли алырмынмы дип бик дулкынлана. әгәр сөйләгәндә дә шулай дулкынлансам. син кул чабып. мине дәртләндереп җибәр. дип. иптәшен кисәтеп куя

Күренекле ирланд сәяхәтчесе Чарлз Стюарт Парнелл беренче чыгышлары вакытында артык дулкынланудан ир туганының әйтүенә караганда, йодрыгын шундый каты кыса торган булган. хәтта тырнаклары батып, учыннан кан чыга икән

Дизраэли депутатлар палатасында беренче мәртәбә чыгыш ясау аңа кавалерия полкын һөҗүмгә алып барудан да кыенрак булды, дигән Аның беренче чыгышы барып чыкмаган Шеридан белән дә шулай булган

Күпчелек инглиз ораторлары шулай уңышсыз башлаганга күрә. хәзер парламентта яшь ораторның беренче чыгышы артык уңышлы килеп чыкса. моны бик яхшыга юрамыйлар Димәк. күңелегезне төшермәгез!

Бик күп ораторларның эшчәнлеген игътибар белән күзәтүче аларның үсешенә күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаучы буларак. мин үзем әгәр шәкертем башта беркадәр дулкынлана. нерв ярсынуы кичерә икән. моңа һәрчак куанам гына

Кешеләр алдында сүз тоту хәтта ул ике дистә генә ир-ат һәм хатын-кыздан торган көндәлек эшкә бәйле бер утырышта гына булса да, бик җаваплы эш чөнки ул барыбер күпмедер киеренкелек. борчулы кичереш күпмедер дулкынлау белән бәйле Оратор тәртәгә кергән йөк аты кебек киеренкелек кичерергә тиеш Үлемсез Цицерон моннан ике мең ел элек үк инде теләсә нинди яхшы чыгыш дулкынланып сөйләнергә тиеш дигән

Телмәрчеләр гадәттә радиодан чыгыш ясар алдыннан була торган хис кичерә Мондый халәт «микрофоннан курку» дип атала Чарли Чаплинның радиодан сөйләячәк чыгышлары һәрчак алдан әзерләнә торган булган 1912 елда ук әле ул «Мюзик-холлда кичә» дигән водевиле белән бөтен илне йөреп чыга Ә аңарчы Англиянең профессиональ театрында уйный Шулай да Чаплин диварлары йомшак материалдан эшләнгән бүлмәгә килеп кереп. микрофонны күргәч бервакыт февраль давылларында Атлантиканы кичеп чыкканда ашказаны бик каты борчыгандагы кебек хис кичерә башлый

Күренекле кино актеры һәм режиссеры Джеймс Керквуд та шундый ук халәт кичергән Театрда ул төп рольләрне уйный ә менә радио студиясеннән бөтенләй күренмәгән аудитория алдында чыгыш ясаганда. маңгаеннан тирен сөртеп-сөртеп ала «Моның белән чагыштырганда Бродвейда премьера берни тормый» — ди ул.

Күпләр ничаклы гына еш чыгыш ясарга туры килмәсен барыбер башта уңайсызлану кичерәләр әмма башлап җибәреп. берничә секунд үтүгә үк бу халәттән котылалар

Хәтта Линкольн да чыгышының башында дулкынлана торган булган «Сүзен башлаганда ул үзен ипсез хис итә иде — дип искә ала анын адвокатлык эшенә караган компаньоны Герндон — Моңа ул бик авырлык белән күнегә кебек иде Берникадәр вакыт ул оялуын дулкынлануын җиңәргә маташып карый тик бу аның уңайсызлануын көчәйтә генә Мин аның мондый халәтенә еш юлыгып андый чакта мистер Линкольнның хәленә керергә тырыша идем Сөйли башлаганда тавышы артык көчле киеренке күнелгә ятышсыз була иде Үз үзен тотышы җыерчыклы ябык караңгы чырае сәер ышанычсыз хәрәкәтләре дә аның файдасына түгел иде Тик мондый тәэсир бик кыска вакытка гына булып ала иде Берничә минуттан инде аңа үз үзенә ышаныч табигый самимилеге җылылыгы игътибары кире кайта иде дә аның чын сөйләме башлана иде»

— Бәлки. сезгә дә менә шундый халәт кичерергә туры килер

— Яхшы оратор булу теләгегез тормышка тизрәк. уңышлырак ашсын өчен сезгә дүрт кагыйдәне үтәргә кирәк булачак

(Дәвамы бар).

Этимологик табышлар

ДАВЫЛ ҺӘМ ДАВЫЛБАЗ

Этимологиясе гаҗәп кызыклы фикерләр уята торган сүзләрнең берсе — **давыл**. Татар, башкорт һәм башка күрше вә кардәш телләрдә бу сүз бик тә көчле җилне һәм шуңа охшашлы күренешләрне белдерсә гагаузча **даул**, уйгурча **давул** «зур хәрби барабан». Гомумән, барча төрки телләрдә очрый торган бу сүзне гарәпчә **табл** (иске татарча да **табыл**) «барабан» сүзеннән килә дип карыйлар. Гарәпчә **табл** исә борынгы-борынгы шумер һәм аккад телләрендәге **таббалу** «хәрби барабан» сүзеннән килә. Ләкин, икенче яктан, төрки телләрнең үзендә ясалган **дагавул, даңавул, таңавул** «шау-шу, дуылдау, дупłау» сүзе дә бар һәм **давыл** сүзе шуннан да бик ансат килеп чыга ала.

Иң кызыгы шул ки, шумер телендәге **таббалу** үзе төрки **даңгавыл** белән бердәй булуы ихтимал.

Давыл, борынгыча **табыл** сүзеннән үзгәреп, **табыш** (борынгыча **табыш**) сүзе дә килеп чыккан дип уйлыйлар.

Гарәпчә **табл** яңгырашына бик күп фарсы-иран төрки һәм бүтән (Кавказ һ.б.) телләрдә очрый торган **даб, таб, дәб, тәб,** татарча (Себердә) **тип** «уен барабаны, төңгер» сүзе кайтып калса кирәк (ягъни **табл** сүзенең азагы — л авазы югалтылган булып чыга). Кайбер телләрдә ул азаккы -л закончалыклы рәвештә -р авазына әверелгән, шуннан фарсыча **табыр, тапра,** карачай-балкар телендәге **давыр,** удмуртча **дабыль, дабыр, дабур** «шау-шу, ызгыш-талаш» сүзе дә килеп чыккан.

Иске әдәби телебездә, бүтән бик күп телләрдәге кебек, фарсы телендә ясалмыш **давылбаз** «хәрби барабан, хәрби-гаскәри барабанчы, ялкынлы оран (лозунг) ясисә сөрән салучы» сүзе кулланылган (мәсәлән, Ленин — революциянең давылбазы, дип әйтелгән).

Безнеңчә, бу **давылбаз** сүзе бик колоритлы, эмоциональ сүз буларак, бүген дә игътибарга лаеклы. Әйтик, «ярык барабан» мәгънәсендә.

ДӘВЕТ ҺӘМ ДӘҮГАТЬ

Миңа **кара савыты** дигән сүз ничектер гарип, зәгыйфь, мәдәниятсез сүз кебек тоела. Хәзер инде элекке кебек бидәрле, иясенең кемлеген белдереп торган «прибор» кара савытлары юк — шарчыклы каләм белән язабыз. Шулай да гади «перо» белән язу да бетмәгән. Димәк, кара савыты да.

Әйберне, шәйне ике сүз белән белдерү — үсешмәгәнлек галәмәте. Татар халкы мәдәни үсеш ягыннан шактый алдынгылардан булып килгән. Нишләп бездә «кара савыты» мәгънәсе бер сүз белән генә белдерелмәсен, ди? Бар андый сүз: татарлар яшәгән төрле урыннарда **дәвет, дәвәт** «кара савыты». Шуның белән янәшә **дәвәт, дәүгать** — «ирләр уң иңбаштан сул янга, хатыннар сул иңбаштан уң янга төшереп кия торган киң тасма — туйда йомышлы кеше булу билгесе» сүзе дә бар. Бу мәгънәләр — «кара савыты» һәм «киң тасма» ничек үзара бәйләнә соң?

Шәрык телләренең иске сүзлекләрендә бу сүзләр топтә бердәй дип аңлатыла. Элекке озын гасырларда уңнан сулга чапрыш килгән тасмага хансарай хадимнәре кара савыты, дарулар һ.б. асып йөрткәннәр. Соңрак бу форма шәрәфле йомышчыларның рәсми киемәнә әверелгән. Дәвәтнең элекке татар дәүләтләрендә киң кулланылганы билгеле. Моңа өстәмә дәлил — **дәвәт, тәвәт** сүзенең «тәңкәле (орденлы) тасма» мәгънәсендә күрше чуваш, мари, һ.б. телләрендә дә еш очравы.

Инде **дәвәт, дәүгать** сүзенең чыгышына килгәндә, аны гарәпчәдән дип уйлыйлар. Кайбер телчеләр иске гарәпчә **дәват** «дәвалар, дарулар» сүзеннән дип караса, икенчеләр **дәвагать** «хезмәт әйберләре» дип аңлата.

Рифгать ӘХМӘТЬЯНОВ,
филология фәннәре докторы.

Яңалык! Яңалык!

Дусларга ярдәмгә

Татарстан Мәгариф министрлыгы белән Удмуртия Мәгариф министрлыгы арасында төзелгән килешүне гамәлгә ашыру җәһәтеннән күптән түгел Татарстан мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү институты методистлары Р.Борһанова һәм Д.Садыйкова Ижевскига барып, Удмуртиядәге татар теле һәм әдәбияты укытучылары курсында лекцияләр укып кайттылар.

Удмуртиядәге татар теле укытучылары үзләре дә Татарстан мәктәпләрендә даими булалар, тәҗрибә уртаклашалар, яңалыклар белән танышалар. Дуслык, хезмәттәшлек дәвам итә.

Г.ГАЙНЕТДИНОВА.

Тел өйрәнү чишмәләре

Урыс телендә укыта торган мәктәпләрдә татар телен укытуны тиешле югарылыкка күтәрү максатыннан Татарстан Мәгариф министрлыгы татар теле кабинетлары арасында конкурс үткәрә. Конкурс ике этаптан тора: беренчесе шушы елның 15 июнендә тәмамланды, ул район мәктәпләре арасында үтте. Конкурска барлык мәктәпләр дә диярлек җәлеп ителде. Үз зоналарында Әлмәт, Алабуга шәһәр-районнары, Теләче районы беренче урыннарга чыкты.

Беренче турда җиңгән 32 мәктәптән икенче турда катнашу өчен документлар килде инде. Алар арасында Биектау, Ютазы, Зәй, Минзәлә, Теләче, Алабуга, Лениногорски һәм башка район мәктәпләре аеруча актив катнаша. Икенче тур нәтиҗәләре ноябрь аенда мәгълүм булачак.

А.ЮСИПОВА.

Ерактан яхшы күренәме?

Татарстан телевидениесеннән шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Разил Вәлиев белән Төркиянең мәшһүр галиме һәм сәясмәне Надир Дәүләтнең әңгәмәсе күрсәтелде. Әңгәмә барышында татар теленең Татарстанда дәүләт теле буларак ни дәрәҗәдә үзгәрә баруына кагылган җитди-җитди сораулар да кузгатылды. Надир Дәүләт республикада бу эштә әллә ни алга китеш юк дип борчылуын белдерде, моңа ышанычлы дәлилләр китерде.

Татар җанлы хөрмәтле милләттәшебез бу юлы да саф татарча аралашу үрнәген күрсәтте. Аның республикага килүе дә телебезне үстерү эшенә өлеш кертү белән бәйле икән — ул җитәкчелек иткән фәнни экспедиция аерым төбәкләрнең милли үзенчәлеген өйрәнеп, махсус хезмәт язачак икән.

И.МАЗИН.

Агач — авыз, балта — тел

Исемнәрен кемнәр куйган

(Халык рейды дәвам итә)

Кемнәр укысын дип?

Мөслим районы — урыслар аз яшәгән төбәкләрнең берсе. Шулай булса да урамнардагы исем-агамаларның күпчелеге телебезне бозып, хәтта мыскыллап язылган. Универмаг, ветераннар өчен кибет, сыра, төзелеш материаллары кибетләре, мәдәният йорты, күпләп-ваклап сату берләшмәсе, «Светлана» фирмасы, «Дуслык» кафесы, «Колос» кинотеатры, автовокзал, аэропорт, район хакимияте, хастахане, төбәкне өйрәнү музее һәм башка оешмаларның элмә такталарында язулар саф татарча түгел, хаталы, яисә татарчасы бөтенләй юк. Мәсәлән «Леззет» берләшмәсе һ.б.

Г.МӘҮЛИЕВА.

Очланмаган җөмлә

Казанның Карл Маркс урамыннан киләм. Менә мемориаль такта: «Бу йортта 1852 - 1864 елларда бөек рус химигы А.М.Бутлеров торды». Язучысының да, яздыручысының да наданлыгына җан өрнеп, башны иеп, атлавымны дәвам итәм. Менә милли китапханәнең элмә тактасы. Шөкер, бер хатасыз язу. Телем өчен, аны хөрмәт итүчеләр, аны яхшы белүчеләр өчен горурланып, башны югары күтәреп, алга таба киттем. Әмма ләкин... «Вахитов районы сәүдә азык оешмасының 4 нче кибетенең «Лакомка»...» Моңысы нәрсә инде? Бу нинди башланып та очлана алмаган җөмлә. «Лакомка» дигәне татарча ничек була икән?

Р.ЙОСЫФ.

Безнең календарь

Октябрь

Рим календарендә бу ай сигезенче булганга, латинча ostower исеме ostodan (сигез) алынган. Сүз үзе урыс теленә грек теле аша кергән һәм борынгы урыс телендә бик төрлечә әйтелеп һәм язылып йөртелә: охтоврии, октоврии, октовръ, октямбрь, октябрь. Болай әйтелеш һәм язылыш башлыча сентябрь, ноябрь һәм декабрь исемнәре йогынтысында булган.

И туган тел...

1995 ел
20 октябрь
№ 3 (26)

Нәби Дәүли.

* * *

Кешеләргә шатлык ташыгыз,
Йөрәк белән, күңел белән,
сүз белән.
Ташыгыз шатлык!
Беркайчан да, беркемгә дә
Шатлык ул булмый артык.

Кызыл тел кызык итә

Шашкалда сүз табылмый

Ике ишет, бер сөйлә

Киләсе саннарда:

- Телләр турында Закон ничек үтәлә? Дәүләт Советы сессиясеннән соң уйлану.
- Телгә ихтыяж нәрсә ул? Сөйләшү бара.
- Тел кабинеты. Тәҗрибә ни сөйли.
- Янә компьютерлаштыру турында.
- Дин һәм тел.
- Агач — авыз, балта — тел.
- Урам буйлап халык рейды.
- Бишек җыры. Конкурс дәвам итә. Һәм бүтәннәр.

Сәхифәнең мөхәррире
Илдар НИЗАМОВ.
Адресыбыз: 420503,
Казан, Бауман урамы, 19
«Мәдәни җомга»,
«И туган тел...»

Ислам сәнгатьне тыйганмы?

фәндә һәм халык арасында мө-
селманнарның сәнгать турында
дөреслеккә туры килми торган
фикерләр бүгенгә кадәр яшәп ки-
лә һәм аларның тиз арада гына
үзеннән-үзе юкка чыгачагына
өметләнергә ярамый да. Мөсел-
ман сәнгате теориясе һәм тарихы,
аның терминологиясенең рухи
һәм эстетик нигезләре өлкәсендә
ныклы тикшеренүләр кирәклеге
көннән-көн ачыграк күренә

Хәзерге вакытта Көнчыгышны
өйрәнү буенча сәнгать белеме та-
рафыннан чит илдә тупланган
фәнни байлык һәм шулай ук Ис-
лам динен тотучы халыкларның
сәнгате белән кызыксынуның нык
артуы яңа матбугат басмалары-
ның нәшер ителә башлавына, тик-
шеренү үзәкләре һәм фондлар-
ның ачылуына китерде 1981 елда
Лондонда оештырылган Ислам сә-
нгате фонды — иң дәрәҗәлесе.
Бу фонд үзенең эшен ике юнәле-
штә — идеяләр алмашу буенча
халыкара форум оештыру һәм ха-
лыкны Ислам илләрендәге сән-
гать белән таныштыру юнәлешен-
дә алып бара. «Сәнгать һәм Ис-
лам дөньясы» журналы да шушы
максатны күз алдында тотып чы-
гарыла.

Дөрестән дә. «мөселман сәнга-
те» сүз тезмәсе, термин буларак,
киң кулланылса да, мәгънәсе әле-
гә бик үк анык түгел. Ул Ислам
идеяләре белән тудырылган һәм
таратылган дини сәнгатьне генә
белдереп калмыйча, мөселман
илләрендә элеккеге заманнарда
ук зур үсешкә ирешкән профессио-
наль һәм халык иҗатының бар-
лык төрләрен дә үз эченә ала.
Исламның эстетик системасы
формалашуы Якын, Урта, Ерак
Көнчыгыш илләрендә яшәп кил-
гән гадәт-йолалар белән тыгыз
бәйләнгән Ислам цивилизациясе
Урта диңгез, Һиндстан, Кытай, Шу-
мер һәм Вавилон мәдәниятләре
биргән эстетик һәм әдәби, сәнгати
байлыкларны үзенә сеңдергән.

Белгечләрнең бу юнәлештәге
эш нәтиҗәләре инде күзгә күренә
дә башлады Һиндстанның сәнга-
тен комплекслы өйрәнү бу ил мә-
дәниятенең Исламга күчеш үзен-
чәлекләрен күрсәтүгә юл ача
(И.Шептунова, Мәскәү) XII гасыр-
да куелган Кутб Минар һәйкәлен-
дә үк һинд-мөселман архитекту-
расының синтезы ачык куллана.
Бу синтезның икенче этабы — Бө-
ек Могол чоры. Ул вакытта үзен-
чәлекле ныгытмалар, төрбәләр
һәм бакчалар булдырыла. Мөсел-
ман Һиндстанында сарай да Ис-
лам тормышында һәм көнкүреше-
ндә аерым әһәмияткә ия булган.
(А.Суворова, Мәскәү) Шәһәр төзү-
нең гамәлдәге тәҗрибәсен өйрә-
нү-тикшерү бигрәк тә мөһим. Чөн-
ки биредә сарай-ныгытманың һәм
чын мәгънәсендәге сарайның ар-
хитектура комплексы белән бер
үк вакытта икенче сарай-бак-
ча — мөселман әдәби, сәнгати
иҗаты һәм гадәт-йолалары яши-
ләр

Мәшрикъ миниатюрасын өйрә-
нү дә яңа юнәлеш алды Тәбриздә
нык үсеш алган Сефевид китап
бизәлеше Сефевид шаһларының
хакимлегенең хокукый яктан көч-
ле булуын күрсәтә (М Назарли,
Мәскәү) Хронологик тәртиптәге
зур күләмле материалда YIII гасы-
рның Җами-әл-Умейа мозаикала-
рыннан алып XYI гасырдагы Сәл-
җук миниатюрасына кадәрге ва-
кыттагы «Мәшрикъ рәсем сәнгате-
ндә шәһәр образы» (Т Старо-
дуб-Еникеева, Мәскәү) күрсәтел-
гән. Шәһәр рәсемнәрен өйрәнү
аларда Ислам идеяләренең дөрес
бирелүләрен дәлилли

Тикшеренүләрнең тематикасы
һәм юнәлеше күп төрле Көнчы-
гыш дәүләт музеенда тупланган
XYII гасыр төрек тукымаларының
төп үзенчәлекләре ачыклана
(Н Сазонова. Мәскәү). Урта Азия
халкы сәнгатендәге дөньяга ка-
раш юнәлешләре өйрәнелә (Е Ер-
макова. Мәскәү), белгечләр игъти-
барыннан озак вакытлар читтә ка-
лып торган Сәлҗук сәнгате про-
блемаларының берсенә кагылып
үтелә (Л Саттарова. Казан), хәзер-
ге заман Әзәрбайҗан рәсем сән-
гатенең Ислам традицияләрен
үзенә алу юллары эзлекле өйрә-
нелә (Л Шихзаманова. Мәскәү).

Белгечләрне төбәкләрдәге сән-
гать үсеше үзенчәлекләре Ислам-
ның классик сәнгать байлыгыннан
ким кызыксындырмый Моннан
тыш без яхшы белгән күренеш-
ләрне өйрәнгәндә дә кызыклы
ачышлар булуы ихтимал. Мәсә-
лән Петербургта сакланган шәма-
илләрне өйрәнү Казан татарлары-
ның сәнгать ядкарьләрен аңлату-
ның яңа юнәлешләрен ачыкларга
мөмкинлек бирде

Русиядә 19 миллион мөселман
яши Мөселман дәүләтләре урыс
иленең коньягында ярымай рәве-
шендә урнашканнар Русиядә төр-
ле диннәрдәге күпмилләтле ха-
лык яши Бу ил өчен мөселман
мәдәнияте чиктәш һәм шул ук ва-
кытта үзенеке кебек тә Шуңа кү-
рә биредә — мөселманнарның
эстетик аңы башка диннәр сәнга-
те белән озак вакытлар янәшә бу-
лган шартларда — Ислам сәнгате
байлыкларын өйрәнүдә уникаль
мөмкинлекләр бар

Лилия САТТАРОВА,
сәнгать белгече.

Төрки дөньяның кабатланмас төсләре

***Узган атна мәдәният яңалык-
ларына, очрашуларга, күргәзмә-
ләргә гаҗәеп бай булды. Казан
шәһәре рәсем сәнгате мәктәбе-
нең 100 еллыгы уңаеннан «Төрки
дөнья» исемле икенче халыкара
сынлы сәнгать, декоратив әсәр-
ләр һәм кул эшләре сәнгате күр-
гәзмәсе ачылды, «Төрки халык-
лар сәнгате. Йолалар һәм заман»
дигән темага конференция узды.
Гомумән, әлеге программа бик
күп чараларны, очрашу-танышу-
ларны үз эченә алды һәм ул ерак
илләрдән, җирләрдән килгән ку-
наклар күңелендә гаҗәп җылы
тәэсир, хатирә калдырды.***

Максим Горький музее — моңа
кадәр дә күргәзмәләр үткәреп үз
залларына күп тамашачыны сәнгать
дусларын җыйган урын «Төрки дө-
нья» күргәзмәсендә Карачай-Черкес
рәссамы Халис Атаевның «Тауларда-
гы этюд», «Йон юу», «Йон буяу һәм
киптерү», «Хычины» дигән үзенчәлек-
ле рәсемнәре халык, милләт тормы-
шын чагылдыра.

Төмән өлкәсенең Тубыл шәһәрен-
нән килгән милләттәшебез рәссам
Эдуарт Тушаки, Башкортстаннан Ри-
зим Хаҗиев. Гагауздан Петр Плох, Ка-
рачай-Черкестан Мекер-Умар Борла-
ков һ б авторларның әсәрләре дә чын
осталарча иҗат ителгән Әлеге күргәз-
мәне оештыручы «Алтын Урда» рәс-
самнар ассоциациясе генераль дирек-
торы Сания Җамал безгә болай диде

— Төрки дөнья сәнгате белән без
даими таныштырып барырга тырыша-
быз Беренче халыкара сынлы сәнгать
күргәзмәсе дә Казанда үткән иде Төр-
ки дөнья сәнгатен яктырту өчен музей
яки галереяның даими эшләп торуы
кирәк. Киләчәктә шуңа омтылабыз.
Ә безнең белән хезмәттәшлек итәргә
теләүчеләр бик күп һәм аларның иҗа-
тына таң калырлык.

Чыннан да, төрки халыкларның сә-
нгате гаҗәеп бай аның тарихы борын-
гы заманнарга барып тоташа һәм чын-
барлыкны ачуга хезмәт итә

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

● **Карачай-Черкес рәссамы Халис Атаев.**

● **Күргәзмәдә очрашулар.**

ГАЗЕТА ҺӘМ УКУЧЫ

Хаҗитархан «Мәдәни җомга»ны үз итә

Сезгә изге Хаҗитархан туфрагында
яшәүче татарлар сәламен ирештерәм
Гәзитегез чыга башлауны мәдәни тор-
мышыбызда зур вакыйга итеп кабул кы-
лдык Көттереп, бик көттереп дөньяга
килде «Мәдәни җомга» Әдәбият-сәнга-
тькә багышланган матбаганы күңел күп-
тән көтә иде инде Ниһаять зарыгып
көткән сәгать сукты Гәзитнең йөгерек
теле күренекле шәхесләребезнең кыю
рәвештә үз фикерләре белән уртакла-
шулары күңелне били аның һәр санын
көтеп алабыз

Киләчәктә дә шул юлдан тайпылмый
барса «Мәдәни җомга» татарны үз асы-
лына кайтаруда үз югарылыгына күтә-
реләр дип уйлыйм - Әдәбият сәнгать,
мәгариф белән бергәттән кешә хокук-
ларын яклый аның мәнфәгатьләрен
кайгырта торган иң абруйлы гәзит бу-
лыр дип ышанам Шагыйрьләр акса-
каллар сүзенә элек-электән ханнар па-
тшалар колак салган «Мәдәни җомга»
— язучылар сәнгать әһелләре галим-
нәр мөнбәре алар хөкүмәткә үз сүзлә-
рен әйтерләр әле «Ташлар елатырлык
сүз» рубрикасында чыга торган фотога-
еплеүдән минемчә шәһәр гүрәләре хә-
зер үк куркып оркеп тора

Гәзитегез - безнең татар иҗтимагый
үзәкләре өчен һәм читтәге татар телле
гәзитләргә дә бик файдалы чыганак
Шул ук вакытта «Мәдәни җомга» үзе дә
безнең ярдәмгә мохтаҗдыр әлбәттә
Милли узаны булган һәр татар кешесе
яңа туган гәзитне базар икътисадында
саклап калуны үзенең бурычы дип сана-
сын иде

Наилә ФАТЫЙХОВА,
Әстерхан шәһәренең «Дуслык»
шурасы әгъзасы
«Идел» гәзите хәбәрчесе



Җәмит РӘХИМОВ

СӘЯСИ...

Алгысыган җаннар су өстендә дә басылмады Без әле һаман да хәрби диңгезчеләр түгел шул. туристлар диярлек. Ниятләнгән зур сәфәребез башланды башлануын Кече Невадагы диңгез пристаненда яңа акшарланган кулшы ташпупатны хәтерләтүче корабка төялдек Мәгәр бу әле — безне зур диңгез причалына илтеп куярга тиешле. гадәттә Ленинградны һәм аның тирә-юнен тамаша кылучы бәйрәмбайлар карамагына бирелә торган теплоход кына Алай да күңелләр күтәренке, кәеф шәп

Диңгез җилендә бөтерелеп. битемә килеп-килеп салынган тасмаларым кебек чәбәләнгән уйларым бүленде — кемдер беләгемнән кысып алды Борылып карасам — якташым Илфат. Ул безнең күршедәге Чирмешән районыннан, шуңа да гел бергә булырга тырышабыз. сүзебез-серләребез уртак Үзә әйтмешли. аңарда борынгы бабаларыбыз каны Илфат шушы кырыс училище шартларында да курсантларга песи ялarлык кына бирелә торган акчага нидер сатып ала. нәрсәләрдер сата, нидер алмаша. Бер очраганда кесәсендә әллә ниткән хикмәтле зажигалка булса, икенчесендә инде — үтә күренмәле тышчасы эченә ялангач гүзәл кыз сурәте иңдерелгән чит ил авторучкасы Ничә карасаң, Илфат хәрәкәттә нидер майтара. кырыкмаса-кырык вак-төяк табып, шулар белән әвәрә килә, үзенең күңелен таба Бу юлы да яныма юкка сугылмагандыр мөгаен Йә. ни бар тагын. дигәндәй, мин аның гел йөгереп торган коңгырт күзләренә, карчыга борынына, бөтен төркемебезнең горурлыгы булган чем-кара чәч бөдрәләренә карадым. Аның исә үз хәле хәл икән:

— Фаил, якташ, — ди бу, таш ваткандай еш-еш сулап, — синең кесә-шәрифләре ничек?

— Һәрвакыттагыча. — дим аңа, тыныч кына, — училищедан алган кызганыч тәңкәләр. Тиеннәр диярге дә була.

— Ничек инде, шундыен сәфәр чыгып?

— Нием ул акча: ашау — байдан, үлем — Ходайдан. Монда ачтан үтермәгәнне, хәрби корабта ашатмаслар дисеңме?!

— Тамак өчен кайгыртуым түгел лә... Чит ил портларына да тукталачакбыз, диләр ич. Диңгез аръягыннан буш кул белән кайту...

Булдыра алган кадәр шашыну-шамакайлану, белмим, тагы күпме дәвам иткән булыр иде икән. Офыкта легендар Котлин утравы — кырыс Кронштадт каласы күренгәч, курсантлар кисәк кенә басылып-боегып калдылар Ни әйтсәң дә, ваемсыз шаяру, сәйран урыны түгел инде бу , XYIII гасыр башында ук ашкынулы һәм гайрәтле падишаһ Беренче Петр тарафыннан нигезләнгән кальга. Кәеф-сафа корып йөрүчеләргә анда да карар, күңел ачарлык нәрсәләр бар анысы. Бардык, күрдек. Кронштадтта берсеннән-берсе күркәм һәйкәлләр, искитмәле музейлар аз түгел. Алай да, аны сәйран-ял урыны дип булмый. Бирелә һавасы ук кырыс: әнә ич, гайрәтле соры нейлон япмалар астына яшерелгән зур-зур хәрби кораблар да күзгә чалынгалый башлады. Утрау-кальганың кургаш тузаны белән тонәтелгәндәй авырсу сулышы безнең хисләребезгә дә орынмый калмагандыр шул.

Шобһәле сизенүбез юкка булмаган икән Причалга килеп туктауга, курсантларны ярга алып чыктылар һәм сафка тезделәр. Монысының да сере мәгълүм. җылы өендә калып, бичәсе кочагында назланачак комиссарларның зурысы, ягъни училищеның сәясәт башлыгы соңгы вәгазен укыячак Без инде аның ни-нәрсә әйтәсен күптән беләбез чит ил портларында урыс кешесенең, диңгезчеләрнең данына тап төшермәскә, тегеләй итмәскә, болай эшләмәскә, точкермәскә һәм йөткермәскә, бигрәк тә чит җир чәчбиләренә күз салмаска Алар анда. туры юлдан яздыру өчен, диңгезчеләрне чат саен көтеп кенә торалар, имеш

Шулай булды да Сәясәтчебез, тортеп торган түгәрәк корсагын сыпыргалый-сыпыргалый: әнә шуңа охшаш нотыгын кәгазьдән укый башлады Бездә исә аның үгет-нәсихәте кайгысы юк, үрелеп-үрелеп,шактый еракта , рейдта торган крейсерны карыйбыз Үз гомеребездә беренче зур сәяхәткә шул легендар йөзмә крепостьта барачакбыз ич. Тик ул моннан бик ачык күренми, томанлы су өстенә калыккан шәүләсенә карап кына аның тулы бер кыя булып торуын чамаларга мөмкин.

Ниһаять, нәсихәт тәмам Безне, катерларга төяп, крейсерга ташый башладылар Причалдан кузгалып китүгә, катерның борынына төялдек Мескен йөзгеч кисәге чүгеп, арты күтәрелеп калды хәтта Капитанның кисәтүенә карамастан, таралырга ашыкмыйбыз, кадаклап куйгандай, баскан урыннарыбызда катып торабыз — дәресләрдә өкияти бер нәрсә итеп сөйләнә торган атаклы крейсерны үз күзләребез белән тизрәк күрәсебез килә Чыннан да, хәйран хәлләр бар икән шул монда. Каршыбызда кораб түгел — тулы бер утрау Хак, ул инде бик нык какшаган, төсләре уңган, әтием әйткәндәй, туе узган туны тузган — тимер-томырга кискәләргә генә калган үзен Мәгәр аның ике йөз метрлар буе, алты катлы палубасы хушыңны алырлык. Барыннан битәр, нейлон бөркәнчекләр астыннан борыннарын төрткән бихисап туплар йөрәкне өшетеп-чемердәтеп ала Булса да булыр икән куәтле ут ноктасы, җитмәсә, су өстендә бит әле

Аңлашыла булыр, мондыен да алып корыч йөзгеч карап тору. яисә мактану өчен генә төзелмәгән, әлбәттә Крейсер күп еллар буена бөтен дошманнарның йөрәкләренә шом салып торган Сугыш вакытында исә Таллинн портында бүленеп калган урыс хәрби флотын камалыштан алып чыккан, Ле нинградны саклауда мөһим калкан ролен үтәгән. Кыскасы, озак еллар буена ботен кыйтга диңгезчеләренең күзләре өстендә каш булып торган «Киров» крейсеры Соңрак немецлар Төньяк боз океанында юлбасарлык кылып йөргән «Адмирал Шеер» кебек авыр типтагы зур-зур крейсерлар булдырганнар булдыруын. Мәгәр «Киров» үзенең җиңел крейсерлар классында бердәнбер булып кала биргән. Сүз дә юк, ул инде хәзер тәмам «картайган», кораллы көчләр сафыннан ук алынган. Тик әле дә кирәксезгә чыкмаган, безнең сыман «яшел» диңгезчеләрне өйрәтергә ярый икән.

Крейсерның баш вәгазьчесе юкка гына мактанмаган. Чыннан да, бу иләмсез зур бегемот шәп алдыра Тизлекне чамалау өчен ярлар күренмәсә дә, моның шулай икәненә гади күз күреме белән дә инанырга була Бездә бит инде хәзер чын диңгезче йөрәге уянып килә Су өстендәге корабның йөрешен дә тоя алмасаң, нинди диңгезче инде син! Сизелә: әйбәт барабыз, утрау-кораб җилдән җитез тулпар сыман сыптыра гына.

Килбәтсез һәм гаять зур йөзгечебез әнә шулай, бәйге чабышкысыннан ким булмаса да, экипажның һәм аларга дублер курсантларның максаты һич кенә дә кабалану түгел Безне бит күп кенә мәмләкәтләрнең уртак хәзинәсе булган бу диңгезгә яисә чит илләрнең берсеннән-берсе үзгә портларын күрсәтергә дип кенә алып чыкмадылар Ниятләнгәнчә, ярлары да күренмәгән олы су өстендә без диңгезченең ифрат авыр хезмәте күнекмәләрен алырга тиеш Тегендә, җылы аудиторияләрдә, хәрби галимнәрнең һәм океаннар кичкән ветераннарның сөйләүләрен тыңлау — бер нәрсә. ә менә ачык диңгез белән күзгә-күз калу — бөтенләй башка.

Менә шуңа да безнең «карт» мильләрне санамый Кайчак ул, канат какмый гына очкан бөркет сыман, бик акрын бара, еш кына туктап якорь да сала Үзебезнең порт саналган Таллиннга бару гына да ике тәүлеккә сузылды Курсантларның исә аның бару-бармавында эшләре юк, үз хәлебез хәл: әле арканнар, әле «янгын эчәгеләре» сөйрәп чабабыз, ул арада хәрби тревога буенча туплар янына, һәркайсыбызга билгеләнгән урыннарга торып йөгерәбез Кыскасы, тельняшкалар ап-ак тоз белән капланганчы изалыйлар курсантларны.

Алай да җанга ныклап тигәне — төнге тревогалар Конозын йөзмә утрауда чабулап, җан тирләренне сыкканнан соң, тәмам эт булып урыныңа ятарга, изрәп китәргә өлгермисең бәгырьләргә төшеп сирена чиный башлый — шомлы «SOS» тревогасы теш сызлавы булып җаныңны талый, тирә-якта «Человек за бортом!» дигән авазлар яңгырый. Белеп торасың пычагым да юк, шомлы караңгыда актарылган диңгезгә берәү дә батмаган — һичкем ярдәм сорамый Барыбер, яшен ташыдай сикереп торасың, атыла-бәрелә киенәсең һәм палубага йөгерәсең Анда инде — синең кебек үк, йокыларыннан айнып җитмәгән курсантлар кая барырга, нишләргә белми бәргәләнә, бер дә юкка йөреп-кайнап торалар Ул арада кемнәрдер шлюпкаларны суга төшерә һәм син дә Ходайга тапшырып, прожекторлар яктысында дәһшәтле кайнап торган диңгез кочагына атыласың Борт артындагы «мескен диңгезче»не әзли-әзли минутлар гына түгел сәгатьләр үтә Отбой булганчыга кадәр җеп өзәрлек хәлең калмый.

Ярый, зарланмыйк, үзең теләп дөньядагы иң хәтәр, авыр хезмәтне сайлагансың икән, сыкранма. Булганына шөкер кыл да практикаңны дәвам ит. Ә безнең чыннан да шөкер итәрлегебез бар Курсантларның күбесе, тәүлекнең теләсә кай вакытында, экипаж әгъзалары белән рәткә вахтага басып «эт җиккәндә», без рәхәтләнеп «җәннәт»тә ятабыз. «Без» дигәнем — училищеның халык уен кораллары ансамбле музыкантлары һәм алда торган концертларда катнашачак үзешчән артистлар Музыкага һәвәслегем һәм төрле уен коралларында көйләр сыза белүем тәки ярап куйды бит. әй! Ярады гына да түгел, училищеда, хәрби казарма шартларында, әлеге һөнәрем әллә ниткән бәлаләрдән коткаручы фәрештәгә әйләнде дә куйды Аның мәрхәмәтле канатын су асты диңгезчеләре әзерли торган шушы училищеда укый башлауга ук тойдым Башка курсантлар төрле хәрби уеннарда, әледән-әле булып торган парадларга әзерлек маршрутларында җиде кат тирләрен сыкканда, мин һәм минем сыман әргән шыгырдатучылар җылы бүлмәләрендә сәхнәгә чыгарга җыенабыз репетицияләр арасында уйнап-көлешеп тә алабыз, вакытында ашыйбыз-эчәбез Мактануым түгел. урыс әйткәндәй, гади үлемдарларга караганда базарлары күтәренке, абруйлы бер башка югарырак музыкантларның.

Сүземне мәзәккә каерырга тырышсам да, хаклык юк түгел анда Дөрестән дә, күп кенә курсантлар иза чиккән байтак кына чаралардан читтә калып, вакытны баян тартып үткәргәләргә туры килгәли миңа Элегрәк башыма килмәсә дә, хәзер әти белән әнигә рәхмәт укый-укый бик теләп барам репетицияләргә Әти белән әнине искә алуым да юкка түгел. Тегендә үзем туып үскән бәләкәй генә яшел һәм тын шәһәрдә яшәгәндә алар мине, якамнан сөйрәп диярлек, балалар музыка мәктәбенә йөреттеләр. Укыттылар гына да түгел. юк эш хакларын бар итеп, мәктәп кассасына акча түләп тордылар Минем исә һич кенә дә баянга өйрәнәсем килми, бөтен уй-исәп — дәресләргә бармый калу, һич югында алардан таю. Мәгәр куллары каты иде шул «картларның». Сугуын сукмадылар анысы әмма гырай гибеп йөрергә дә юл куймадылар Еш кына үпкәли идем үзләренә җүләр Хәзер исә рәхмәт кенә дим

Крейсер алга барган, безнең су өстендә тирбәлгән көннәр ишәйгән саен, ансамбльнең репетицияләре дә кызды һәвәскәрләрне инде очы-кырые күренмәгән күнегүләрдән дә азат иттеләр Сәхнәгә ялгызы гына чыгарга тиешлеләргә, билгеле инде, миңа да, офицерлар гына яшәргә тиешле аулак каюталар бирделәр. Репетицияләрне дә май белән ипи ашау дип булмый булуын, алай да, бу инде диңгездә чиләнү түгел.

Бу араларда гел генә күктә чекрәеп торган кояш астында, дымсу диңгез җиле белән тартыша-тартыша, ике-өч сәгать изаланганнан соң, килбәтсез һәм авыр контрабасны кубрик почмагына куям, дневальныйга тапшырам да, үземә билгеләнгән каютага ашыгам. Башка музыкантлар, әнә, көлешә-көлешә ял итәләр, мине исә анда потлы баяным көтә. Концертта уйнаячак көйләрем бик популяр, миңа күптән танышлар анысы — аларны көй итеп чыгара торган төймәләрне озын бармакларым үзләре табып торалар Тик, аңа карап, факультет комсоргы Бостриков репетицияләрнең өзелүенә юл куймый, күпме уйнавымны, нишләвемне тикшереп кенә тора. Алай да, аулак бүлмә — крейсер палубасы түгел инде.

Каютага кереп, бераз тын алдым да, идәндәге баяныма карап куйдым. Юк, уйныйсы килми. Әмма берни эшләр хәлең юк. Тартырга кирәк бу әрганне. Теләр-теләмәс кенә баянга үрелдем һәм, иллюминатор янына басып, аны шыгырдатырга тотындым.

Чирек сәгать тә үтмәде, тар аралыкта аяк тавышлары ишетелде. Каюта ишеге төбендә алар тынып калды Елмаеп куйдым — комсорг Бостриков, билтеле Бастырык буйлы, чандыр һәм сары чәчле бу урыс егете гадәттән тыш активлыгы һәм куштанлыгы белән дан тота. Аны аңларга була анысы. Бостриковны әле күптән түгел генә партия әгъзалыгына кандидат итеп алдылар. Әнә шуңа болай да үтә кызыл комсорг сәяси командирлар алдында чәче белән җир себерә, үзенә дә, башкаларга да һич тынгы бирми Бәлки аның шулай борчылуы кирәктер дә. Ни генә димә, безгә бит чит ил кешеләре алдында чыгып басасы. Концерт һич кенә дә йөзгә абкызыллык китерерлек, совет диңгезчеләренең абруена күләгә төшерерлек булмасын. Чынында концерт дип атала гына ул, аның эчен тышка әйләндерсәң, шул ук кып-кызыл пропаганда килеп чыга Максат — капиталистлар кулы астында изелеп яшәп яткан хезмәт ияләренә социализм оеткысын йоктыру. безнең бөтен дөньяда иң гуманлы системабызга ятсыныбрак карый торган илләрдә дусларыбызның кызыл иманнарын ныгыту Тик алар чыгышыбызның кызыл пропаганда икәнен сизмәскә тиешләр Менә шуңа да без аны әдәби-музыкаль композиция дип атыйбыз Аны инде диңгез утраулары аның берсендә яши торган латыш балыкчылары алдында сынап та карадык Болай ошаттылар сыман

Сагышка бирелеп, уйнавымнан туктап калганмын икән Кинәт баянымны киереп тартып «Ай, былбылым»ны сызып җибәрдем. Үзем үк җырын да сузам, имеш Тик мин бу шөгыльне сизмим уйларым — ламан да туган якларда Яшерен-батырын түгел, җәйләрне авылда үткәрсәк тә татар җырларын уйнамый да. җырламый да идек без Урыс оеткысыннан яралган нефтьчеләр каласында туган тел, милли моң дигән нәрсәләрнең үзләре димим төшенчәләре дә юк иде Билгеле инде, алар музыка мәктәбенең бусагасыннан ук кертелми Гомумән, туган телдә сөйләшү. татар көйләрен уйнау. яисә җырлау хурлык санала иде безнең шәһәрдә Минем исә әти дә әни дә — чын татарлар Әтием безне өйдә урысча

...єйләштерми, әни исә гел генә диярлек татар җыр-...арын, бигрәк тә «Ай, былбылым»ны җырлый Алар ...ш кына мине үзебезнең татар көйләрен уйнарга ...етлиләр Ә минем күңел тартмый, барыбер бере-...ә дә кирәге юк ич аларның. Алай да әнигә хөрмәт ...зеннән әнә шул «Ай, былбылым»ны өйрәндем. ...отасыз гына, әнкәй җырына ияреп.

Бервакыт шулай, музыка мәктәбендә инде, дәре-...ләр башланыр алдыннан әлеге дә баягы татар ...өен шыңгырдатып утырам Кисәк ишек ачылып, ...тазым, Чистай ягы мишәре Хәсби абый килеп ...рмәсенме.

— Туктале, нишләп син «соль» урынына «ля»ны ...инатасың, — диде ул, кырыс елмаеп һәм әллә каян ...ына бер кочак җыр китаплары тартып чыгарды. ...раларында ноталары төшерелгән «Ай, былбылым» ...а бар икән.

Ул көнне Хәсби абый миңа, бәлки беренче кат ...рограмманы бозыптыр, әнә шул җырның көен дә-...ес уйнарга өйрәтте. Тора-тора безнең кача-поса ...ткәрелә торган милли дәресләр ешайды. Мәктәпне ...мамлаганда мин инде шактый гына татар көй-...әрен дә сыздыра идем.

Шыгырдап ачылган ишек мине туган төбәгемнән ...олкып алды, бүгенге көнемә кайтарды. Бусагада ...ере шәүлә — комсорг Бостриков иде.

— Ты опять за свой буль-буль?! — дип ысылдады ...ысылган тешләре арасыннан. Сәясәт куштаны-...ың чираттагы кызыл вөгазенең башы иде бу

Кайтарып бер сүз дә эндәшмәгәч, Бостриков озак «сайрамады», кергәндәге сыман, җилтерәп чыгып ...итте. Үземнең һәм халкым моңының бер дә юкка ...имсетелүенә үртәлеп, байтак кына тын утырдым ...да, ачу белән тегә «ватанпәрвәрлек» җырларның

ХАТА

Хикәя

...өйләрен уйнарга тотындым. Ләкин кәефем тәмам ...ырылган иде инде. Баянымны бераз тарткаладым ...а, башымны аның күрегә өстенә салып, тынып ...алдым. Күңелне нидер чеметтерә. Туган якны юк-...ыну галәмәтеме, әллә соң йөрәккә кеше кешесе ...уның, юкка-барга да кимсетелүнең ачы юшкыны ...уны тоюмы бу?! «Их, тяжела солдатская служ-...а, но почетна», — дип чытык елмайдым да, дөнья-...ны онытып поляк композиторы Огинскийның мәш-...үр полонезын уйный башладым.

Бүтәннәрдә эшем юк, мин әтине уйлыйм. Затлы, ...әшһүр графлар һәм кенәзләр нәселеннән чыгып, ...аланты белән дөньяны таң калдырган бөек ком-...озитор һәм киемнәреннән генә түгел, тәненнән үк ...ир мае исе килеп торган минем әти. Нинди уртак-...ык булырга мөмкин алар арасында?!

Тукта, атаңны хөкем итәргә ашыкма. Соңгарып ...улса да, өзек-төтек сөйләгәннәреннән аңладым ...ин аны. Гомере буе каһәрләнгән туган җире, тап-...алган туган теле, кимсетелгән милләте, җәберлән-...ән тарихы-мәдәнияте өчен янып-көеп, сыктап-сык-...ап яшәгән әти. Ә бит аның һәм минем Идел-йор-...ыбыз гына түгел, Огинскийның Польшасы да ...ын-озак еллар буе басынчылар табаны астында ...рәгән. Бәс шулай икән, нишләп әле олуг Огинский ...елән минем гап-гади әти арасында уртаклык бул-...асын, ди?! Бар ул, бар бәхетсезлек уртаклыгы! Ул — туган ил, әммәт хафасы! Ачышым шундыен да ...е һәм үкенечле иде ки, баянымны ятакка ташлап, ...лубага, һава алырга чыгып киттем.

Әнә шул рәвешле — кем диңгез төеннәре чи-...чишә чиләнеп, кем — янып төшкәнче әргән тар-...ып, кем — үзенең шомлы уй-сагышларында кый-...алып йөзә торгач, атна үтте, икенчесе башланды. ...ез инде, берничә җиргә тукталып, Балтыйк буе ...еспубликалары балыкчыларына концертлар бир-...ек, аларның «сәяси аң»нарын агарттык. Юк, болар ...үзебезнең» халыкка кызыл пропаганда җиллү генә ...ел, үзенә күрә — безнең генераль репетицияләр ...а. Әдәби-музыкаль композиция отышлымы, чит ил ...амашачысы алдында хур булырлык түгелме — әнә ...ларны сынап карау. Өченчеме-дүртенчеме кон-...ерттан соң, партия эмиссарлары: «Бара», — дип ...атиха бирделәр.

Сәфәребезнең унберенче көнендә крейсер ...ольша ярларына якынлашты.

Крейсер причалда шактый читтәге аулаграк уры-...ында якорь ташлауга, курсантлар арасында мәхшәр ...упты. Аларны хәрби командирлар да, партия куш-...аннары да тыя алмадылар — һәркем үзенең парад ...ормасы өчен борчыла иде. Шулай булмыйни, хәр-...и кораб — әтиең йорты түгел, монда сиңа үтүкне ...әрәү дә өзерләп куймаган. Тик юкка хафаланган-...ар, совет диңгезчеләренең абруе хакында үтә дә ...к кайгыртучы сәяси аталарыбыз анысы турында ...уйлаганнар икән. Алмашлап чалбар-тельняшка-...арыбызны өтәли башладык.

...даньски безне зәңгәр күгә, чекерәеп торган ко-...ы һәм халык диңгезе белән каршылады.

— Фаил, карале, — дип уйларымны бүлде як-...ым һәм каядыр бер тарафка ымлады. — Ну, ...дәләр була бүген монда! Күрәсеңме, алыпсатар-...ар купме җыелган...

— Әйе, поляклар зурлап каршылыйлар совет диңгезчеләрен, — дип җавап бирдем аңа, үзе сы-ман ук шыпыртлап диярлек.

— Зурлап?! Төкерәләр алар совет морякларына, — дип кызып китте Илфат — Онытгыңмыни, бүген бит Балыкчылар көнә Поляклар исә безнен Сабан туе сыман опылап билгеләп үтәләр аны Әнә шул бәйрәмнәренә җыелганнар алар

Сүзенә ышанмасам да, Илфатның ничектер нәф-рәтләнеп сөйләвеннән эчемә салкын йөгерде Бул-мас. Балыкчылар көне дип, болай ук кубарылмас халык Безне каршыларга килгәннәр Мөгаен!

Мәйдан уртасына, әр-яңа нарат такталарны шо-мартмый-нитми генә. сәхнә сыман нәрсә өмәләп куйганнар Тик, нишләптер, аның тирәсе буш дияр-лек Әле генә халык диңгезен көч-хәл белән ерып уздык лабаса, монда исә хет футбол уйна Илфат-ның юраганы юш килер микәнни соң? Бу хәлгә үзем гаепле кеше сыман, көенә башладым. аннан исә эчемнән генә үземне сүгеп ташладым Сиңа ни, сиңа нәрсә калган?

Үземне-үзем шулай битәрләсәм дә. гавамның би-тарафлыгы эчне пошыра иде Күр инде. безнең якка күз дә салмыйлар диярлек, тик кайныйлар шунда үзара. шушының кадәр кеше карурманында да та-нышлары белән очрашып куана-сөенә күрешәләр. кочаклашалар Мәйдан гөр итеп тора. ят телдә кем-нәрдер нидер сөйли, көлешә, шатлыклы чыркылда-ша. Затлы сигарет төтәтеп тыныч кына сөйләшеп торучылар да, сыра парыннан кәефләнүчеләр дә күренә арада. Тик бездәге сыман сәрхүшләр юк. Мәгәр аннан безгә җиңеллек юк, сәхнә яны һаман да буш диярлек.

Без, уен коралларын футлярларыннан чыгарып, аларны көйли-кычкырта башладык. Шуны ишетеп, халыкның беразы болайга тартылды Эш пешә. ди-мәк, оркестр уйный башлауга, башкалары да тама-ша күрергә җыелачак.

Шулай булып чыкты да. Без беренче маршны уйнауга ук, тамашачылар сафы куерды Әмма без-нең уенга мөкиббән китүче күренмәде. халык ниче-ктер салкын һәм битараф кына үзешчән музыкант-лар уенын тыңлап тора иде.

Бу әле поляклар безнең сәнгатьне бөтенләй ка-бул итмәделәр. дигән сүз түгел, оркестр башкарган һәр көйне, сыеграк булса да, алкышладылар алар. Ә менә ялгыз җыр башкаручыларның эше бөтенләй хөрти иде Тамашачылар. шушы да булдымы инде җыру, дигәндәй, аларны илтифатсыз гына тыңлады-лар, шапы-шопы гына кул чапкандай иттеләр Хәтта факультет сандугачы дип саналган Игорь Соловьев җыры да мәйдан өстендәге ваемсызлык пәрдәсен ерта алмады.

Бу халык исә үтә мәгърур, үз милләтенә, аның мәдәниятенә бик тә бирелгән, диләр Потлы баяны-мны асып, сәхнәгә боек кына күтәрелдем һәм, те-ләр-теләмәс кенә «Мәскәү янындагы кичләр»не уй-ный башладым. Күзем — тамашачыларда. Моңа кадәр минем көндезләрен сәхнәгә чыкканым юк иде Кояш яктысында халык алдында басып торуы ай-һай кыен икән Мин тагын да каушый төштем һәм бармакларым белән бер-ике мәртәбә «өтәч кычкыр-тып» алдым. Кыйгачлабрак карасам, сәхнә почма-гында безнең комсорг Бостриков басып тора икән. Ул миңа ниндидер ишарәләр ясап маташты — сизе-лә иде, мине шелтәләвә.

Ничек кирәк, алай да көйне ермачлап чыктым, соңгы аккордны бирдем дә. нәрсәгәдер өметләнеп, тамашачыларга бактым. Алгы рәттәге поляк хәр-биләреннән бер төркем сыек кына кул чапкандай итте Әмма арттагырак рәтләрдәгеләр ваемсыз гына басып торалар, кайберләре үзара нидер сөйләшә-ләр иде. Аңлашылды: яндым мин, беттем. Хәзер, менә шушы минутта нидер эшләмәсәм, бөтенләй хурлыкка калачакмын. Үзеннән-үзе шулай килеп чыктымы, әллә инде шул секунд эчендә башымда бер-бер ният бөреләндеме, алып баручының сәх-нәгә күтәрелгәнен дә көтмәстән, тамашачыларга әй-теп салдым: Татар халык көе «Ай, былбылым». Шун-нан инде күзләремне сәхнә идәненә төбәдем дә, әниемнең яраткан җырын уйнап җибәрдем. Тик ха-лык алдында болай «бүкәй» булып тору килешми иде. Кабат башымны күтәрдем һәм мәйданга күз салдым Чү, тамашачылар үзгәреп киткәннәр түгел-ме соң?! Сизелә, игътибарларын сәхнәгә юнәлткән-нәр болар, арттарак сөйләшеп-көлешеп торучылар да миңа таба төбәлгәннәр. Алай да арада бер-бере-нең колагына иелүчеләр күренгәли. Нидер пышыл-дашалар да бугай. Йа, Хода, нишләдем мин? Берен-че көем белән концертны сүрелдерүем җитмәгән, икенче ахмаклык, тагын да хәтәр дуамаллык яса-дым! Әнә бит, күршеләренең колакларына пышыл-даучылар миңа таба төртеп-төртеп күрсәтәләр. Мө-гаен, бер-берсенә әйтәләр болар: менә ул теге кыр-гый азиат, явыз Чыңгызхан токымы шушы инде, дип.

Туган халкымның күңел бизәге булган көйне мин гадәттәгедән дәртләнеп, бер дә булмаганча шома уйнадым. Ничектер, кәеф күтәрелеп китте, комсор-гыбызның ачулы карашларына да игътибар итмә-дем, хәтта. Хәер, «Ай, былбылым» моңнары астында минем күңел инде монда түгел, балачак хатирәсе булган Тамчылы чишмә буенда йөри иде.

Поляклар дәррәү кул чаптылар, кемнәрдер нидер кычкырдылар. Мин исә боларның берсенә дә игъ-тибар итмәдем. Әсәрләнүем җиткән иде, дәшеп-ни-теп тормастан, Огинскийның мәшһүр полонезын уй-нарга тотындым.

Кинәт тамашачыларга әллә ни булды. Алар бөте-нләй тынып калдылар, ничектер алга тартылдылар, сәхнәгә якынлаштылар сыман. Күрәм: моңа кадәр мәйданның аргы очында гамьсез генә йөрүчеләр дә, ашыга-кабалана, болайга омтылдылар. Поляклар-ның әнә шул халәтләрен, күңел җылылыкларын тоеп, ничә еллар җанымда йөрткән полонезны уй-ныйм да уйныйм Дөньяда тере җан иясе калмаган-дай булды, төрле аһәңнәргә күчеп сайраган баян тавышы аша диңгез шавы ишетелә сыман.

Бармакларымның талганын сизәм. Акрынайган-нан-акрыная барып, тылсымлы музыканың соңгы тактларын бирәп-бирәп алам да, туктап калам Әл-лә күк күкрәде. әллә таш диварлар ишелеп төште — мәйдан котырынган алкышларга күмелде Кул-ларында бернәрсәләре дә юк иде кебек лөбаса, ә аягым астына чәчкә бәйләмнәре ява башлады Ул да түгел. бәдәннәрен авыр хезмәт ныгыткан. бит-ләрен диңгез җиле каралткан пәһлевандай ирләр сәхнәгә сикерешеп менделәр. мине баяным-нием белән кочаклый. кыса-изә башладылар. муен сөяк-ләрем шытырдады. хәтта. Анысы гына җитмәгән иде кулларына эләктереп алдылар да күккә чөй-деләр. һич тукталмый. мине һавада атындырырга тотындылар Аларның минем белән мавыгулары су-зылды. дәвамлы алкышлардан арган һәм шатлыклы дулкынланудан исерләнеп калган поляклар күңел-лә шаулашып тарала башладылар Ә бит безнең партия-комсомол органнары раслаган программа-быз бетмәгән иде әле Димәк, концерт өзелдә һәм аның сәбәпчесе — мин Эчем өшеп китте. көч-хәл белән, шашынган поляклар кулыннан ычкынып, сә-хнәдән җиргә сикердем һәм комсорг Бостриковка тап булдым Ул миңа күзләре белән ашардай булып карады Монысына да исем китмәде, чөнки мин сөенеч дәрьясында йөзә идем әле Уңыш, җиңү бит бу! Хак, әлеге алкышлар, хуплаулар һәм кадер-хөр-мәт миңа түгел анысы Алар барысы да олуг ком-позитор Огинскийга. Тик барыбер аның атаклы по-лонезын мин башкардым, полякларның милли хис-ләрен мин кузгаттым ич!

Уен коралларын озаткач. безне портның аулаг-рак почмагына җыйдылар һәм телəүчеләргә шәһәр-нең порты тирәсендәге кварталларын карап кай-тырга мөмкин икәнен белдерделәр Хуш сәгатьләр-гә сузылган киеренкелектән соң, дуслар белән бер сәйран кылуга ни җитә?! Тик шунысы сәер. йөрергә чыгарга тиешле төркемнәрдә һич кенә дә бериш дуслар тупланмаган... һәр бишенчесе — партия ку-штаны. Ул чакта без моңа шактый сәерсенсәк тә. серне соңыннан гына төшендек. төркемдәгеләр бер-бере артыннан шымчылык итсеннәр һәм шәһәр-дә булган хәлләрне партия эмиссарларына җиткер-сеннәр өчен шулай эшләнә икән бу

Кичен мине офицерлар кают-компаниясенә ча-кырдылар Барсам — өстәл тирәсенә партия куш-таннары бояпгән, бирге башта исә. башын иеп, Ил-фат басып тора. Мин килеп керүгә, комсорг Бост-риков утырган урыныннан калкынып куйды һәм те-ше арасыннан ысылдады

— Вот еще один голубчик. Тоже мне... зем-ля-ки!

Аның сүзенә игътибар итүче булмады кебек, эш-ләрен дәвам иттеләр. ягъни Илфатны талкыдылар. Мин башта аның гаебен аңламый тордым, бераздан төшендем Ул акча алыш-биреше ясаган, шәһәрдә йөргәндә тупы өч сумга (совет сумына!) әнисенә дип бер яулык сатып алган икән Аны тәмам чәйнәп бе-тергәч, миңа күчтеләр Сорау һәм гаепләү бар син, гап-гади курсант комсомол һәм партия оешмалары раслаган программаны бозарга ничек җөрьәт ит-тең?! Нәтиҗәдә сәяси концертны өздең!

Сүз һәм киная. куркыту һәм өркетү озак дәвам итте. Ниһаять, безнең тәртипсезлек фактының, учи-лищега кайткач, факультет комсомол оешмасында тикшереләчәген дә бик ачык сиздерделәр

Без аннан соң да Аурупаның байтак шәһәрләрен-дә, чит ил портларында булдык, концертлар бирдек. Сүземдә тордым, программаны башкача үзгәртмә-дем. Илфат та тәртип бозмады. Хәер, аның инде, шулай ук безнең дә, башкача сукыр бер тиен дә акчабыз юк иде

Күбебез өчен чит илләргә беренче баруыбыз бул-ган бу сәфәр барыбызга да шатлык булырга тиеш иде Тик мин, Гданьскидан соң, башкача сөенә ал-мадым инде Юк, сәясәтчеләрнең янавыннан кур-кудан димим, гөнаһым зур түгел анысы Тик бары-бер иптәшләр алдында тора салып кызарасы килми иде. Җитмәсә, кайту юлында тагын бер күңелсез хәл килеп чыкты — безне Финляндия башкаласы Хель-синкига кертмәделәр

Ни булган? Безнең маршрут үзебез барасы чит илләрнең җитәкчеләре белән килешенгән, дигәннәр иде бит Ул чакта моның сәбәбен безгә берәү дә әйтмәде Соңыннан белдек. узган сугыш вакытында «Киров» крейсеры, еш кына килеп, Хельсинкины каты-каты тупка тоткан икән Шуны онытмаган фин халкы, каһәрле крейсерның үз портларына туктала-сын белүгә, протест демонстрациясенә чыкканнар һәм хөкүмәттән аны якын җибәрмәүне таләп иткән-нәр.

Шулай, күңелсезләнергә сәбәпләр бар иде. Тик, ни гаҗәп, туган ил ярларына якынлашкан саен, алары каядыр артка чигенә. күз алдына әледән-әле Польшадагы беренче концертыбыз килеп баса. Тук-та, ни дип тынгы бирми ул миңа? Баш ватасы да юк, шул көнне мин моңа кадәр беркайчан да татымаган бәхетемә тап булдым Аның шулай икәнен ул чакта ук сизенгән идем Тик әлеге бәхетнең ни-нәрсә икә-нен башкаларга аңлату түгел, үзем өчен дә анык-лый алмаган идем Менә хәзер, офыкка җан тарт-кан ярлар шәйләнгәч, кисәк зиһенемә ачыклык иң-де: дөньяда милли хистән дә мөкатдәсрәк, милли горурлыктан да бөегрәк мәгърурлык юк! Бәхетем әнә шул хакыйкатьне йөрәгем белән аңлауда икән. Әлеге ачышым шул кадәр дә зур, газиз һәм йөрәккә якын иде ки, аның янында алда торган комсомол җыелышы чүп кенә булып калды...

Явыз Иван дәверендәге

Альберт ШЛИХТИНГ

(Дәвамы. Башы 13 нче санда)

Патша коточкыч ямьсез тавыш белән акыра. «Берәү белән дә санашып тормаска, туракларга да елгага ташларга!» Ул һәлак итүнең тагын бер алымын уйлап таба. Кешеләрне боз белән капланган елга өстенә кертәләр. Алар бергә тупланган. тирә-юньдәге бозны балталар белән ватарга тотыналар. Күп тә үтми, зур авырлыкка чыдый алмыйча, боз чатнап ярыла. Кешеләр су төбенә китәләр. Кыскасы, залимнең Новгород кешеләрен үтерүдә кулланмаган яман бер генә әмәле дә калмый.

Бик нык газаплап үтертә ул аларны. Сыңарына кадәр үтереп бетерелгән гади кешеләрне санамаганда да, шәһәрнең 2770 күренекле заты һәлак ителә. Новгород өлкәсендә йөз җитмешләп монастырь була. Патша аларның бөтен байлыгын талый. бөтен монахларны һәм дин әһелләрен үтереп бетерә.

Новгородка килеп кергәч, аны шәһәр епископы үзенә ашка чакыра. Баш тартмый залим. Табында төрле монастырьларның башлыклары да шактый була. Кунак ашы узып, өстәлләрне җыештырып бетерүгә, патша үзенең җан сакчыларын шәһәр үзәгенә урнашкан изге София храмын талатырга җибәрә. Талыйлар, ваталар, җимерәләр. Ул гынамы? Әле генә үзен кунак иткән епископны каршысына чакырып китерә дә, аның башындагы тиарасын (махсус башлык) суырып ала, өстендәге затлы киемнәрен салдыра, епископлыгыннан мәхрүм итүен белдерә. «Сиңа епископ түгел, ә күңел ачучы булырга кирәк иде. Мин сине өйләндерәм. хатынлы итәм!» — ди. Соңыннан калган монахларны үзенә ашка чакыра: «Инде, зинһар өчен. миңа кунакка рәхим итегез! — ди. — Менә бу епископның туен уздырабыз хәзер». Чакырылучыларның һәркайсы исә мәгълүм күләмдә бүләк алып килергә мәҗбүр ителә. Әйтик, һәр архимандрит — 2000, монастырь башлыгы — 1000, ә калган монахлар 500, 300 сум алтын түләргә тиеш була. Шул рәвешле уздырылган мәҗлестән соң патша епископка бер бия бирә: «Менә сиңа — хатын! — ди. — Хәзер үк өстенә менеп атлан да Московиягә кит, анда минем көлдерүчеләрем исемлегенә теркәл!» Епископ нишләсен, менеп атлана биягә Патша җайдакның аякларын .биягә бәйләп куярга куша. Шул килеш аны әлеге юлга куып җибәрә. Тик, озак та үтми, епископны кире кайтарта. Каршысына китереп бастыра да, аның кулына лира дигән уен коралы тоттыра. «Менә шушы сәнгатьне үзләштер! — ди — Син бит хәзер хатынлы булдың инде, аның күңелен ачарга тиешсең!» Епископ, атка атланган килеш, кулына лира тотып, Мәскәү ягына юл тота. Патша башка монахларның бөтен мөлкәтен талап ала, күбесен әллә нинди ысуллар белән җәзалаганнан соң, «теге» дөньяга озата.

Шушындый «тамашалар» күрсәткәннән соң патша Новгородтан ярты чакрым чамасы ераклыкка китеп урнаша. Шуннан торып, үзе янына Новгородның күренекле кешесен, шәһәрнең баш сәркатибе Федор Ширковны чакыртып ала. Каршысына китертә дә, аның биленә озын бау бәйләргә боера. Бауның икенче очын җан сакчысына тоттырып, Ширковны Волхов елгасына томырырга куша. Су төбенә җиткәч, аны кире тартып чыгаралар. Патша бу бичарадан су төбендә ниләр күргәнлеген сорый. Теге җавап бирә. «Су төбендә бик күп явыз җаннар күрдем. Башка елгаларның явызлары да шунда җыелган иде. Алар тиздән өскә калкып чыгачаклар һәм синең гәүдәңне үзләре янына алып китәчәкләр!» Мондый коточкыч җаваптан соң Явыз Иван Федорны учак янына китертә, өстенә кайнар су койдырта, үзе Федордан акчасын кая яшергәнен сорый. Бу кеше чыннан да бик бай була. Ул үз хисабына унике монастырь гына салдырткан икән. Бик тырыша торгач, тиран аңардан унике мең көмеш тәңкә түләттерә.

Шул рәвешле җәзалап, мал-мөлкәтен алып, аны үз казнасына озаткач, залим Федорны тураклатып, су төбенә ташлаттыра. Сәркатипнең туганы Алексей да нәкъ шул язмышка дучар ителә. Новгородлыларның җәзалануын, күпме байлык югалтуларын һичничек исәпләп-нитеп бетерә торган түгел. Бу кала элек-электән мул тормышта яшәгән, аңарда бик танылган сәүдәгәрләр, байлар күп булган. Аларның йортлары да әллә кайдан игътибарны җәлеп итеп торган. Һәр хуҗалыкта ит-май маясы, балавыз, очы-очы белән ефәк-атлас. кыйммәтле киемнәр саклангаң. Мәскәү патшасы ефәкләрне үзенең җан сакчыларына өләшә, алтын-көмешне үз казнасына салдыра, калган байлык исә харап ителә — йортлар тоташтан яндырыла. Гомер-гомергә муллыкта, рәхәтлектә яшәгән гөл кебек кала тәмам хәерчелеккә төшә.

Явыз патша бу шәфкатьсезлекләрен 1569 елда, бөек король илчеләре килеп өлгергәнче кылып ташлый. Илчеләр — воевода Инноулодиславский, Тальвос Каштелян Минский, капитан Радзиковленский һәм бөек корольнең сәркатибе Андрей.

Новгородны хәрабәгә әйләндергәннән соң, Иван үзенең 500 сугышчысын күренекле сәүдә үзәге саналган Нарвага җибәрә һәм Новгородтан китертелгән товарлардан сакланырга кирәк, дигән хәбәр тарата. Шул рәвешле, Новгород товарлары аерып куелгач, аларны яндырырга әмер бирә. Әгәр берәү әлеге күрсәтмәләрне бозса, аны шунда ук туракларга, мал-мөлкәтен яндырырга кушыла.

Новгород фаҗигасе вакытында ярлы халык шәһәрдән куып чыгарыла, ялан кырда калдырыла һәм күпләр шунда туңып-өшеп үлә. Исән калганнар исә, ачлыкка чыдый алмыйча, төннәрен мәет белән тулган шәһәргә кайткалый, аннан кеше гәүдәләреннән ит кисәкләрен умырып-умырып алырга, шуның белән тамак ялгарга мәҗбүр була. Хәтта кеше итен мичкәләргә салып тозлап та куялар. Тик бу «рәхәтлек» тә озакка бармый. патша мәетләрне мичкәдә тозлап саклауларын белеп ала, ник болай эшләүләрен сорый. Тегеләр, ачка үлмәс өчен, дигәч, барысын да терелэй суга ташлата.

Новгородны тар-мар иткәннән соң патша Псковка юнәлә, аның нинди максат белән килүен берәү дә чамаламый. Әмма Новгородтагыдай рәхимсезлекләрдән котылу өчен шәһәрнең һәр кешесе үз капкасы төбенә мул табын чыгарып тезә. Патша кайда туктарга теләсә дә, аңа ачык йөз, тәмле сүз һәм сый-хөрмәт әзер. Кайберәүләр, шәһәрдән чыгып ук, кулларына ипи-тоз тотып, аны каршыларга баралар.

«Җирәнмәсәгез, безнең ризыклардан авыз итегез, — диешәләр. — Без — сезнең коллар. Җаныгыз ни теләсә, шуны кылыгыз!» Залимгә аларның шул кадәр кимсенүләре, баш июләре бик ошый. Ул аларны үтерми, тик шулай да мал-мөлкәтләрен, алтын-көмешләрен талап ала. Тагын монахларга бәйләнә, кайберләрен турата, суга батыра, гыйбадәтханәләрен талый, барлык кыңгырауларын юкка чыгарта.

Патша сараенда аның бик якын киңәшчесе, дусты, танылган кенәз Афанасий Вяземский була. Бу кеше, үзенең патшага йогынты ясый алу көчен тоеп, аңа Григорий дигән бер кешене үз тирәсенә урнаштырырга киңәш бирә. Григорий тиз арада патшаның ышанычлысына әйләнеп китә. Аның Мут дигән кушаматы да бар икән. Кушамат, күрәсең, бу адәмнең холкын шактый тирәннән белгән түрәләр тарафыннан бирелгән. Ник дигәндә, күп тә үтми, Мут-Григорий тиранга Афанасий турында яман хәбәрләр ирештерә башлый. Имештер, Афанасий патшаның серләрен чишә. Патша Афанасийга ышана, хәтта, кирәк чакта, табиблар тәкъдим иткән даруларны да бары тик Афанасий кулыннан гына ала торган була. Инде Мут-Григорийның әләгән ишеткәч, ул ифрат кыза, үч алырга хәл кыла. Иң әүвәл Афанасийның барлык колларын үтертә. Патшаның җан сакчылары, Афанасий тиран белән киңәшеп утырган чакта, берәм-берәм кенәзнең колларын юк итә баралар. Шул рәвешле бөтенесен үтереп бетерәләр. Афанасий, киңәшмәдән чыгып, сарай ишегалдындагы туракланган гәүдәләрне күрә, әлбәттә, тик һичничек үзенең гаҗизләнүен сиздерми. Явыз Иванга бу гына бик аз тоела. Бераздан Афанасийның туганын һәм барлык хезмәткәрләрен кырып бетерәләр. Кенәзнең мал-мөлкәтен да тартып алалар.

Эшнең яхшылыкка таба бармаганлыгын сизеп, кенәз Арнольд исемле табиб канаты астына сыена, биш көн буе качып ята. Арнольд бөек кенәзнең шәхси табибы була. Тиран Афанасийны чакыртып ала да кисәткән булып кылана: «Күрәсеңме, — ди ул. — Сиңа каршы фетнә оештырыла бит. Син, акылың булса, кичекмәстән Мәскәүгә кит, анда мине көтеп тор!». Кенәз Афанасий ышанырга да, ышанмаска да белми, тик, нишләсен, атка атланып, Мәскәү юлына чыга. Патша кисәткән фетнәчеләр шикле… юлында очраган һәр кешене ут… рәп калдыра. Бераздан Мәскәү… патша үзе дә кайтып төшә һә… Афанасийны җәза урынына ч… кырта. Ул аңардан һәр көн… 1000, 500 яки 300 көмеш түл… тәрә, ә үзен көне-төне таяк бел… тукмыйлар. Афанасийның тән… кубырчыкланып бетә, түләр ак… часы калмый. Исән калу өмете… белән ул әле бер, әле икенче к… шегә яла ягарга мәҗбүр була… «Ул миңа акча бирергә тие… иде», — дип, әллә кемнәрне гаеп… сезгә патша карамагына тапшы… ра. Теге бичаралар, Афанасийга… бурычлары булмаса да, бу «б… рычны» түләргә мәҗбүр ителә… ләр. Шуңа да карамастан, Афанасийны һаман кыйный бирәләр. Иван Афанасий карамагындагы кырык кызны үз сараена күчертә. Кызлар ука белән бик затлы киемнәр чигәләр икән. Шул рәвешле, тиранның иң якын киңәшчесе дә сабак ала.

Торжок һәм Тверь

Патша әлеге шәһәрләрдә дә Новгородта кылган яманлыкларын күрсәтә. Монда ул Полоцкины алганнан соң куып китерелгән 500 поляк әсирен һәлак итә. Шунда ук 19 татар әсиренә бәйләнә. Алар, тиранның поляк әсирләре белән кылган ерткычлыгыннан соң, җиң эчләрендә пычак йөртә башлаганнар икән. Патша палачлары кылыч белән янарга тотынгач, тегеләр, икеләнеп тормастан, үз пычакларын чыгарып сугыш ачалар һәм патшаның җан с…ыларын утка бастыралар. Отряд җитәкчесенә аеруча каты эләгә, аны бер татар тәмам эчтән чыгара, тиран ялчысының эчәкләре актарылып чыга. Ул үлем хәлендә бу вакыйга турында патшага хәбәр итәргә боерык бирә. Укчылар килеп җитә, татарларны утлы коралдан атып үтерәләр.

Изборски шәһәрен поляклардан тартып алгач, патша моңарчы төрмәләрдә интеккән әсирләрнең һәммәсен суга батырырга әмер бирә. Әмма алда телгә алынган Афанасий аңа бу фикереннән кире кайтырга куша: «Синең яманлыкларың бөтен дөньяга фаш булыр. саклан!» — ди. Тиран аның белән килешә һәм әмерен кире ала. Тик бу фикерендә озак тынычланып кала алмый, әсирләр барыбер үтерелеп бетерелә. Җан сакчылары Ярославль, Ростов, Кострома кебек шәһәр… төрмәләрендәге әсирләр янын… җибәреләләр. Төрмәләрне ача… лар, әсирләрнең зынҗырлары… салдырыла һәм аларга күренек… ле затлар янындагы мөнбәргә та… ба атларга кушалар. Имештер хәзер аларны Польшага кайтарып җибәрәчәкләр, ә Польшадагы урыс әсирләрен, шуңа җавап йөзеннән, Русиягә чакыртып алачаклар.

— Алай булгач, ник соң хатыннарыбызны да чыгармыйсыз? — дип сорыйлар бичара әсирләр.

— Алар да, балаларыгыз да… чыгарылачак. — диләр җан сакчылары.

Хатыннар карап кала. Ә и… әсирләрне, аз гына читкә киту бе… лән, кулларын артка каерып бәй… ләп, арбаларга төйиләр дә боз… өстенә алып төшеп китәләр. Анда исә бәкеләр әзер. Бөтенесен шул…

бәкеләргә салып бетерәләр. Бу хәлдән соң өч көн узгач, әсирләрнең хатыннары янына бер мескенүле килә дә фаҗига турында сөйләп бирә, хатыннарга да шундый ук җәза булу ихтималын әйтә. Бичаралар үз яннарына дин әһеле җибәрүләрен сорыйлар, үлем алдыннан гыйбадәт кылырга телиләр, гөнаһларыннан арынырга өметләнәләр. Аларга ике сәгать вакыт бирелә. Гыйбадәт кылган һәр хатын, баласын күкрәгенә бәйләп, һәлакәткә бара. Җан сакчылары хатыннарның шул ук бәкеләргә үз аяклары белән чумуларын таләп итәләр. Берәүнең дә үз ихтыяры белән бәкегә сикерәсе килми. Шуннан соң тегеләр балалары үзләренә бәйләнлә Йомышлары төшсә бары тик үзләрә генә йөри башлый.

Польша короленә ярдәм сорап юлга чыккан кенәз Горинский залимнең әләкчеләре тарафыннан ярты юлда тотып алына. Аны патша әмере белән Литва җирендә үк казыкка утыртып, һәлак итәләр. Горинский юлга 50ләп юлдашы белән чыккан була. Аларның барысын да асалар. Бер кол качкан була, тик патшаның Петр Зайцев дигән җан сакчысы моны сизеп алып, тиранга җиткерә. Шушындый «оятсызлык»ны белгән патша әлеге качакны гына түгел, хәтта Зайцев хезмәткәрләренең дә икәвен асарга боера. Бу өчәүнең асылган гәүдәләре Зайцев яши торган телгән кадәр «файдалана» инде ошап бетми икән аны берәр сугышчысыннан көчләтеп мыскыл иттерә үзе шул вәхшилеккә карап тора. аннары көчләнгән хатынны ире янына куып кайтара. Ә инде берәр хатынның ирен яратмаса, аны суга ташлата. Ул моннан бер ел гына элек үзенең сәркатибен шул ысул белән һәлак итә. Башта аның хатынын һәм хатынның асравын үзе янына алдыра. Бик озак вакыт алардан «файдалана». Аннары бу ике көчләнгән хатынны иренең ишек түбәнә астырып куйдыра. Гәүдәләр залим элмәкне кисәргә кушканчы. бик озак асылынып торалар. Үз сарае хезмәткәре белән дә шул ук хәл була. Хезмәткәр-кулына әсирлеккә төшкән имеш, һәм аның каршысында җавап бирә. Егет бу төшне Явыз Иванның мәрхәмәтен яулап алу өчен юри уйлап чыгара. Хәбәрне патшага көне-сәгате белән ирештерәләр. Ул егетне үзе янына чакырта да төшен сөйләргә куша. Сөйләп бирә теге «Польша короле сез Галиҗәнаплар каршында богауланган килеш басып тора иде — ди ул. — Сез аңардан сорау ала идегез». Патша төшнең уйлап чыгарылганлыгын сизеп. бичараны җәзаларга тотына һәм аны бу төшне төрмәдән котылу өчен сөйләгәнлеген танырга мәҗбүр итә.

Русия турында яңа хәбәр

гән хатыннарны икешәрләп-өчәрләп бәкегә ташлый башлый. Бу вәхшәтне карап торучы халык еларга, ыңгырашырга тотына. Тик аларны бик тиз туктаталар: «Әллә үзегезнең дә җәһәннәмгә олагасыгыз киләме?!» — дип кенә кычкыралар. — Тынычгызны чыгарасы булмагыз, бу турыда берәү дә белергә тиеш түгел!»

Хуҗасы нинди, эте шундый дигәндәй, сугыш кораллары өчен җавап бирүче Дмитрий Васильевич исемле бер хезмәтчесе була Явызның. Ул укчыларга хезмәт хакын вакытында бирми интектерә. Моннан тыш, ул әле тагын бер этлек эшли — аның карамагында Полоцкида кулга төшерелгән ике поляк әсире була. Алар качалар һәм, тотылгач, тиранга корал сакчысының гаделсезлегенә чыдый алмауларын сөйләп бирәләр. «Без Литвага китмәкче идек», — диләр. Явыз Иван бу бичараларны арбага утырта, нык кына бәйләргә куша, ә арбага җигелгән атның күзләрен чокыта. Сукыр ат суга барып төшә. Патша суга чумганнарга: «Барыгыз, бөек королегез янына кайтыгыз, мин бит сезне арбага утырттым, ат бирдем», — дип кычкыра. Бераздан барысы да су төбенә китәләр.

Бервакыт Явыз Иванның дьягы мәҗлес ясый. Ул үзенең дус-ишләрен кунакка чакыра. Мәҗлес барган чакта дьяк, залим сараенда андый-мондый хәл юкмы икән, дип үзенең ялчысын җибәрә. «Белеш әле! — ди, — Патша ни белән мәшгуль икән? Миңа йомышы-фәләне килеп чыкмаганмы?»

Ялчы Кремльгә китә. Барса, патша Афанасий белән киңәш-табыш итеп утыра икән. Дьякның ялчысын күргәч, патша тиз генә яшерене, бу кешенең нишләп йөрүен белергә боера. Ялчы барын да сөйләп бирә: «Минем хуҗам патшаның ни белән шөгыльләнүен белергә җибәрде», — ди. Ялчыны тотып алалар, ә дьякны бөтен кунаклары белән патша янына китереп бастыралар. Кунаклардан сорау алу башлана: «Ник җыелганнар? Патшаның бу вакытта нишләве аларга ник кирәк булган? Патша турында ни сөйләшкәннәр?..» Сорау алу коточкыч җәзалаулар белән чиратлаштырылып алып барыла. Җавапка тарттырылучыларның кайберләре, чыдый алмыйча, шунда ук җан бирә. Исән калганнарның барлык мал-мөлкәте талана. Шуннан соң берәү дә патша янына ялчыларын җибәрмәс буйорт каршында өч атна буе тирбәлеп тора. Өйгә керергә теләгән һәр кеше бу бәхетсезләрнең гәүдәләре яныннан узарга мәҗбүр була. Ә Сицкий фамилияле кенәздән ачу алыр өчен залим аның хезмәткәрләрен кенәз өенең алдында ук астырып үтертә һәм үз боерыгыннан башка гәүдәләрне алмаска куша.

Залимнең хатын-кызларга карата ерткычлыгы

Явыз Иван үзе турында кайсы хатынның ни сөйләвен белеп торыр өчен махсус шымчылар асрый. Яман сүз әйткән хатынны, тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә, хәтта ире белән йоклап яткан чагы булса да, үз каршыларына китерүләрен таләп итә. Әгәр әлеге хатын аңа ошаса, ул аңардан нең көчләнгән хатыны гаилә ашый торган өстәл өстендәге түшәмдәге ыргакка асыла һәм шунда бик озак эленеп тора.

Явыз патша, воевода Иван Петрович утарын басып алгач, үз лагерена искиткеч чибәр 50 хатынны китертә. Аларны күтәреп кенә йөрттерә ул. Бу чибәрләрне саклау өчен 500 сугышчы бүлеп бирә. Әлеге бичара җаннардан үзенә ничек кирәксә, шул кадәр файдалана, ә туйдырган берен суга батыра бара.

Тиранның төш юраулары

Шактый мәгълүм бер бәндәнең улы патша төрмәсенә эләгә. Тоткынлыктан ничек котылырга белми интеккәндә, аңа бер уй килә. Имештер, ул төш күргән. Төшенә караганда, Польша короле тиран

● И.Репин. Иван Грозный һәм аның улы Иван. 1885.

Залим бу бәндәне бик каты суктырып. кирeдән төрмәгә яптыра һәм ул сөйләгән төш хакыйкатькә туры килгәнчегә кадәр. тоткынлыкта изаларга боера.

Бервакыт Явыз Иван янына бер карт килеп керә. Теге терсәкләренә таянган килеш уйланып утыра икән. Картны күргәч: «Әйдә, уз, минем тугры колым. — ди патша. — Утыр якынрак. Мин сиңа тиешлесен бирермен!». Борис Титов исемле әлеге карт якынрак килеп баса, ә залим һәрчак үзе белән йөртә торган пычагын алып, картның колагын кисеп ташлый. Карт авыр сулап әйтә: «Рәхмәт, падишам! Синең бу җәзаң — минем өчен иң кадерле бүләк!» «Алай булгач, колагыңны ал да ычкын моннан, — дип үкерә патша. — Югыйсә мин сиңа тагын да зуррак бүләк бирермен!»

1566 елны Иванның якыннарыннан исәпләнгән 300ләп кеше берләшеп, аңа мөрәҗәгать итәргә булалар. Мөрәҗәгатьтә болай диелә: «И безнең якты йөзле падишабыз, әфәндебез! Син ник безне иң тугрылыклы кешеләреңне үтертәсең? Без бит сиңа тугры хезмәт итәбез, синең өчен җаннарыбызны да кызганмыйбыз. Безнең тугры хезмәтебез коточкыч җәзалар белән кире кагыла бара. Өстебездә синең җәлладлар өере тора, алар теләсәләр, кисәләр, теләсәләр, асалар безне...»

Патша аларның һәммәсен дә төрмәгә яптыра. Анда биш көн торгач, кайсының телен, кайсының аяк-кулларын кисә, ә өченчеләрен таяк белән яра, башкаларын җибәрә. Берничә көннән соң иреккә чыгарылганнарын исенә төшереп, кабат чакырта, кисә, турый.

Залимнең ауга йөрүе дә гыйбрәтле. Шәһәр урамында, кибетләр тирәсендә берничә кеше җыелып торганын күрсә, аларга кыргый аю җибәртә торган була. Кешеләр котлары алынып кача-йөгерә башлыйлар. Ач аюлар исә аларны эләктереп алып тешлиләр, өзгәлиләр. Үлгәннәрнең хатыннары зарланып килсә, патша аларга өчәр көмеш тәңкә бирә. Тегеләр хәйран калалар: «Ничек инде адәм башы өч көмеш кенә торамыни?» — диләр. «Патшага һәм аның улларына бик кызык тамаша булды ул. Сезгә бирелгән тәңкәләр шул тамаша бәясе», — дип җавап кайтаралар аларга.

(Ахыры 20 нче биттә).

Явыз Иван дәверендәге Русия турында яңа хәбәр

(Ахыры. Дәвамы 18, 19 нчы битләрдә).

Александр сараенда ау күренеше оештырырга теләсә, патша берәр якынын аю тиресенә киендерә дә аңа дүрт аяклап йөгереп китәргә куша. Бераздан, аның өстенә ау этләре өерен өстерә. Этләр, аю тиресенә төренгән бәндәне чын аюга санап, теткәләп ташлыйлар.

Мәскәүдә бозау ите ашаудан чирканалар. Бу хәл менә нидән башлана. Патша үзенең крепостнойларын Вологда крепостен салырга җибәрә. Крестьяннәр ачлыкка түзә алмыйча бозау сатып алалар һәм туйганчы ашыйлар. Аларның шулай тамак туйдырганнары турында ишеткәч, патша күбесен яндырып үтерә һәм бозау ите ашауны тыя.

Ташбәбәк хаким карамагындагы татар сугышчыларына аеруча каты әләгә. Татарлар (берничә йөз атлы сугышчы) аның мәкерлегеннән һичничек котыла алмый интегәләр. Ул аларны төрле крепостьларга бүлгәләп бетерә. Алар шунда кыш чыгарга тиеш булалар. Патша аларны аерым-аерым чакырып ала һәм татар сугышчылары барып җитү белән үк аларны үтереп суга ташлыйлар. Арадан бик сирәкләре генә исән кала.

Ике кенәзне — Осип Щербатый белән Георгий Борятинскийны (алар Польшада әсирлектә була) поляк әсирләренә алмаштырып, Мәскәүгә кайтарта ул. Аларны кунакка чакыра, ука белән чигелгән киемнәр бүләк итә, аларның сәламәтлеге өчен көмеш чәркәләрдән аракы чөмерә һәм Польшадагы хәлләр турында сораша. Осип дигәне аны-моны абайламыйча үз күзе белән күргәннәрне хәбәр итә, ә Борятинский исә теленә ни килде, шуны алдап утыра — Польша короленең Мәскәү патшасыннан бик куркып яшәгәнлеге турында такылдый. Ашап туйгач, патша урыныннан кузгала да Борятинскийга кычкырып җибәрә: «Йә кабатла әле. Польша короле миннән ни рәвешле куркып яши соң, ә?» Теге җавап кайтара: «Падишам, ул синнән генә түгел, хәтта синең һәр сугышчыңнан, Мәскәү байрагын тоткан теләсә кайсы кешедән коты алынып яши, чөнки аларның корал ягыннан да, көч ягыннан да өстенрәк булуларын тоеп тора», — ди. Иван сүзнең ялганга тоташканын сизеп ала да: «Кызганыч, бичара король шулкадәр куркак икән! — дип куя да, шунда ук Борятинскийга эндәшә: «Ә син — ата ялганчы! Үз-үзеңне коткарыр өчен юри әкият сөйләп утырасың!» һәм ул аны таяк белән ярырга тотына. Бичара Борятинский патшаның аягына егыла, аңа тугры хезмәт итәчәген, әлеге кыйнауны да бүләк рәвешендә кабул кылуын теләп кычкырый. «Белем, белем! — ди аңа патша. — Синең башка чараң юк бит, син шуңа күрә генә тугрылыклы!»

«Бөек король галиҗәнаплары! Сезнең илчеләр киткәч, залим Третьяк белән Висковатыйны кагнга батырды. Күпләп акча сорады. Берсенең хатынын китертте. Ул бичара патшаның аягына егылган. Залим аңа торып басарга куша да, башындагы кәпәчен сугып төшерә, әти-әнисенең исемен сорый. Хатын шактый ук билгеле нәселдән икән. Патша аны суга батырырга боера.

Тагын шуны әйтәсем килә. Бу Явыз Иванның Гвоздев фамилиясен йөртүче ике туганы бар. Берсе — сарай башлыгы, икенчесе — Бөек кенәзнең йокы бүлмәсен саклаучы итеп билгеләнә. Әлеге икенчесе үзе күргәннәрне шул хәтле оятсыз рәвештә сөйләп йөри, хәтта бу турыда әйтергә дә оят. Бервакыт әлеге «йокы сакчысы»ның табында ниләр сөйләп утыруын ишетеп, тиран аның читкәрәк китүен таләп итә. Аның китүе була, табынга кайнар кәбестә ашы китерәләр. Патша шул кәбестә шулпасын туганының башына коя. Тегесе: «Зинһар кичерә күр, бөек падишам!» — дип ялвара. Шул вакытта патша пычагын аның йөрәгенә кадый.

Бу патшаның хәтта үз туганнарына карата да шәфкать-мәрхәмәт дигән хисе юк. Киресенчә, ул андыйларны тагын да шәфкатьсезрәк рәвештә интектерә. Аның туган-тумачалары бер-берсен әзәрлекләргә җайлап куелганнар. Турысын гына әйткәндә, мондагы туган-тумачалыкта ата — улны, ана — кызны белми һәм белергә дә теләми. Шундыйлардан бер мисал. Ике бертуганның абыйсы көлдерүче итеп билгеләнгән энесе алдында үз әтисенең фамилиясен Оболенский дип атый. Иван бу фамилияне искә алуны тыйган икән. Шымчылар, әлбәттә, әлеге сүзне аңа ишеттерәләр. Нәтиҗәдә, патша яратып йөри торган бер тамаша вакытында әлеге көлдерүче үз агасы өстенә кыргый аюны өстерә. Аю өзгәли башлаган ирне коткара башлыйлар. Аю китә, әмма әлеге «көлдерүче» бөтен тамашачы алдында үз агасын һәлак итә. Чөнки аңа үз гомере кадерлерәк.

Боярларны мыскыл итү

Изге апостол Иаков көнендә залим үзенең җан сакчыларын Мәскәү шәһәренең үзәк мәйданына җибәрә. Алар анда егерме казык кагалар. Биек казыкларга аркылы киртәләр бәйлиләр. Моңарчы мондый хәлне күрмәгән халык шәһәрдән кача башлый. Ә җәлладлар үз эшләрен дәвам иттерә: әлеге казыклы «төзелеш» янында учаклар ягыла. Су кайнаталар, салкын су салынган савытлар да куела. Ниһаять, залим мәйданга үзе белән җан саклым мәйданга үзе белән җан саклап чыгучылары, айбалталы җәлладларын, 1500 атлы сугышчысын ияртеп килә.

Мәйдан халык белән тулгач, ниһаять, залимнең «төшен сызлатып торган» 300ләп күренекле ир атны китерәләр. Борын-борыннан үз нәсел-нәсәпләре белән горурланып яшәүче әлеге ирләрнең өсләренә карарга да кызганыч: алар тәмам мәсхәрәләнгән. Кайберләре аякларында көчкә басып тора, күбесенең аяк-куллары киселгән, барчасыннан да елга булып кан ага.

Шул бичараларны залим каршына китереп тезәләр. Мәйданга җыелган халык, бу вәхшәткә чыдый алмыйча, кире борылмакчы була. Тик Явыз Иван, шәһәр халкының барысын да шулай җәзаларга уйлаганлыгын, соңгы минутта гына әлеге карарыннан кире кайтуын искәртә. Бу коточкыч кисәтүдән соң халык кабат мәйданга борыла. Шуннан соң залим акыра-бакыра болай ди: «Мин хыянәтчеләрне җәзалап дөрес эшлимме?». Коты алынган халык: «Дөрес, дөрес!» — дип җавап кайтарырга мәҗбүр була.

Шул «карардан» соң һәр «гаепле» мәйдан уртасына чыгарыла. «Кем аны беренче булып җәзаларга әзер?» — дип сорый патша. Җәлладларның иң өлгере теге бичараның борынын телеп уза, икенчесе — колагын... Шул рәвешле тәмам һәлак итеп бетерәләр бу ир-егетләрне. Бер җәллад үз карамагына тапшырылган корбанның җенси әгъзасын кисеп төшерә. Патша моңа үзе дә хәйран кала. «Синең үзеңә дә шул «ләззәт» тиеш!» — дип кычкыра. Ренут исемле бу башкисәр шул ук җәзадан терелә алмый җан тәслим кыла.

Мәскәүнең атаклы ир-егетләре белән «эш»не түгәрәкләгәч, патша аларның улларына, аннары хатыннарына үчегә: сиксәнләп хатын үтерелә, ә биш йөзләбе патша сараена китерелеп, алдагы көннәр өчен «файдалануга» калдырыла.

Мин Мәскәү каласындагы чын хәлләр турында гына язам. Аның елгалары адәм каны белән болгатылган, җире кан вә сөякләр белән ашландырылган.

Тиранның алдан күрүчәнлеге

Новгородка ясалган яман сәфәр чорында Афанасий Вяземскийның бик шәп юргасы була. Бервакыт шул ат, иярләрен өзеп, сәхрәгә чыгып чаба. Әй куалар аны ялчылар, әй йөгерәләр артыннан — һич тота алмыйлар. Нәкъ шул вакытта залим бер манзарага тап була. Бичара хайван аның юлын аркылы кисеп уза. Бу хәлне начарга юрап, патша аны да, аны тота алмый интеккән колны да үтерә.

Юлында очраган хатыннарга да мөнәсәбәт шундый була. Патша аларның барысын да туктата. Кем хатыны икәнлекләрен сорый. Аннары шәп-шәрә калырга боерып, үзенең йөзләрчә ялчыларына бөтен әгъзаларын күрсәттертә.

...Бөек галиҗәнабым, королем! Мин монда бары тик үз күзләрем белән күргәннәрне һәм дә үз колакларым белән ишеткәннәрне генә язам. Мин белмәгәннәре, башка кече һәм олы калаларда кылынган кыргыйлыклар зур-зур томнарга да сыймас иде.

Өстәмә

Хәзерге вакытта бу явыз бәндә, Кырым татарларына каршы һөҗүм оештырам дигән булып, Мәскәүдән чыгып качты, моннан 20 чакрым ераклыктагы Коломнага күчеп китте. Чынында, ул Мәскәү каласындагы авырулардан — ваба, тилчә кебек чирләрдән кача. Киткәндә дә кеше күп яши торган авыл-шәһәрләрне чистләтеп узды, чир йоктырудан коты алынды.

Сезгә илче итеп җибәрелгәннәр арасында кенәз Григорий Мещерский, кенәз Иван Камбуров, керәшен татарларыннан — Казан патшалыгы вәкилләре кенәз Григорий Путятин белән Олиф Непея һәм дьяк вә писарь бар. Алар юлга җыеналар, барып җитә алырлармы, белмим. Чөнки монда халык яман чирләрдән кырыла. Аерата 28 шәһәрдә күп үләләр, Мәскәүдә һәр көнне 600ләп кеше вафат булып тора.

Бүгенге көннәрдә Мәскәү белән кенәз Масальский, казакчы Борис Сукин җитәкчелек итә. Явыз патша ялгызы гына җитәкчелек итүне бирүгә дә тапшырмый.

Мин язганнар, бөек королем, бу илдә җиде ел буе күргәннәремнең меңнән бер өлешен дә тәшкил итми. Ходаем шаһит — болар барысы да дөрес һәм аларны һичкем ялгыш дип әйтә алмый.

ТӘРҖЕМӘЧЕ ИСКӘРМӘСЕ:

Мин бу язманы тәрҗемә иткәндә, ифрат дәрәҗәдә дулкынландым. Йа Ходаем! Әлеге язмада тасвирланган мәрхәмәтсезлекләр Русия империясендә әле хәзер дә дәвам итә түгелме? Безнең чор «патшалары» Әфганстанда, Ичкериягә бәреп кереп, анда канлы сугышлар ачып, күпме егетләрнең башына җиттеләр. Хәер, шуңа охшаш кансызлыклар күп булды инде бездә. Үзенең шәфкатьсезлеге белән башка халыкларны куркытып яшәүче бу империянең мәрхәмәтсезлегенә кем, кайчан чик куяр??? Белмим, белмим..

Әсәрне **Кояш ТИМБИКОВА** тәрҗемә итте

ДҮШӘМБЕ

23 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.35. Мультфильм. 18.45 Балалар өчен «Тамчы». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшырулар анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булырга тиеш? 20.10 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 БМО бүгенге дөньяда. 3 нче тапшыру. 21.15 «Гашыйклар телеканалы». 21.50 И.Мөхәммәтҗан концерты. 22.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка». 7.30 «КиноМеню». 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 8.15, 11.05 — «Юл патруле». Атналык йомгак. 8.30, 14.45 — «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!». 9.20, 12.55 — «90х60х90». 9.40 Диск-канал. 10.00 «Чәй клубы». Зиновий Гердтта кунакта. 10.30 Сериал: «Один к десяти». 11.20 «Атна фаразлары». 11.50 «Валюта бәясе». 12.00 Нәфис фильм: «Мстители». 4 нче серия. 13.10 Нәфис фильм: «Замороженный». 15.00 Телесериал: «Флиппер». 7 нче һәм 8 нче серияләр. 15.55 «Кино музыкасы». Мәскәү турында җырлар. 16.10 «Минем кино». И.Колеров. 16.50 «Базар» тележурналы. 17.40 «Минем тарих». О.Газманов. 18.05 «Теледискотека». 18.30 А.Габрилович документаль фильмы: «Футбол нашего детства». 19.20 Мультфильм: «Полигон». 19,30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.55 — «Шәһәр» информацион программасы. 20.40 «Табигый газ — мотор ягулыгы». 21.00 Мультфильм: «Ушастик и его друзья». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Нәфис фильм: «В горе... и в радости» (Мадлен Робинсон). 23.15 «Ел буе — сәяхәт». 23.20 «Криминаль хроника тележурналы».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 — Яңалыклар. 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 «Могҗизалар кыры». 11.00 «Чечен балалары». 11.30 Телеуен: «Көен таны». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 «Мәхәббәт формуласы». 14.20 «Кумирлар, кумирлар...» Георг Отс. 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Марафон-15». 16.00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.00 «Джем». 17.30, 0.35 — «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 Фантастик детектив: «Электронные жучки». «Среди мертвецов» (Багз). 4 нче серия. 22.50 «Тарих табышмаклары» циклыннан. Э.Радзинский. «Акыллылык үзе бер бәла». 2 нче кисәк. 23.50, 0.10 Сериал: «Твин Пикс».

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.50 Театраль разъезд. «Однажды в губернском городе NN». 9.35 «Телегазета». 9.40 Телеэкран премьерасы. В.Тодоровскийның «Катафалк» фильмы. 10.50 «Мөһим мизгел». 11.20. «Милиция хроникасы». 11.30 «Музыкаль экспромт». 11.45 Мульти-пульти: «Волшебник Изумрудного города», «Веселая карусель». 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «РОСТ» компасы. «Евровидение концертында яшь талантлар». 2 нче кисәк. 17.50. «Юк, мин бөтенләй үк үлмәдем...» 18.20 «Алыргамы-алмаскамы». 18.30 «Коткару-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 «Дүшәмбе саен детектив». «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм: «Доведенный до отчаяния» (Бөекбритания). 21.40 Репортер. 22.05 «Бизә үсез». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «299-00-00» хезмәте. 23.55 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Горькая кровь» (АКШ). 3 нче серия. 0.45 Джо Коккер — Мәскәүдә.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә!» 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.15 «Гүзәллек». 10.10 «Бибу-шоу». 10:20 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 «Музыка». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле». 13.25, 15.40, 20.55 — «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Табиблар һәм фармацевтлар һәм аларның пациентлары өчен тапшыру: «Рецепт». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.45 Ура, комедия! Нәфис фильм: «В мире грез и фантазий». 17.20 «Антре». Цирк программасы. 17.40 Мультфильм. 18.00 ТВ мәгълүматлары Европа калейдоскобы.
21.30 Д.Хворостовский концерты 22.25 «Шәһәр эшләре». 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Музыкаль шоу: «Парадлар парады». 0.15 Нәфис телефильм: «Валентина» (Италия). 7 нче серия.

СИШӘМБЕ

24 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

